№ 4
2025

# МӘГАРИФ
## ТАТАР ТЕЛЕ



# Мәгърифәтче ХАРИСОВЛАР

5 декабрь, 2025 ел
№ 4

МӘГАРИФ
ТАТАР ТЕЛЕ

ОЕШТЫРУЧЫСЫ:
**«ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ**

УЧРЕДИТЕЛЬ: **АО «ТАТМЕДИА»**

**Телефон редакции:** (843) 222-06-09

**Адрес издателя:**
420097, г. Казань,
ул. Академическая, 2

12+

**www.magarif-uku.ru**

Создано при поддержке Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям.

Зарегистрирован в Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций 04.09.2014 г.

**Эл № ФС 77 - 59204**

**Периодичность выхода** – 1 раз в квартал

Мнение редакции не всегда совпадает с мнением авторов. Редакция не располагает возможностью выступать ходатаем в официальных организациях. За достоверность рекламных объявлений ответственность несёт рекламодатель.

**Почтовый адрес:**
420066, г.Казань, а/я 47
**e-mail:** magarif@bk.ru

**Адрес:**
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
«Мәгариф» журналы редакциясе,
а/т 47
**e-mail:** magarif@bk.ru
**Сайт:** magarif-uku.ru
«Мәгариф», 2025

Баш мөхәррир: **Закирова Г.Р.**
Чыгаручы мөхәррир: **Лотфуллина Ф.А.**
Мөхәррирләр: **Хисмәтова Л.К., Сабиров А.З.**
Корректор: **Фәйзуллина Р.Ә.**
Дизайн һәм вёрстка: **Мадьярова З.Н.**

**ТЫШЛЫКТА:**
Педагогика фәннәре докторлары, профессорлар, Татарстанның атказанган фән эшлеклеләре, Татарстанның атказанган укытучылары **Чулпан һәм Фираз Харисовлар.**

**Альберт САБИР** фотосы.

Журнал распространяется бесплатно.

МИЛЛИ МӘГАРИФ
**Лилия ХИСМӘТОВА**
Мәгърифәтче Харисовлар ... 3
**Фираз ХАРИСОВ**
Татар теле дәресләрендә милли-мәдәни компонентны Каюм Насыйри иҗаты нигезендә куллану ... 11
**Лениза ХӘБИБУЛЛИНА**
Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ» грамматикасында мәгънәви мөнәсәбәтләр бирелеше ... 15
**Диләрия АБДУЛЛИНА**
Урта һәм югары сыйныфлар өчен яңа буын «Туган (татар) телдәге әдәбият» дәреслекләре ... 18
**Гөлнара ҺАДИЕВА**
Әдәбият дәресләре өчен дидактик материаллар ... 22

ҺӨНӘРИ ТӘҖРИБӘ
**Рәмзия ГАБДЕЛВӘЛИЕВА**
Укучыларда функциональ грамоталылык формалаштыру буенча комлекслы биремнәр ... 25
**Миңлегөл СУБАЕВА**
Һөнәри компетентлык һәм әхлак сыйфатлары тәрбияләүдә «Тапшырылмаган хатлар» әсәренең роле ... 29

ДӘРЕС
**Рания ЗАКИРОВА, Миләүшә ХӨСНЕТДИНОВА**
«Сәлам иленә» сәяхәт ... 32
**Язгөл ТАМАСОВА**
Сыйфатларны кабатлау ... 37
**Эльмира ГАРИФУЛЛИНА**
Сүз ясалыш ысулы буларак, сүзләрне кушу. Кушма сүзләр ... 41
**Эльмира ГЫЙЛЬМАНОВА, Налия ГОСМАНОВА**
Бәйлекләр һәм аларның кулланылыш үзенчәлеге ... 45
**Гөлнара ЮНЫСОВА**
Шарт фигыль ... 49
**Гөлнара СӨНГАТОВА**
Бәйлек сүзләр темасын кабатлау ... 55
**Антонида ВАСИЛЬЕВА**
Бакый Урманче – җырлы, моңлы, шигъриятле, озын гомер юлы үткән шәхес ... 58
**Алсу ХӘМИДУЛЛИНА**
Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясе ... 64
**Энҗе ГАЛИУЛЛИНА**
Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» драмасында М.Җәлил образы ... 68
**Азалия ШИҺАПОВА**
Шамил Рәкыйповның «Чәчәкләр сөйли белә» әсәрен өйрәнү ... 71
**Гөлназ ШАГАЛИЕВА**
Басым ... 76
**Гөлия БУЛАТОВА**
Илдар Юзеевнең «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасы ... 81
**Ләйсән ИБРАЕВА**
Галимҗан Гыйльмановның «Ике дус һәм Ак бабай хакында кыйсса» әсәре буенча квест ... 86

1

ИНТЕРВЬЮ




# МӘГЪРИФӘТЧЕ ХАРИСОВЛАР




Алар икесе дә ярты гасырга якын гомерен фәнни-педагогик эшчәнлеккә багышлаган шәхесләр – педагогика фәннәре докторлары, профессорлар, Татарстанның атказанган фән эшлекләләре, Татарстанның атказанган укытучылары, Каюм Насыйри исемендәге премия лауреатлары, «Мәгарифтәге казанышлары өчен», «Мактаулы остаз» билгеләре ияләре, күп хезмәтләрен автордашлыкта язган галимнәр. «Мәгариф. Татар теле» басмасының бүгенге кунаклары – Чулпан һәм Фираз Харисовлар.

**– Сүзебезне үткәннән – мәктәп һәм студент елларыннан ук башлыйк әле. Сез фәнгә һәм мөгаллимлек эшчәнлегенә нинди юллар белән килдегез? Ни өчен нәкъ менә укытучы һөнәрен сайладыгыз?**

**Чулпан Мөхәррәмовна.** Без – Совет чорында белем алып, сайлаган профессияләребез буенча ярты гасырга якын эшләгән кешеләр. Кукмара районындагы Зур Сәрдек урта мәктәбендә укыганда да, аннан соңгы елларда да безнең өйдә китап уку, нәрсәнедер өйрәнүгә омтылыш бик зур иде. Укытучыларымның, өйдә әти-әниемнең хуплавы, әлбәттә, зур роль уйнады. Күз алдына китерегез: мин – барлык уку-укыту һәм тәрбия эшләре татар телендә алып барылган мәктәп укучысы. Һәр атнаның җомга кичендә мәктәптә төрледән-төрле кичәләр уздырыла, әле шул елларда ук «Яктылык» исемле әдәби-музыкаль һәм тәнкыйди эчтәлекле татарча журнал чирек саен чыгарыла, спорт ярышлары, спартакиадалар һәм тагын әллә никадәр башка төрле чаралар үткәрелә иде. Кыскасы, мәктәптә тормыш туган телебездә «кайный» булып чыга. Менә шушындый иҗади мохит һәм укытучыларыбызның укучыларга бердәм педагогик таләпчәнлек белән якын килүләре алдагы һөнәремне сайлауга булышлык итте дип уйлыйм.

Бу урында мин беренче укытучым Саҗидә апа Мөлекованы олы ихтирам белән искә алам. Безгә математикадан Т.М. Сираҗиева, рус теленнән Д.И. Галиева, татар теле һәм әдәбиятыннан Г.В. Каюмова (ул, профессор В.Х. Хаков җитәкчелегендә аспирантурада укып, кандидатлык диссертациясе язды), тарихтан Г.Ә. Хафизов, химиядән А.Ш. Арысланов, физикадан Г.Ф. Гыйләҗева, географиядән Г.Ф. Фазлыева, биологиядән М.Г. Нуриев ныклы белем биреп, киләчәктә алачак һөнәребезгә дөрес юнәлеш тә күрсәтә алган. Бүгенге шартларда еш истә тотыла торган «көндәшлеккә сәләтле булу» да нәкъ әнә шунда күренә.

1970–1975 елларда Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетында татар теле һәм әдәбиятыннан, рус теле һәм әдәбиятыннан бик ныклы, төпле югары белем алу фәнгә һәм мөгаллимлек эшчәнлегенә килүдә хәлиткеч урын

тота. Ул вакыттагы ректор, филология фәннәре докторы, профессор М.З. Зәкиевнең «Татар теленең синтаксисы» исемле монографиясен 4 нче курста укыганда ук редакцияләүдә катнашу, филология фәннәре кандидаты, доцент М.Ш. Җәләлиева җитәчелегендә икебезнең дә фәнни докладлар белән чыгышлар ясавы, 2 нче курста кафедраның фәнни җыентыгында аның белән автордашлыкта мәкалә бастыру – үзе генә ни тора!!! Филология фәннәре кандидаты, доцент З.М. Вәлиуллина җитәкчелегендә язган диплом эшем татар һәм рус телләрендәге рәвешләрне чагыштырып өйрәнүгә багышланган иде. Безнең остазларыбыз арасында филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Р.А. Юсуповны телебезнең чисталыгы, сафлыгы өчен көрәшнең алгы сызыгында баручы олпат галим буларак беләбез.

**Фираз Фахразович.** Мин дә белем-тәрбия процессын ана телендә алып барган, Мостай Кәрим әйтмешли, Башкортстанның төньяк капкасы булган Яңавыл районының Истәк авылы мәктәбендә укыдым. Ул вакытта мәктәп 8 еллык иде, кайбер елларны укучылар саны 350 гә кадәр җитте. Аннан соң Нурихан Фәттах, Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова һ.б. танылган язучылар, артистлар укыган 1 нче урта мәктәптә ике ел белем алдым. Без хәтта төгәл фәннәрне дә Казаннан кайтартылган, татарчага тәрҗемә ителгән дәреслекләр буенча өйрәндек. Менә шундый заманнар бар иде! Кызганыч, хәзер Татарстанда да андый мәктәпләрне эзләп табу җиңел түгелдер дип уйлыйм.

Энекәшләрем белән укытучы һөнәрен әнкәйнең энесе – 1960 елда Казан дәүләт университетының татар бүлеген тәмамлаган Мөнәвир Ибраһим улы Фазлыев һәм аның шул ук елны рус бүлеген тәмамлаган хатыны Рәшидә Закирҗан кызы үрнәгендә сайладык. Аларның гомуми педстажы 80 елга якын иде. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Мөнәвир абый тәкъдиме буенча, Совет армиясе сафларына алынганчы, булачак һөнәремне башта практикада сынап карарга булдым – мәктәптә ике ел лаборант һәм укытучы булып эшләдем. Мөнәвир абыйга дәрәҗәле вазифаларны үтәүче җитәкчеләрдә була торган аналитик акыл, эрудиция, һәр эшкә җаваплы мөнәсәбәт, хезмәт сөючәнлек һәм тапкырлык хас иде. Милли традицияләрне саклаучы гаилә башлыгы, халык җырларын яратып башкаручы, сәясәтне дөрес аңлаучы һәм таләпчән мөгаллим дә иде. Шагыйрь буларак та танылды.

Һөнәри юнәлешемне билгеләүдә, беренче ныклы адымнарны ясауда әнкәйнең дә (ул күп еллар дәвамында мәктәптә тәрбияче булып эшләде) роле бик зур булды.

**– Фираз Фахразович, Сезнең гомуми педагогик стажыгыз да 250 елга якын икән бит. Якыннарыгыз турында да бераз сөйләп китмәссезме?**

**Ф.Ф.** Без гаиләдә дүрт малай бик тату үстек. Иң зурысы мин булам инде. Барыбыз да укытучы һөнәрен сайладык һәм бүгенге көнгә кадәр мәгариф өлкәсенә хезмәт итәбез.

*Фарис* – мәктәп укытучысы, завуч, директор, Мәскәү районы мәгариф идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасының мәгариф министры, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Мәгарифне үстерү федераль институты директоры һ.б. җаваплы урыннарда эшләде. Ул – педагогика фәннәре докторы, профессор, Россия мәгариф академиясе әгъза-корреспонденты, РФ һәм ТРның атказанган укытучысы, РФ гомуми белем бирү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре. Ул – өч дистәдән артык монография, методик кулланмалар, 400 гә якын мәкалә авторы. Аның җитәкчелегендә берничә аспирант кандидатлык диссертациясен яклады. 2009 елдан




«Здоровьесберегающее образование» исемле журналның баш мөхәррире, 2012 елдан бүгенге көнгә кадәр Россия Дәүләт думасында Мәгариф һәм фән, милли эшләр буенча комитетларның экспертлар советы рәисе, 2009 елдан «Мәгарифне сәламәтләндерү: тәҗрибә, проблемалар, үсеш перспективалары» Бөтенроссия форумының идеологы һәм оештыручысы, инде 16 ел дәвамында «Бөтенроссия сәламәтләндерү укытучысы» конкурсының авторы һәм оештыручысы.

*Фәнит* – педагогика фәннәре кандидаты, РФ гомуми белем бирү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре, Татарстанның атказанган укытучысы, ТРның «Фидакяр хезмәт өчен» һәм «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәте өчен», Бөтендөнья татар конгрессы Халыкара берлеге медальләре белән бүләкләнгән, «Укытучы-эзләнүче – 2011» республика гранты иясе, 2014 елда «Безнең иң яхшы директор» гранты җиңүчесе. «Казан хакына мактауга лаек хезмәте өчен» күкрәк билгесе иясе, «ТРның 2008 ел ир-аты» бәйгесендә «Лидер ир-ат» номинациясе җиңүчесе. Ул 35 елга якын Казанның Киров районындагы 15 нче татар гимназиясендә директор булып эшли.

*Фәрит* (1958–2022) – Фәнитнең игезәге. Ул – РФ гомуми белем бирү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре, Башкортстанның атказанган мәгариф хезмәткәре, Башкортстанның мәгариф отличнигы, 30 елдан артык Яңавыл шәһәрендә мәктәп һәм гимназия директоры, шәһәр мәгариф идарәсе мөдире булып эшләде. Күп еллар дәвамында Россия география оешмасының Яңавыл бүлеген җитәкләде, өч тапкыр Яңавыл шәһәр советы депутаты булып сайланды һәм шәһәр советы рәисе вазифаларын үтәде. I Бөтенроссия мәгариф оешмаларының смотр-конкурсы лауреаты, «Бөтенроссия хезмәт даны» проекты кысаларында «Россиянең мактаулы педагогы» исемле 1 нче

дәрәҗәдәге медаль иясе. Кызганыч, энекәшебез бик иртә бакыйлыкка күчте.

Хатыннарыбыз да – укытучылар: Чулпан белән Людмила педагогика фәннәре докторлары, профессорлар. Резеда 40 елга якын Яңавылда татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләде. Без барыбыз да пединститутның тарих-филология факультетын тәмамладык.

**– Тел укытуга караган хезмәтләрне иҗат итүгә Сезгә нәрсәләр этәргеч ясады? Фәнни һәм һөнәри эшчәнлегегездә шуларның кайсысын иң әһәмиятлесе дип саныйсыз?**

– Телебезне сыйфатлы итеп укыту өчен кирәк булган әсбапларны булдыруның төп максаты – аның фәнни системасын, эчке үзенчәлекләрен аңлату, шушы телдә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү. Әлбәттә, бу киң масштаблы эш ике төрле юнәлештә алып барылса отышлы (һәм шактый еллар буе шулай укытылды да): туган тел буларак өйрәнүче өчен ул система буларак, ә башка яки чит тел буларак өйрәнүчегә телдән сөйләмне оештыру өчен кирәк. Кызык бит: кемнәрдер (республикабызда яшәүчеләр турында сүз бара), мәсәлән, ике, кайвакыт өч телдә дә сөйләшә, аралаша, балалары да әлеге эштән читтә калмый. Ә икенче берәүләр исә бары бер телне генә белә. Балаларда аларның кайсылары соклану, гаҗәпләнү, яхшы мәгънәсендә көнләшү, хәтта телне өйрәнүгә омтылыш та тудырырга мөмкин?

Безнең төп фәнни-методик юнәлешебез – башка милләт вәкилләрен һәм татарча сөйләшә белмәгән милләттәшләребезне татар теленә өйрәтү. Кандидатлык һәм докторлык диссертацияләребез дә шушы проблемага багышланган. Татар теле укыту методикасы тарихында безгә кадәр бу өлкә буенча докторлык диссертациясен беркем дә язмаган булган. Басылып чыккан хезмәтләребез дә меңнән артып китә. Шуның нәтиҗәсе буларак, мәктәп-гимназияләр һәм югары уку йортлары өчен утыз елдан артык татар теле программалары, монографияләр, дәреслекләр, укыту-методик кулланмалары, мультимедиа чаралары (компакт-дисклар, электрон дәреслекләр һәм кулланмалар), сүзлекләр (арада рәсемлеләре дә бар) төзедек. Әйтергә кирәк, төрле дәрәҗәдәге, эчтәлектәге китапларның, брошюраларның саны 160 тан артып китә. Мәктәптә һәм югары уку йортында эшләү тәҗрибәсе шактый булу сәбәпле, телне өйрәтү өчен, нинди материалларның кирәклеген, кайсыларының җитмәвен, аларны өйрәнүчегә – укучыга, студентка ничек итеп җиткерүнең беренчел әһәмиятен аңлап эш итүгә китерде. Шулай ук татар теленең сүз ясалышы һәм морфологиясенә караган фәнни һәм фәнни-популяр характерда язылган шактый гына хезмәтләребез дә бар. «Татар теле. Кагыйдәләр, күнегүләр» исемле китабыбыз 2007 ел нәтиҗәләре буенча «Мәгариф» нәшриятының «Татар теле» номинациясендә иң күп сатыла торган китап дип танылды. «Татарский язык. Справочник» (2014); шулай ук 9–11 нче сыйныфлар өчен өч кисәктән торган «Татар теле: олимпиадага әзерләнү» (2016, 2017) исемле китаплар да укытучылар һәм укучылар арасында киң популярлык казанды, берничә тапкыр нәшер ителде.

**– Сезнең тарафтан төзелгән рәсемле татарча-русча сүзлекләр дә Татарстан китап нәшриятында берничә тапкыр басылып, тиз арада сатылып та бетте бит.**

– «Иллюстрированный татарско-русский словарь» (1995) – «Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителә» дигән гриф белән берничә тапкыр нәшер ителде, димәк, ул бөтен Россиядә законлы рәвештә кулланыла ала торган китап.

2017 елда басылып чыккан «Рәсемле татарча-русча тематик сүзлек» Татарстан Мәдәният министрлыгы уздырган «Ел китабы – 2019» конкурсында II дәрәҗә Дипломга лаек булды.

Бу хезмәтләрнең барысы да безнең өчен кадерле, алар бик күп балаларга, татар телен белмәүчеләргә тәрбия һәм белем бирү чыганагы буларак кулланыла.

**Кызганыч, соңгы елларда телебез чүпләнә, аның әйтелеш нормалары да бозыла бара, моңа без бик борчылабыз. Шуңа да рус телендә сөйләшүчеләрне татарча әйтелешкә өйрәтүгә багышланган хезмәтләребез аерым бер юнәлешне тәшкил итә. Бу өлкәгә караган һәм төрле нәшриятларда басылып чыккан күләмле монографияләр – «Обучение татарскому произношению в русской школе» (Мәскәү, 2000), «Теория и практика обучения произношению в русскоязычных школах (начальный этап)» (Санкт-Петербург, 2001), «Татарча әйтелешкә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре» (Казан, 2018) хәзерге лингвометодистлар тарафыннан югары бәя алды.**

**– Әгәр Сезгә «Гаилә учагында һәм фәнни хезмәттәшлектә» исемле истәлекләр китабын язарга тәкъдим итсәләр, анда нинди бүлекләр булыр иде?**

– Иң башта ул китапның тышына исемен язгач, җәяләр эченә «Аларның гаиләсе өчен бу гадәти хәл» дип өстәр идек (елмаялар). «Гаилә нык булганда, эшләр дә гөрләп бара», «Гомеребезнең иң якты мизгелләре», «Икең дә укытучы булу җиңелме?», «Яшәү өчен түгел, эшләү өчен яшәү», «Безнең кулыбызда телебезнең, милләтебезнең киләчәге», «Мәгариф проблемалары: борчыган мәсьәләләр һәм тәкъдимнәр» дигән бүлекләр булыр иде, дип уйлыйбыз.

**– Балаларыгызда туган телгә һәм мәдәни мираска мәхәббәт тәрбияләүдәге тәҗрибәгез белән дә уртаклашсагыз иде. Ул безгә, яшьрәк буын вәкилләренә, үрнәк булып тора.**

– Әти-әнинең балаларына биргән тәрбиясе турында сүз чыкканда, иң башта бу мәсьәлә гаиләнең яшәү рәвешенә бәйле, дип уйлыйбыз. Без икебез дә укытучылар укытучысы булып эшлибез. Өйрәтү (укыту) объектыбыз – туган телебез – татар теле. Ул безнең тормышыбызда төп урынны били. Шулай булгач, табигый ки, балаларыбыз да татарча рухта үсте. Улыбыз белән кызыбыз Казандагы 7 нче рус гимназиясен тәмамласалар да (өйгә якын иде!), татарча сөйләшеп, татарча китаплар укып, татар теленнән олимпиадаларда катнашып, призлы урыннар алып укыдылар. Гимназиядә инглиз телендә сөйләшергә өйрәнделәр. Тормышларында өч телне куллана алу аларга һич кенә дә авырлык тудырмый. Рус һәм инглиз телләрен белү туган телдә сөйләшергә, аралашырга бер дә комачау итми аларга. Алар, үз һөнәрләрен сайлаган белгечлекләре буенча югары белем алып, икесе дә кандидатлык диссертацияләрен якладылар. Улыбыз Мәскәү дәүләт университетында аспирантурада укыды. Ул – икътисад фәннәре кандидаты. Кызыбыз – психология фәннәре кандидаты. Илшат гаиләсе белән чит илдә инде ун елдан артык яши, өч балалары бар, алар мәктәптә укый. Үзе дөньяның танылган консалтинг компаниясендә үсеш проектларын төзү белән шөгыльләнә, киленебез Венера белән оныкларыбызны үзебезчә, татарча, милли рухта тәрбиялиләр, ана телендә сөйләшәләр. Кызыбыз Гөлшат КФУда

укыта, доцент, психологлар, укытучылар һәм ата-аналар өчен «Инновацион мәгариф психологиясе һәм балалар сәләтен үстерү» исемле магистр программасын төзегән иде. Ул – Европа психологлар ассоциациясенең сертификацияләнгән психологы, Россия психология оешмасы әгъзасы, Россия Дәүләт думасының мәгариф һәм фән комитетында эксперт советы әгъзасы. Оныкларыбыз Гайшә белән Йосыфның теле туган телдә ачылды, алар, безнең белән телебезне бозмыйча, татар телендә аралаша. Оныкларыбыз, балалар бакчасына йөргәндә үк, шәһәребезнең «Татар кызы», «Татар малае» конкурсларында призлы урыннарны алып, кыйммәтле бүләкләргә ия булды. Шуңа да һич шикләнмичә әйтә алам: балаларның да, оныкларның да туган телен белүе, беренче чиратта, әти-әнисе, әби-бабасының яшәү рәвешенә, аларның үз теленә карата уңай мөнәсәбәтенә турыдан-туры бәйле. Телне аралашканда гына саклап калып була бит, аралашудан туктыйсың икән, ул инде юкка чыга һәм милләтнең дә бетүенә китерергә мөмкин. Дөресе мәкальдәгечә: «Иң татлы тел – туган тел, анаң сөйләп торган тел».

**– Фираз Фахразович, Сезнең фикерегезчә, заманча укыту технологияләре яшьләр арасында татар телен популярлаштыруга ничек ярдәм итә ала?**

**Ф.Ф.** Мөмкинлекләр бик зур: компьютер технологияләре, төрле электрон белем бирү ресурслары, КФУның «Ана теле» онлайн мәктәбе бу өлкәдә зур эш башкара, хәзер белгечләр ясалма интеллектны файдалану турында да сүз алып баралар. Матбугатта да төрледән-төрле язмалар чыгып тора. Без үзебез дә бу турыда еш уйланабыз. Үткән берничә ел вакыт эчендә төрле нәшриятларда заманча белем бирү технологияләренә багышланган хезмәтләр бастырып чыгару насыйп булды: «Заманча белем бирү технологияләре» (2015); «Татар теле: укыту теориясе һәм практикасы» (2018); сүзлекләребез нигезендә төзелгән компакт-дисклар, электрон дәреслекләр, кулланмалар һ.б. Татар теле укыту методикасы буенча автордашыбыз Г.Р. Шакирова белән иҗат иткән һәм әле генә диярлек «табадан төшкән» укыту-методик комплектта (УМК) да заманча технологияләргә киң урын бирелә. Яшьләргә килгәндә, алар өчен заманча укыту җиһазлары, төрле технологияләрне үзләштерү әллә ни кыенлык тудырмас. Тик аларны дәреснең кайсы этабында, укучыларның яшенә, мөмкинлекләренә туры китереп, әмма шул ук вакытта чамасын да белеп (дәрес 40–45 минут кына бара бит!) куллану осталыгы турында да онытырга ярамас. Тел дәресләрендә укырга-язарга өйрәтү максаты гына куелмый, бәлки шушындый технологияләрне укучыларның сөйләшә белү куәсен арттыруга да юнәлтергә кирәк.

**– Әгәр Сезгә Татарстан мәгариф системасында татар телен өйрәтүнең сыйфатын арттыруга юнәлтелгән тәкъдимнәр кертергә кушсалар, беренче чиратта нинди чара күрергә кирәк дип уйлыйсыз?**

**Ф.Ф.** Билгеле инде, беренче чиратта телебезне өйрәтү өчен каралган сәгатьләр санын арттыру кирәклеген ассызыклар идем. Моның өчен республика җитәкчелеге башка милли республикалар белән берлектә федераль җитәкчеләр, Дәүләт думасы депутатлары белән даими рәвештә эш алып барырга тиеш. Күптән аңларга вакыт: атнага 2+1 яки 1+1 варианты белән балага телне камил дәрәҗәдә өйрәтеп булмый. Җитмәсә, хәзер бик күп гаиләләрдә аралашу рус телендә генә бара. Әти-әниләрнең бу мәсьәләгә карата карашын үзгәртергә кирәк, чөнки аларның күбесе, баласы татар теле һәм әдәбияты дәресләренә йөрсен өчен, гариза да язмый бит хәзер.

Мәгариф системасы өчен кадрлар әзерләү проблемасы турында да җитди сөйләшүнең урынлы булуын танырга кирәк дип уйлыйм. Бу хәл башка предмет укытучыларына да кагыла. Белгечләр әзерләү турында сүз чыккан икән, югары уку йортларында өйрәнелә торган төп фәннәрнең дә сәгатьләрен арттыру кирәклеге көн тәртибенә куелсын иде, чөнки аларның күләме даими рәвештә кимеп бара. Без хәзер полуфабрикат әзерлибез түгелме соң?!

– **Чулпан Мөхәррәмовна, тормышларын педагогикага һәм фәнгә багышларга хыялланган яшьләргә Сез нинди киңәшләр һәм үгет-нәсыйхәтләр бирә алыр идегез?**

**Ч.М.** Уку – энә белән кое казу ул. Бер караганда, кеше кайда гына укымасын, аңа сыйфатлы белем алу өчен, өзлексез укырга, эзләнергә, китапханәләрдә озаклап утырырга кирәк. Мөстәкыйль яшәү, зачёт-имтиханнарга әзерләнү, өстәмә әдәбият белән танышу – барысы да яшь кешегә ерып чыга алмаслык гамәл булып тоелырга мөмкин. Әмма баштан ук һәр эшен алдан уйлап, планлаштырып куярга өйрәнгән студент яисә яшь укытучы бер дә югалып калмый, барына да җитешә ала. Тик тагын бер нәрсәне истә тоту кирәк дип саныйм: студент үзенең укуы, эш-гамәлләре өчен генә җавап бирә. Ә укытучы балалар белән, алай гына да түгел – әти-әниләр белән дә даими эшләргә тиеш. Димәк, укытучы һөнәрен сайлаган кеше үзенең җәмгыять алдында җаваплы һәм бурычлы булуын истә тотып эшли, яши дияр идем. Аның эш объекты – яшь буын, шулай булгач, укучылар ничек, нинди белем һәм тәрбия алган, укытучы эшенең нәтиҗәсе дә шунда күренә. **Булачак укытучы беренче көннән үк үзе сайлап алган һөнәрен яратырга өйрәнергә тиеш.** Күренекле тарихчы һәм акыл иясе Василий Ключевский: **«Яхшы укытучы булу өчен, үзең укыткан фәнне дә һәм укучыларны да яратырга кирәк»,** – дип, бик дөрес язып калдырган.

**Лилия ХИСМӘТОВА**
**Альберт САБИР** фотолары




**Редакциядән.**

*Язма басмага әзерләнгән көннәрдә Фираз Фахразовичның Мәскәүдән тантаналы чарадан кайтуы билгеле булды. Ул анда «Россия югары мәктәбенең алтын исемнәре» Бөтенроссия конкурсының җиңүчесе итеп танылган! Аның исеме «Золотые Имена Высшей Школы» дигән басма һәм электрон китапка кертелгән. Без аны редколлегия һәм барлык журнал укучылары исеменнән зур җиңүе белән ихлас күңелебездән котлыйбыз!*

2



**Фираз ХАРИСОВ,**

КФУның татар теле белеме кафедрасы профессоры,
педагогика фәннәре докторы

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МИЛЛИ-МӘДӘНИ КОМПОНЕНТНЫ КАЮМ НАСЫЙРИ ИҖАТЫ НИГЕЗЕНДӘ КУЛЛАНУ

МИЛЛИ МӘГАРИФ

**Тел ул – иҗтимагый күренеш һәм әйләнә-тирә дөнья турындагы мәгълүматны саклаучы, милли мәдәниятнең көзгесе. Милли-мәдәни компонент (ММК) уку-укыту процессына мәдәният белеменә караган материалларны, укучыларның аралашу компетенциясен тәэмин итә торган халыкның рухи мәдәнияте эчтәлеген туплаган белешмәләрне системалы һәм эзлекле рәвештә кертүне күздә тота. Шуңа да, безнең уебызча, татар теле дәресләрендә милли-мәдәни компонент укытуның эчтәлеген тәшкил итәргә тиеш. Бу өлкәдә телебезне өйрәтүгә зур өлеш керткән бөек мәгърифәтчебез Каюм Насыйриның эшчәнлеге бүгенге көндә дә зур әһәмияткә ия.**

**Башлап йөрүче галим-методист**

Заманында татар әдәбиятының күренекле вәкиле Галимҗан Ибраһимов та аны үз халкы идеяләренең даһи реформаторы дип атый. Чыннан да, телебезне үстерүгә, аның грамматик нигезләрен фәнни яктан эшкәртүгә, аңлатмалы сүзлекләр төзүгә Каюм Насыйри зур көч куя. Аның тарафыннан төзелгән «Әнмүзәҗ» исемле хезмәт Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди эшчәнлегенә, аерым алганда, мәктәп дәреслекләре төзүгә үрнәк булып тора. Күрәбез: заманыбызның күренекле тел галиме М.З. Зәкиев әйткәнчә, К. Насыйри татар милли әдәби теленең теоретик проблемалары белән генә чикләнми, бәлки аларны гамәли яктан да тормышка ашыруда да үзеннән саллы өлеш кертә. Татар телен туган тел буларак та, башка милләт вәкилләренә укытуда да, бүген без, бик актуаль саналган икетеллелек проблемасы буенча да ул – башлап йөрүче галим-методист, дип әйтә алабыз.

**Милли өметләр рус халкына бәйле**

Татарстан Республикасы Дәүләт архивында сакланган документлар арасында Каюм Насыйриның Казан руханилар училищесында һәм Казан руханилар семинариясендә 1855–1870 елларда татар теле укытучысы булып эшләве турында мәгълүмат бар. Җитмәсә, тору урыны булмагач, ул семинария бинасында берничә ел яши дә. Аның «Кыскача татар грамматикасы» исемле китабы студентлар өчен уку әсбабы буларак уңышлы файдаланыла. Галимнәр тарафыннан Каюм Насыйриның балалар өчен язылган әйләнә-тирә дөнья турындагы китабы да рус телле кешеләргә татар телен өйрәтү өчен уңайлы кулланма дип саналган. Каюм Насыйри үз милләтенең үсешенә өметләрен рус халкы белән бәйли. Ул татар һәм русларның үзара дус, тату яшәвен һәрвакыт хуплый, беренче чиратта, үзенең хезмәтләрендә рус мәдәнияте һәм аның белән якынаюы аркасында уңышка ирешүен ассызыклый.

Каюм Насыйри хезмәтләрен игътибар белән өйрәнгән кеше күрми калмас: аларда ММКның эчтәлеген билгеләгәндә, бары лингвистик критерийларны гына истә тотып эш итәргә ярамавы ачык күренә. Беренче чиратта, куелган методик максатны исәпкә алып, телне өйрәткәндә, укучылар милли мәдәниятка дә тартылырга тиеш. Хәзерге вакытта укучыларга, һичшиксез, үз халкының рухи мәдәнияте белән бергә аның рус һәм башка халыкларның мәдәниятләре белән уртак яклары турында да белү кызыклы булачак. Дәрестә этнограф Каюм Насыйри тарафыннан җыелган һәм системалаштырылган фольклор материалларын файдаланырга була. Мондый материал укучыларның татар мәдәниятенең югары кыйммәтләрен үзләштерү буенча танып белү эшчәнлеген активлаштыруга ярдәм итәчәк, ул татар әдәбияты, фольклоры үрнәкләрен нәтиҗәле итеп укыту максатларына хезмәт итәчәк.

Н.М. Шанский билгеләп үткәнчә, рус теленә өйрәтүне рус халкының мәдәниятен үзләштерү белән бәйләргә кирәк, ә методик системаны камилләштерү мәктәп курсына милли-мәдәни компонентны эзлекле кертү белән бәйле. Бу фикер безнең телебезне башка милләт вәкилләренә өйрәтүгә дә турыдан-туры карый. Чөнки андый материал укучыларда татарларга хас булган, әмма текстны адекват кабул итү өчен кирәкле белемнәр, ассоциацияләр, эмоциональ бәя формалаштыра. Шәхеснең эчке дөньясы билгеле бер иҗтимагый коллективка хас булган нормалар һәм кыйммәтләр тәэсирендә, кешене милли традицияләргә, гореф-гадәтләргә тарта торган милли-мәдәни фонда формалаша. Хәзерге тел ситуациясе шартларында кешенең формалашуы ике, кайчакта күбрәк милли мәдәният, традицияләр, сөйләм һәм башка этик нормалар системасы йогынтысында бара.

**Татар теле дәресләренә ММКны куллану укучыларда кызыксыну уяту өчен җирлек булып тора. Мәдәни компонент фразеологизмнар һәм мәкаль-әйтемнәрдә дә, халык авыз иҗатының башка төрле жанрларына караган әсәрләрендә ачык чагылыш таба. Шулай ук укучыларның бу белемнәре географик характердагы мәгълүматлардан, тарихи вакыйгалардан, көнкүрештән, татар теленең милли-мәдәни семантикасына һәм мәдәниятлелек аспектына ия булган тел берәмлекләреннән төзелә.**

**Этномәдәни компонент**

Дәресләрдә туган якны өйрәнү материалын куллану да укучыларның туган теле һәм мәдәнияте белән ярашырга тиеш. Бу материаллар укучыларга үз яшьтәшләренең милли-мәдәни проблемаларына тирәнрәк үтеп керергә, башка телне үзләштерү белән кызыксынуны арттырырга ярдәм итә, эшне сөйләм эшчәнлеге төрләре белән үзара бәйләнештә, ягъни коммуникатив нигездә алып бару шарт.

Татар һәм рус телләрен үзара бәйләнешле өйрәтү принцибын тормышка ашыру, шулай ук сөйләм эшчәнлеге төре буларак укырга өйрәтүдә этномәдәни компонентны киңрәк куллану өчен, без сөйләм тәртибе һәм этикеты традицияләренә, гореф-гадәтләрен һәм нормаларын чагылдырган милли бәйрәмнәр турындагы текстларга (Сабан туе, Нәүрүз, Пасха, Татьяна көне һ.б.), декоратив-гамәли сәнгать (костюм, чигү, күн эшләнмәләре, нәфис керамика һәм металл эшкәртү, ташка уеп ясау һ. б.), шул ук вакытта күрсәтмәлелеккә (картиналар, рәсем сәнгате әсәрләренең репродукцияләре, мәдәният ядкәрләренең фотосурәтләре, декоратив-гамәли сәнгать әйберләре, видеоматераллар) һәм укучыларның бу өлкәдәге төп белемнәренә таянабыз. Болар барысы да ММКка караган текстларны яхшырак аңларга, дөньяга карашны киңәйтергә һәм укучыларның мәдәният өлкәсенә караган компетенциясен җентекләбрәк формалаштырырга ярдәм итә.

Татар телен өйрәткәндә, тел һәм сөйләм материалларын чагыштырырга, гомуми һәм берләштерүче элементларны ачыкларга була. Күрсәтмәлелек һәм туган мәдәният белән чагыштыру методын куллану, күрү-ишетү образларын файдалану нәтиҗәсендә материал шактый җиңел үзләштерелә,

уку процессы интенсивлаштырыла, ә укытучы тәкъдим иткән текстлар яңа мәгълүмат чыганагы булып тора. Күрсәтмәлелек өйрәтеп кенә калмый, бәлки танып белү, тәрбияләү функцияләрен дә үти, сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы һәм тотрыклырак күнекмәләр формалаштыруга ярдәм итә.

Декоратив-гамәли сәнгать материалларын халыклар мәдәнияте диалогын формалаштыруның мөһим чыганагы буларак куллану очраклы түгел: халыкларга хас булган гомумкешелек кыйммәтләренең бердәмлеген сәнгать кенә үз эченә ала ала. Аерым алганда, татар сәнгатендә милли үзенчәлекләр аның мәдәниятендә, көнкүрешендә, дөньяга карашында чагыла. Татарларның декоратив-гамәли сәнгате тамырлары белән ерак үткәнгә барып тоташа. Үз эшенең тиңдәшсез осталары тамбур белән чигү һәм алтын белән тегүдә, күн мозаика һәм ювелир әйберләр ясауда, бизәкле туку, каллиграфия, нәфис керамика һ.б. искиткеч әсәрләр иҗат иткән.

Татар бәйрәмнәренең шактый өлеше бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Казан татарларының Җыен һәм Сабан туе бәйрәмнәре дә борынгылыгы белән аерылып тора. Туй, өй туе – традицион рәвештә күп халыкларның гаилә бәйрәмнәре дә. Татарларның һәм русларның бәйрәм мәдәнияте дөньяви һәм дини бәйрәмнәргә бүленә (татарларда – Корбан бәйрәме, Ураза бәйрәме, русларда – Раштуа, Пасха һ.б.).

Укырга өйрәткәндә, сөйләм эшчәнлегенең башка төрләренә өйрәткән кебек үк, татар (рус) халык бәйрәмнәре турындагы текстлар белән эшләгәндә, укытучылар күрсәтмәлелеккә таянырга тиеш, бу исә укучыларда культурологик белемнәрне киңәйтә, тел өйрәнү белән кызыксынуны арттыра.

**Билгеләү критерийлары**

Укылган текстның эчтәлеген аңлау дәрәҗәсен, укуның продуктивлыгын һәм аңлы булуын, үзеңнең сөйләм әсәрләреңне булдыруны, тексттан культурологик мәгълүматны ала белүне түбәндәге критерийлар буенча билгеләргә мөмкин:

1. Этнокультура белеме материалын үз эченә алган текстны аңлау сыйфатын ачыклау:

– төп теманы билгеләү;

– текстның эчтәлеген аңлау (төп фикерне аерып чыгару, төп сүзләрне, фразаларны билгеләү, татар халкының милли-мәдәни үзенчәлекләрен тасвирлаган урыннарны табу һәм уку);

– текстта милли колоритны тапшыру өчен кулланылган тел чараларын аңлау (табу);

– текстның мәгънәсен аңлату (текстка һәм абзацларга исемнәр бирү).

2. Укылган текст ярдәмендә укучыларның аралашу компетенциясен ачыклау:

– авторның теманы һәм төп фикерен ачуы (текстның эчтәлеген сөйли белү);

– укучылар әйткән сүзләрнең аралашу юнәлешенә туры килүе;

– әйтелештә мәдәнияткә караган белемнәрне куллана белү (укучылар сөйләмендә татар милли мәдәнияте чынбарлыгын чагылдырган образлы-сәнгатьле тел чаралары, терминнар булу).

Шулай итеп, татар теле дәресләрендә ММКлы текстларны куллану укытуның милли-мәдәни аспектын тормышка ашыру максатларына һәм бурычларына, укучыларның аралашу мөмкинлекләрен киңәйтүгә туры килә. Әлеге материалларны дәресләрдә актив куллану укучыларның халыкның милли-мәдәни мирасы турындагы белемнәрен киңәйтергә һәм тирәнәйтергә ярдәм итә.

3



**Лениза ХӘБИБУЛЛИНА,**

филология фәннәре докторы,
ТР Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты өлкән фәнни хезмәткәре

# КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ «ӘНМҮЗӘҖ» ГРАММАТИКАСЫНДА МӘГЪНӘВИ МӨНӘСӘБӘТЛӘР БИРЕЛЕШЕ

МИЛЛИ МӘГАРИФ

**Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ» грамматикасы 1895 елда басыла. Әлеге хезмәт татар телен комплекслы фәнни тикшерүнең беренче тәҗрибәсе булып тора. «Әнмүзәҗ» грамматикасында мәгънәви, семантик-синтаксик мөнәсәбәтләр махсус анализланмаса да, аларга килеш, бәйлек, теркәгеч һәм рәвешләрне өйрәнгәндә игътибар ителә.**

Семантик-синтаксик мөнәсәбәтләр вакыйгаларның эчке логик-мәгънәви бәйләнешләрен белдерәләр. Аларның семантикасы күп очракта җөмләнең яки контекстның гомуми эчтәлеген анализлап ачыклана, чөнки татар телендә еш кына бер үк бәйләүче чаралар төрле мәгънә белдерү өчен хезмәт итә һәм аерым семантика маркеры булып санала алмыйлар. Мәсәлән, татар телендә һәм, гомумән, төрки телләрдә сәбәп-нәтиҗә һәм максат семантикалары формаль яктан охшаш, чөнки әлеге мөнәсәбәтләрне белдерүче конструкция компонентлары еш кына бер үк чаралар ярдәмендә, әйтик, баш кисәккә *өчен* бәйлеге ярдәмендә ияргән иярчен кисәк/җөмлә белән белдереләләр. Максат һәм сәбәп-нәтиҗә мәгънәләрен аеруда төп күрсәткеч булып контекст – эш-хәлнең махсус эшләнүе яки эшләнмәве санала.

«Әнмүзәҗ» хезмәтендә Каюм Насыйри да сәбәп мәгънәсенең *өчен* бәйлеге ярдәмендә бирелүе турында яза: *«Өчен – тәғлил вә сәбәб мәғнәсе өчен мөстәғмәлдер, мәсәлән: Син кичә ни өчен килмәдең»*. Әлеге чара ярдәмендә максат мәгънәсен дә белдерү турында әйтелми.

«Әнмүзәҗ» грамматикасында шарт мөнәсәбәтләрен белдерүче *әгәр, әгәр дә, бәнагяһ* шарт теркәгечләре күрсәтелә: *«шарт хәрфе дигәнемез шундайын хәрефдер ки, бер нәрсәнең үҗугына икенче нәрсәне шарт йасыйдыр: Әгәр кич тыныч вә җилсез булса, қойаш йақтырыб чығар; Әгәр шәрикләр арасында мовафәқәт булмаса, аларның эше һич уңға бармас»*.

Тел белеме фәнендә кире шарт мәгънәсен белдерүче конструкцияләргә карата галимнәрнең фикерләре бердәй түгел, чөнки алар төзелеше буенча да, мәгънәви эчтәлеге буенча да вакыт, сәбәп-нәтиҗә, шарт мөнәсәбәтләре белән тыгыз бәйләнештә. Тюркологлар В.А. Богородицкий, Н.К. Дмитриев кире шарт мөнәсәбәтләрен шарт мөнәсәбәтенә якынайталар һәм кире шарт җөмләсен иярчен шарт җөмләнең бер төре дип карыйлар.

Каюм Насыйри да «Әнмүзәҗ» грамматикасында шарт һәм кире шарт мәгънәсен аерып карамый. Фигыльнең шарт наклонениесе кулланылган җөмләләр күрсәтелә, әмма китерелгән мисалларның барысы да шарт мәгънәсен белдерми: *Син бойырсаң, мин эшләрмен; Ул чакырса, мин барырмын; Син аны белсәң дә әйтмәссең; Бу китаб кирәк булмаса, мин аны йазмас идем*. Күргәнебезчә, *Син аны белсәң дә әйтмәссең* мисалында кире шарт мәгънәсе белдерелә.

Шарт һәм кире шарт мөнәсәбәтләрен аерып карамау моннан соң дөнья күргән Г. Алпаров, В.Н. Хангилдин грамматикаларында да очрый.

Шарт мөнәсәбәтләренең иң төп һәм еш кулланыла торган күрсәткече – шарт фигыль формасы. Иярчен шарт җөмлә иң беренче формалашкан иярчен җөмлә типларыннан санала, чөнки борынгы шарт формасы *-сар/-сӓр* V–VII гасырга караган төрки язма истәлекләрендә очрый.

«Әнмүзәҗ»дә дә шарт фигыльнең *-са/-сә* кушымчасы ярдәмендә ясалуы һәм шарт мәгънәсе белдерүе әйтелә: *«Фиғыл шарт ошбу тариқча тәсныйф қыйлынадыр ки, асыл фиғылдән соң -са/-сә хәрфе илхақ қыйлыныб шарт мәғнәсен ифадә қыйлыр: йазсам, йазсаң, йазса...»*.

Татар телендә, гомумән, төрки телләрдә шарт фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле ярдәмендә ясалган конструкция теләк мәгънәсен белдерә. Әлеге үзенчәлек Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ» грамматикасында да игътибарга алына: *Алсиде җани алсиде, ағызмаған баллар булсиде. Һавадин фәрештә инсиде, инде қаушасыз дисиде.*

Хәзерге лингвистика фәнендәге антропоцентризм күренеше белән бәйле рәвештә тел системасында кешегә мөһим урын бирелә. Мәгълүм булганча, вакыйгалар, күренешләр, процесслар һәм кеше үзе дә телдә пространство һәм вакыт яссылыгында күзаллана. Пространство мөнәсәбәте – лексик-синтаксик категория, чөнки еш кына ул лексема буларак аерым сүз белән түгел, ә сүзләрнең синтаксик формалары ярдәмендә белдерелә. Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә пространство семантикасын килеш формасындагы сүзләр (юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше), бәйлек сүзле конструкцияләр, рәвешләр, алмашлыклар белдерә ала.

«Әнмүзәҗ» грамматикасында, пространство мәгънәсен белдерү өчен, *-да/-дә* урын-вакыт килеше формасының кулланылуы әйтелә, мисаллар китерелә: *Ул Қазанда тора; Мәсҗеддә намаз уқыйлар*. Моннан тыш, Каюм Насыйри пространство белдерүче *арт, алд, уң, суң (сул), аст, өст, урта, ара* сүзләрен билгели.

И. Гигановның «Грамматика татарского языка» (1801), А. Казем-Бекның «Общая грамматика турецко-татарского языка» (1846) грамматикаларында темпораль мәгънә белдерүче вакыт рәвешләре күрсәтелә. Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ»ендә түбәндәге сүзләр вакыт рәвешләре дип карала (барысы да рәвеш булмаса да): *бу көн/бүген, көндез, төнлә, төнәген, әле, байа, иртә, кич, өйләдә, иртә белән, кич белән, кыш көне, йаз көне, җәй көне, көз көне, бу йыл/быйыл, былтыр, ай, йыл, атна, тәүлек һ.б. Мәсәлән: Кичә килдем, көндез йоқладым.*

Күргәнебезчә, Каюм Насыйриның татар телен алга таба фәнни өйрәнүгә теоретик нигез булып торган «Әнмүзәҗ» грамматикасында семантик-синтаксик мөнәсәбәтләргә берникадәр урын бирелә: сәбәп-нәтиҗә, шарт, пространство һәм вакыт мөнәсәбәтен белдерүче кайбер чаралар күрсәтелә.

***Әдәбият:***

1. Насыйри К. Әнмүзәҗ. – Казан, 1975. – 213 б.

2. Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч. III. Синтаксис / под общ. ред. Н.К. Дмитриева, Н.А. Баскакова, Е.И. Убрятовой. – М.: Изд-во АН СССР, 1961. – 232 с.

4



**Диләрия АБДУЛЛИНА,**

ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты милли мәгариф бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, Татарстанның атказанган укытучысы

# УРТА ҺӘМ ЮГАРЫ СЫЙНЫФЛАР ӨЧЕН ЯҢА БУЫН «ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ» ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕ

МИЛЛИ МӘГАРИФ

Алдагы чыгарылышта белем бирү системасында туган тел һәм туган телдәге әдәбиятны заман таләпләреннән чыгып укыту өлкәсендәге үзгәрешләрне исәптә тотып, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлегендә 1–11 нче сыйныф укучылары өчен «Туган (татар) телдә әдәби уку» һәм «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметыннан яңа буын укыту-методик комплектлары эшләнүен хәбәр иткән идек (*авторлары: Мөхәрләмова Г. Н. һәм Абдуллина Д. М.*). Башлангыч белем бирү звеносына тәкъдим ителгән «Әдәби уку» дәреслекләренә шактый тәфсилле күзәтү дә ясалды.

Алга таба урта һәм югары сыйныфларга аталган «Туган (татар) телдәге әдәбият» дәреслекләре белән таныштыруны дәвам итәбез. Алар башлангыч белемне нигез итеп ала һәм алга таба үстерә. Укытучы һәм укучы өчен бөтен кирәкле материал бергә тупланган: дәреслек, электрон дәреслек, уку әсбабы (сыйныфтан тыш уку өчен китап), видеодәресләр, слайдлар һәм һәр дәреснең иң мөһим этапларын билгеләгән методик ярдәмлек.




Мәктәптә укытыла торган фәннәр арасында әдәбият фәне үзенчәлекле урын алып тора. Ул белем бирү белән бергә шәхесне тәрбияләү, үстерү һәм тормышка әзерләү юнәлешендә дә зур мөмкинлекләргә ия. Әлеге мөмкинлекләр тиешле дәрәҗәдә файдаланылган очракта милли үзаңы югары, кеше күңелен тирәнтен аңлый, ситуацияне дөрес бәяләп мөнәсәбәтләр урнаштыра, үзенең фикерләрен язма рәвештә һәм телдән аңлаешлы, логик яктан дөрес формалаштырып башкаларга җиткерә, әйләнә-тирәне, андагы вакыйгаларны хис белән кабул итеп, билгеле бер пафос белән кабат тергезә алучы иҗади шәхес тәрбияләү мөмкин була. Әлегә кадәр кулланылышта булган дәреслекләребез телне яхшы белүче, әзерлекле укучыны күздә тота иде. Мәктәпләрдә атнасына 4–5 сәгать татар теле дәресләре укытылганда, татар телендә белем бирүче мәктәпләребез, гимназияләребез булганда кулланылышка куелганлыктан алар белән эшләү алымнары да, бурыч-максатлар да башкача иде.

Яңа әдәбият дәреслекләре, иң яңа таләпләр һәм мөмкинлекләргә нигезләнеп, туган телнең асылына төшендерү, аның мөмкинлекләрен ачу, бу телдә иркен аралашу һәм иҗат итү мөмкинлегенә ия булган шәхес тәрбияләүне күздә тота. Белем бирү өлкәсендә еш телгә алына торган «функциональ грамоталылык», «эмоциональ интеллект» төшенчәләре таләпләрен дә үзәккә куя.

«Туган (татар) телдәге әдәбият» предметы яңа предмет һәм ул хәзер үзендә ике юнәлешне берләштерә. Беренчедән, татар әдәбиятын фән буларак тәкъдим итә, чөнки ул – рус әдәбиятына өстәмә буларак укытыла торган «Родная литература» гына түгел, татарның язма мирасы, әдәби барышы, сәнгати үзенчәлекләре белән таныштыручы бердәнбер предмет. Икенчедән, туган телдәге әдәбият сүз сәнгатен милли хәзинә буларак, халкыбызның тарихы, традицияләре, милли фәлсәфәсе, холкы, инанулары, бөек шәхесләре белән бәйләп, укучыга җиткерүне дә максат итеп куя. Башкача әйткәндә, үз халкына тирән хөрмәт саклаган, аның дәвамчысы булырлык милли рухлы шәхес тәрбияләү бурычын да үз өстенә ала.

5 – 9 нчы сыйныфларда туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү башлангыч сыйныфларда алган белемнәрне тирәнәйтү, үстерүне, укучыларны татар халкының күп гасырлык әдәби, мәдәни мирасы белән таныштыруны күздә тота. Шул нигездә милли үзаңны үстерү, этник чыгышыңны аңлау, тарих, тел, мәдәният, дөньяга караш, менталитет, үз халкыңның фәлсәфи карашлары турында системалы белемнәр алу өчен шартлар тудыруны, әдәбиятны сәнгатьнең бер төре буларак кабул итүне, форма һәм эчтәлек бердәмлеге принципларына таянып аның асылын аңлауны, шәрехли алуны, анализлау күнекмәләрен үстерүне тәэмин итә.

5 – 7 нче сыйныфларда төп максат буларак әдәбиятның төр һәм жанр мәсьәләсен карау алга чыкты. Аерым алганда, 5 нче сыйныфта игътибар үзәгендә әдәби төрләр белән танышу тора. Аерым әсәрләр мисалында проза, лирика, драма үзенчәлекләре өйрәнелә. 6 нчы сыйныфта лирика, хикәя, повесть, лиро-эпик әсәрләрдә, драмада, фантастик һәм автобиографик характердагы әсәрләрдә образлылык тудыру алымнары карала. 7 нче сыйныфта укучылар хикәя, повесть, роман, драма һәм лиро-эпик әсәрләрнең жанр хасиятләрен өйрәнәләр. 8 нче сыйныфта әдәби әсәрдә сәнгати алымнарны тикшерәләр. Программа нигезендә, укучы 5 – 8 нче сыйныфларда әдәби әсәрләрне төрле яссылыкта өйрәнә, аларның авторлары белән таныша, ягъни әдәби барышны кабул итәргә әзерләнә. 9 нчы сыйныф материалы алган белемнәрне системалаштыруны күздә тота, әдәби барышка гомуми йомгак ясала. Ул тулысынча татар әдәбияты тарихына күзәтү ясый. Әдәби процессны халык тарихы һәм гомуми әдәби барыш белән бәйләнештә күзаллау мөмкинлеге тудыра. Сүз сәнгатенең кешенең рухи дөньясы белән тирәнтен керешкән төре булган әдәбиятны аңлап кабул итәргә өйрәтә.

Программага кертелгән әсәрләрне укучыга җиткерү дә аерым игътибар таләп итә. Бирелгән вакытның, сәгатьләр санының бик чикле булуы, өйрәнелә торган әсәрләрнең күләмен киметүне сорый. Әмма укучы укылган әсәрнең идеясен тулысынча аңласын, нәтиҗә ясасын өчен, андагы вакыйгаларның сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен бер җепкә тезеп кабул иткәндә яхшы. Шуны исәптә тотып әсәрләрдән өзек кенә түгел, ә кыскартылган әсәр рәвешендә тәкъдим итү кулай табылды. Өзек яки әсәрне кыскартып алу әсәрне өйрәнү максаты белән дә бәйле. Әйтик, билгеле бер сәнгати алымны (мәсәлән, портрет тудыру алымын) өйрәнгәндә, тулы әсәрне иңләү төп максат булмаска да мөмкин.

Дәреслектәге материал әдәби әсәрне өйрәнү текстны укып аңлау, эчтәлеге һәм төзелеше ягыннан бәя бирү кебек әдәбият фәне куйган таләпләрне генә түгел, аңа бәйле этномәдәни, тарихи күзаллау чикләрен киңәйтүне, атаклы шәхесләр белән таныштыру үрнәгендә тәрбия бирүне дә максат итеп куя. Дәреслекләрнең эчтәлеге бу максатка тулысынча тәңгәл килә. Андагы рәсемнәр милли яшәешебезне, гореф-гадәтләрне, традицияләрне ачыклауга мөмкинлек бирә (*дәреслекләрнең рәссамы Д. Нәүрүзова*).





Әдәби әсәрләргә махсус ясалган рәсемнәр дә, рәссамнарыбыз иҗат иткән картиналар һәм сәнгатьнең башка төренә караган иҗат эшләре дә аларның сүз сәнгате белән бәйләнешен ачыкларга, янәшә куеп өйрәнергә ярдәм итә.

Әйтик, Габдулла Тукайның «Шүрәле» поэмасын өйрәнү татар халкының күренекле шәхесләре Бакый Урманче, Фәрит Яруллин һәм татар опера сәнгате белән танышуга юл ача. «Шәхесләребез» рубрикасында әдипләребез генә түгел, мәдәният, сәнгать, тарих һәм башка өлкәләргә караган шәхесләр турында кыскача мәгълүмат урын ала.

«Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыз» рубрикасы әсәрләрдә чагылыш тапкан яшәешебезне киң колачлы шәрехләүгә мөмкинлек бирә. Биредә укучы өчен таныш булмаган төшенчәләргә тулы аңлатма табарга мөмкин. Анда элек кулланылышта булган *гөбе, сәке, өсәк, талир тәңкә, аяк чолгавы* кебек әйберләргә дә, тарихи чор белән бәйле күләмле төшенчәләргә дә урын бирелгән. Әйтик, *ТАССР, Аркадия, Швейцария бакчалары* һ.б. Бу укучыларның әсәр эчтәлеген аңлауга гына ярдәм итеп калмый, күзаллавын киңәйтә, фикерләвен тирәнәйтә.

Өстәмә мәгълүмат бирә торган мондый рубрикалар дәреслектә берничә. «Бу кызыклы» рубрикасы да күп кенә яңалыкны үз эченә ала.

Дәреслектә бирелгән QR-кодлар да материалны кызыклырак итә һәм баета. Укытучыга һәм укучыга өстәмә мәгълүматны табу җиңеләя.

*QR-код аша кереп, Татарстан Республикасына мөнәсәбәтле Бөек Ватан сугышы турындагы мәгълүматлар белән танышыгыз.*

https://tatfrontu.ru/

10–11 нче сыйныф дәреслекләре модульле системага корылган. Ике дәреслек алты зур теманы үз эченә ала. Темалар әдәбият предметын фән буларак кабул итү, теоретик нигезне ныгытудан тыш яшәеш кануннары, аларга тәэсир итүче факторлар, җәмгыять һәм шәхес арасындагы мөнәсәбәтләр, кешенең рухи кыйбласы, яшәү мәгънәсе кебек фәлсәфи тирәнлектәге уйланулар аша укучыга яшәешнең асылын аңларга, җәмгыятьтә үз урынын билгеләргә ярдәм итә.

Һәр тема кеше һәм шәхес төшенчәсенә бәйләп карала. Мәсәлән, 10 нчы сыйныфта «Кеше – иң югары кыйммәт», «Кеше һәм гаилә», «Милли холык һәм кеше» темалары, 11 нче сыйныфта «Кеше һәм җәмгыять», «Кеше һәм тарих», «Кеше һәм табигать» темалары билгеләнгән.

Әдәбият – тормыш мәктәбе. Иң элек ул кешенең хисләрен баета, янәшәдәгеләрнең рухи халәтен аңларга ярдәм итә, күңелендәгене башкаларга җиткерергә өйрәтә. Сүзлек байлыгын арттырып, телен баетып кына калмый, укучыны халкыбызның рухи мирасы, мәдәнияте, тарихы белән бәйли. Укучы һәр халыкның милли үзенчәлекләре булуын аңлаган хәлдә, татар халкының затлы сыйфатлары, олы тарихы белән горурлана, башкалар алдында аны дәлилләргә өйрәнә.

Димәк, хәзерге шартларда әдәбият дәресләре – укучыларыбызга милли тәрбия бирүнең төп формасы. Белемнәрне җиңел үзләштерү һәм хәтердә саклау алымнарына нигезләнгән бу дәреслекләр укучыга һәм укытучыга игелекле хезмәт итәр дип ышанабыз.

5



**Гөлнара ҺАДИЕВА,**

ТР Мәгарифне үстерү институтының
татар теле һәм әдәбияты кафедрасы
өлкән укытучысы

# ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕ ӨЧЕН ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАР

Соңгы елларда мәгариф системасында үзгәрешләр «Туган телдәге (татар) әдәбият» предметы буенча сәгать саны кимүгә китерде. Аз вакыт эчендә татар әдәбияты турында күзаллау булдыру, татар язучылары һәм шагыйрьләренең тормыш юлы, иҗаты турында белемнәр формалаштыру татар теле һәм әдәбияты укытучысының бурычы булып кала бирә.

Тәкъдим ителгән дидактик материаллар татар теле һәм әдәбияты укытучысының хезмәтен җиңеләйтү, аңа методик ярдәм күрсәтү максатыннан төзелде. Дидактик материаллар дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә эш дәфтәре, эш бите буларак та кулланыла ала. Әдәбият дәресләрендә язучының тормыш юлын һәм иҗатын кабатлау, ныгыту һәм йомгаклау максатыннан куллану да нәтиҗәле булачак. Шулай ук дидактик материаллар текст белән эшләүгә юнәлтелгән уку грамоталылыгын үстерү максатыннан да кулланыла ала.

Дидактик материаллар төп гомуми белем бирү оешмаларында туган (татар) телендә сөйләшүче 5 нче сыйныф укучыларына төзелгән дәреслек буенча *(авторлары: Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М.)* Федераль эш программасына нигезләнеп төзелде.

Бүген сезгә Габдулла Тукайның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган материалны тәкъдим итәбез. Алдагы саннарда башка язучыларның тормыш юлы һәм иҗатына тукталырбыз.



Минем исемем ________________
Туган урыным________________
Яшәгән елларым_______________
Минем профессиям____________
Минем яраткан шөгыльләрем______
Минем биографиядән фактлар______

**1.** Авторы билгеле әкиятләр ул ________________________ дип атала.

**2.** «Шүрәле» нинди әкият төренә карый?___________________________

**3.** «Шүрәле» әкиятен укыганда нинди төсләр күрәсең, нинди тавышлар ишетәсең, нинди исләр сизәсең? Таблицаны тутыр.

| Төсләр | Исләр | Тавышлар |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

**4.** Шүрәле образына синквейн төзе.
*Кем?* ( 1 сүз)______________________
*Нинди?* (2 сүз)_____________________
*Нишли?* (3 сүз) ____________________
*Герой турында нәрсә уйлыйсың?* (4 сүз)____________________________
*Беренче юлга синоним* (1 сүз) ________

**5.** Эзлеклелекне дөрес итеп урнаштыр.

☐ Кырлай урманнары

☐ Шүрәле һәм Былтырның уены

☐ Кырлай авылы

☐ Егет һәм Шүрәле

☐ Кырлай авылы турында түгел

**6.** «Шүрәле» әкиятенең төп фикере ___

______________________________

**7.** Беренче татар балеты «Шүрәле»нең авторы ______________________

**8.** «Шүрәле» поэмасы буенча график хезмәтләр авторы ______________

**9.** «Шүрәле» әсәре буенча сүзләрне аңлат һәм глоссарийны дәвам ит.

1. Хәтфә – ____________________
2. Инеш – ____________________
3. Хозур – ____________________
4. Җиһан – ____________________
5. Килешсез – __________________
6. ____________________________
7. ____________________________

**10.** «Пар ат» шигырендә нинди вакыйга сурәтләнә? ______________

**11.** Казан образына характеристика бир.



______________________________

______________________________

**12.** «Пар ат» шигырендәге юлларда төшеп калган сүзләрне яз.

*«И Казан!* ______ *Казан!* _____ *Казан!*
_________ *Казан!»*

Шигырьдә ничә строфа? ___________

Һәр строфа ничә юлдан тора? ________

**13.** «Пар ат» шигырендә автор нинди хисләрне сурәтли? Тойгы, хисләрне белдерә торган сыйфатларны сайлап ал.

| | |
|---|---|
| Тыныч | Курку |
| Шатлыклы | Шаян |
| Борчулы | Тантаналы |
| Моңсу | Күтәренке |

**14.** «Пар ат» шигыре буенча таблицаны тутыр.

| **Хис, тойгы** | **Нинди сүз белән бирелә?** |
|---|---|
| Өмет | |
| Сагыш | |
| Борчылу | |
| Киләчәккә ышаныч | |

**15.** Габдулла Тукай чынбарлыкта Казанга кайчан һәм нинди транспорт белән килгән?



**16.** Сүзләрне аңлат.

Хикмәт – ______________________

Гыйфран – _____________________

Мәгърифәт – ___________________

Хур – _________________________

**17.** Рәсемнең авторын яз.



______________________________

**18.** «Пар ат» шигырендә образларны санап кит. ____________________

**19.** Билгеләмәләрне дәвам ит.

Лирика ул – ____________________

Шигырь ул – ___________________

**20.** Әдәби әсәрдә лирик герой нинди хисләр кичерә ала? Стикер астына хисләрне язып чык.



6



**Рәмзия ГАБДЕЛВӘЛИЕВА,**

Казандагы 175 нче гимназиянең
I квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

# УКУЧЫЛАРДА ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫК ФОРМАЛАШТЫРУ БУЕНЧА КОМЛЕКСЛЫ БИРЕМНӘР

ҺӨНӘРИ ТӘҖРИБӘ

**Тәкъдим ителгән текст эше укучыларның уку грамоталылыгын булдыруга юнәлтелгән. Әлеге эшчәнлек өчен өч төрле текст алынды. Аларның төрлелегеннән чыгып, һәр текстка мәгълүматны табу, интерпретацияләү, бәяләү төренә караган биремнәр китерелде. Биремнәрнең һәрберсе предмет, метапредмет нәтиҗәсен булдыруны күз алдында тота.**

**Текстның исеме:** Фәнис Яруллин «Иң бәхетле көн».

**Форматы (тоташ/тоташ булмаган/кушма/катнаш):** тоташ.

**1. Текстны укы.**

Ялгандырмы-чындырмы, булгандырмы-юктырмы, авылда түгел, шәһәрдә шушы безнең көннәрдә яшәгән, ди, бер юаш малай. Бик оялчан, бик юаш булганга, аны малайлар дус итмәгән, кызлар иш итмәгән. Ул, килеп, уенга кушылса, читкә сибелгәннәр, сүз башласа, егыла-егыла көлгәннәр... Юаш малайның моңа бик-бик хәтере калган, әмма үзен рәнҗетүчеләргә каршы чыгарга кыюлыгы җитмәгән. Чөнки ул кешеләрне рәнҗетүдән бик-бик курка торган булган. Таң артыннан таңнар аткан, җилләр искән, сулар аккан. Ә бу вакыт эчендә ишегалды малайлары бер-берләре белән утыз тапкыр ачуланышырга, кырык тапкыр дуслашырга өлгергәннәр, тик әлеге юаш малай гына үзенә иптәш таба алмаган. Көннәрнең берендә ишегалдының усал малайлары, череллдек кызлары уйный-уйный арып өйләренә таралышкач, күктә йолдызлар кабынгач, болытларны аралап, ай калыккач, бөркет җанлы юаш малай чыккан да җепшек кардан бик матур итеп Кар кызы ясап куйган. «Без синең белән мәңге дуслар булырбыз, бергә-бергә тау шуарбыз, тәгәри-тәгәри уйнарбыз, яме», – дигән ул Кар кызына.

– Мин риза, – дигән Кар кызы. Һәм алар җитәкләшеп, тауга менеп киткәннәр. Итекләрен чана иткәннәр. Чаналарына төнге җилләрне җиккәннәр. Егылсалар, бер-берсен тартып торгызганнар, арысалар, иңгә-иң куеп ял иткәннәр, күктәге йолдызларга карап сокланганнар. Юк кына нәрсәдән дә кызык табып, тәгәри-тәгәри көлгәннәр. Шатлыктан күңелләре тулып ташыса – җырлап җибәргәннәр. Куеннарына суык кереп, тәннәрен чеметкәли башласа – рәхәтләнеп биегәннәр.

– Их! – дигән юаш малай, хискә бирелеп. – Дөньяда дустың булу нинди рәхәт!

– Әйе, – дигән Кар кызы, – синең кебек батыр малай белән дус булуыма мин бик шат.

– Юк шул, – дип кире каккан малай аны, – мин батыр түгел.

– Син батыр! – дигән Кар кызы.

– Чөнки син, кара төннән курыкмыйча, берүзең урамга чыктың. Аннары, әле генә минем күзләремә карап: «Мин батыр түгел», – дип әйтә алдың. Үзеңә карата мондый сүзне әйтер өчен дә, батырлык кирәк.

Шушы минуттан башлап, юаш малай бернидән дә курыкмый башлаган.

– Әйдә, синең белән шәһәр әйләнәбез, – дигән Кар кызына.

– Әйдә, минем төнге шәһәрне бик-бик күрәсем килә.

...Төнге шәһәр буйлап алар озак йөргәннәр. Шаярганнар, көлгәннәр. Йөреп туйгач, иңгә-иң куеп, сүзсез генә утырганнар.

– Бәхетле төн үтеп тә китте! – дигән малай, көрсенеп. – Яңадан бервакытта да мин болай бәхетле булалмам инде.

– Булырсың, – дигән Кар кызы, – чөнки синең күңелең бай. Ә күңел байлыгы – зур бәхет ул. Һәм, чыннан да, шушы көннән башлап, бөркет җанлы юаш малай батырларның батырына әйләнгән. Көчсезләрне рәнҗетсәләр, яклашыр өчен, араларына атылып кергән, уенда иң беренче үзе башлап йөргән. Әти-әниләре: «Безнең малаебызга ни булды соң?» – дип сокланып та,

аптырап та карап куялар икән. Ә бөркет җанлы юаш малай, үзенең тугры дусты Кар кызына тәрәзә аша күз кысып: «Рәхмәт, дустым, син мине көчлелегемә, үземнең бүтәннәрдән ким түгеллегемә ышандырдың. Мин бик-бик бәхетле, чөнки синең кебек әйбәт дусты булган кеше бәхетсез дә, кыюсыз да, куркак та була алмый», – дип эндәшә икән.

**Биремнәр.**

***Мәгълүматны табу:***

1. Кар кызына хас сыйфатларны текстан табыгыз.
2. Малайның батырлыгы турында Кар кызы әйткән сүзләрне табып укыгыз.
3. Малай үзен бик бәхетле саный. Шул юлларны табып укыгыз.

| Раслау | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| Юаш малайның дуслары булмаган. | | |
| Кар кызы – чын дус. | | |
| Малай бернәрсәдән дә курыкмый башлаган. | | |
| Малай җепшек кардан Кар бабай ясаган. | | |
| Малайның төнге шәһәрне күрәсе килгән. | | |
| Иртәнге шәһәр буйлап алар озак йөргәннәр. | | |
| Малай җепшек кардан бик матур итеп Кар кызы ясап куйган. | | |
| Малай, кара төннән курыкмыйча, берүзе урамга чыккан. | | |



Рәсемдә кемнәр сурәтләнгән? Рәсемгә карап, әсәрдә сөйләнелә торган нинди сыйфатны ачыкларга була?

Малайларны чын дуслар дип әйтеп буламы? Ни өчен?

***Мәгълүматны интерпретацияләү:***

1. Әсәрнең төп идеясен әйтегез.
2. Ни өчен малай Кар кызы белән дуслашкан?
3. Хикәядә бирелгән вакыйгалар малайның моңарчы күренмәгән нинди сыйфатларын ачып бирә? Малайга характеристика бирегез.
4. «Чын дус» төшенчәсен сез ничек аңлыйсыз? Фикерегезне языгыз.

***Бәяләү:***

1. Сез ничек уйлыйсыз, Кар кызы яхшы дусмы?
2. Дуслар нинди булырга тиеш?
3. Әсәр сездә нинди хисләр уятты? Шул турыда фикерегезне кыскача языгыз.

**2. Текстның исеме:** Сашаның дуслары.

**Форматы (тоташ/тоташ булмаган/кушма/катнаш):** тоташ булмаган.

**Текстны укы һәм биремнәрне эшлә:**

Сашаның дуслары күп. Ләкин аның иң якын дуслары икәү генә. Алар – Валера белән Азат. Дуслар гел бергә йөри: мәктәпкә дә, спорт түгәрәгенә дә, китапханәгә дә. Алар бергә уйныйлар, дәрес әзерлиләр. Туган көннәрен, бәйрәмнәрне бергә үткәрәләр.

Бервакыт Сашаның әбисе авырды. Аның башы авыртты.

– Улым, даруханәдән баш даруы алып кайт әле, – диде әбисе Сашага.

Саша акча алды һәм даруханәгә йөгерде. Ләкин даруханәдә акчасын тапмады. Хәзер нишләргә? Саша кире өйгә кайтырга уйлады.

Юлда дусларын күрде һәм ярдәм сорады. Валераның акчасы бар, ләкин ул аны Сашага бирмәде. «Үземә кирәк», – диде. Ә Азат: «Мин хәзер», – диде дә өенә йөгерде. Ул яңа уен алырга акча җыйган иде. Шул акчаны дустына бирде.

Икенче көнне Валера Сашаны уйнарга чакырды. Ләкин Сашаның чыгасы килмәде.

***Мәгълүматны табу:***

1. Сашаның ничә дусты бар? Аларның исемнәре ничек? Тексттан табып күрсәт.
2. Дуслар вакытларын бергә ничек үткәрәләр?
3. Сезнеңчә, Сашаның чын дусты кем? Ни өчен?

4. Сашаның әбисе турында нинди мәгълүмат бирелә? Ул нишләгән?
5. Ни өчен Сашаның Валера янына чыгасы килми?
6. Дуслар вакытларын бергә ничек үткәрәләр?

***Мәгълүматны интерпретацияләү:***
1. Ни өчен Валера акча бирмәгән?
2. Бу малайларга характеристика бир.
3. Әсәрнең төп фикере ничек дип уйлыйсың?
4. Кайсы мәкаль текстка туры килми?
А) Чын дуслык – зур байлык.
Б) Аз сөйлә, күп эшлә.
В) Дустың булмаса – тап, тапсаң – сакла.
Г) Дустың үзеңнән яхшырак булсын.

***Бәяләү:***
1. Дуслар бер-берсенә нинди мөнәсәбәттә булырга тиеш? Фикерләгез.
2. Әсәр синдә нинди хисләр уятты?
3. Текстка сез нинди исем куяр идегез? Җавабыгызны дәлилләгез.
4. Сез Азат белән Валера урынында нишләр идегез? Җавабыңны дәлиллә.
5. Азат нинди яхшылык эшли? Фикерлә.
6. Валера Сашаны урамга чакырды. Ул чыкмады. Малай дөрес эшләдеме?

**3. Текстның исеме:** Рөстәм Закир «Дуслык нурлары» шигыре.
**Форматы (тоташ/тоташ булмаган/кушма/катнаш):** тоташ.

**Шигырьне укы һәм биремнәрне эшлә:**
*Дуслык – иң зур байлык безгә,*
*Ташламый ул беркемне дә.*
*Йөрәкләрне җылыта ул,*
*Якты юллар сала көндә.*
*Кыен чакта дуслар белән,*
*Авырлыклар артта калыр.*
*Һәрбер сүздә ышаныч бар,*
*Күңелләрне тынычландырыр.*
*Бергә көлеп, бергә елап*
*Үтәбез без тормышны.*
*Дуслык җебе нык бәйли,*
*Аералмый дөньяны.*
*Дуссыз тормыш – буш бер җирлек,*
*Җаннар өши, күңел тына.*
*Дуслар кирәк һәрчак безгә,*
*Күңел күгебез яктыра.*

***Мәгълүматны табу:***
1. Шигырьдә нәрсә турында сүз бара?
2. Дуслык нәрсә ул? Тексттан шул фикерләрне табып әйт.
3. Бирелгән вариантларның кайсысы дөрес?
а) дуслык – байлык;
б) дуслык – ышаныч;
в) дуслык – буш бер җирлек.
4. Дуслыкның көче нәрсәдә?
5. Чын дуслык кайчан беленә? Шул юлларны табыгыз.

***Мәгълүматны интерпретацияләү:***
1. Ни өчен шигырь «Дуслык нурлары» дип атала?
2. *Дуслык* сүзенең мәгънәсен сүзлектән кара.
3. Ни өчен дуслык йөрәкне җылыта?
4. Кешегә дуслар ни өчен кирәк?
5. Дуслык җебе бәйли аламы?

***Бәяләү:***
1. Шигырь сездә нинди хисләр уятты?
2. Сезнең дусларыгыз бармы?
3. Авторның сүзләре белән килешәсезме? Фикерегезне дәлилләгез.
4. Үрнәк буенча дустыгыз турында языгыз.

***Минем дустым***

Мин сезгә ___________ турында сөйлим. Аның исеме ___________. Без аның белән ____________ дуслаштык. Без бик __________.
Дустым_____________, _____________, _____________. Без бергә _____________, _________________. Мин үземнең дустымны бик _______________________ һәм __________________. Минемчә, дуслык – ул ________________________________

7



**Миңлегөл СУБАЕВА,**

Казан медицина көллияте укытучысы

# ҺӨНӘРИ КОМПЕТЕНТЛЫК ҺӘМ ӘХЛАК СЫЙФАТЛАРЫ ТӘРБИЯЛӘҮДӘ «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР» ӘСӘРЕНЕҢ РОЛЕ

ҺӨНӘРИ ТӘҖРИБӘ

Бердәм дәүләт стандартларының нигезендә рухи-әхлакый һәм иҗтимагый кыйммәтләр, кешене һәрьяклап шәхес итеп формалаштыру концепциясе тора. Ул бик күп мәгънә сыйдырган төшенчәләр үз эченә укучының белем дәрәҗәсе белән бергәттән, тел культурасын яки коммуникатив осталыкны да ала. Белем һәм тәрбия бирүдә иң әһәмиятле урынны әдәбият, әдәби әсәрләр алып тора. Укучының рухи үсешенә, сөйләм культурасына, тел, фикер байлыгына шулар зур йогынты ясый. Әйе, әдәп-әдәбият – тамырдаш сүзләр. «Әхлак берлә әдәбият бергә булырлар, бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлак шул рәвештә булыр», – дип язып калдырган безгә Риза Фәхреддин.

> **Дөрестән дә, бер техник чара, иң яңа буын компьютер да, ясалма интеллект та әдәби әсәрне, аның милли тирәнлеген укучыга җиткерә, алыштыра алмый.**

Киләчәктә кулларында кеше гомерләре, сәламәтлеге булачак медицина уку йорты студентларына да иң элек әдәби сөйләм теле, коммуникатив компетенция зарури. Моның өчен аларны медицина темаларын чагылдырган матур әдәбият үрнәкләре белән күбрәк таныштыру кирәк. Әхлак, аралашу педагогикасын, сөйләм телен алар шулар аша баетып кына калмый, деонтология нигезләрен дә үзләштерә. Сүз – медицина хезмәткәрләре өчен аралашу коралы. Бу фикер халык авыз иҗатында да раслана. «Җылы сүз – җан азыгы», «Сүз – яралый, сүз – дәвалый», «Күңелне дәваламый торып, җанны дәвалап булмый» һ.б.

Чын табиб, медицина хезмәткәре үз вазифасын үтәүне нәкъ әнә шуннан башлый. Иң элек җылы сүз белән авыруда савыгуга өмет уята. Озак еллар медицина өлкәсендә укыту тәҗрибәмдә тел культурасын үстерү белән бергәттән, медицина әхлагы формалаштыру максатыннан, әдәби үрнәкләрне беренче урынга куеп эш итәм. Шулар арасыннан Гадел Кутуйның ике әсәре аеруча үтемле. Аның берсе – «Вөҗдан газабы» әсәре утызынчы елларда ук татар әдәбиятында медицина әхлагын яктырткан, икенчесе – «Тапшырылмаган хатлар» әсәре мәхәббәт, гаилә, гаилә кору темаларын күтәреп чыга. 1935 елда ук язылган «Тапшырылмаган хатлар»ы Җир шарында иң күп таралган дүрт татар китабының беренчесе була, бик тиз арада тәрҗемә ителеп дөнья буйлап та тарала. Аның шулай тиз арада укучыда кызыксыну уятып, тарала алуының серен тәҗрибәле укытучы яхшы аңлый. Дөрестән дә, әсәрне укырга тәкъдим итү мизгеленнән үк укучыда китапны тизрәк укып чыгу теләге көчле булуын сизеп үк аласың. Дәрес өчен бу – мөһим момент. Укытучы монда алдагы дәреснең уңышлы узасын фаразлап ук куя. Китапның исемен ишетүгә үк, укучыда сорау, кызыксыну туа, мотивация көчле. Шул ук вакытта аның хатлар рәвешендә, эпистоляр жанрда язылуы да укучыны тиз җәлеп итә. Бу хатларда бирелгән беренче ярату кичерешләре, хисләрнең нечкә төсмерләре, аларның үз күңелендә беренче мәхәббәт бөреләнгән, уянган чакта тәэсир көчен тагын да арттыра. Шуны да әйтергә кирәк: язучының яшьләр психологиясенең үзенчәлекле якларын аңлап, психологларча оста эш итүен дә күрәсең. Бу гаҗәп түгел, чөнки Гадел Кутуй үзе дә, институт бетергәннән соң, Казан авиация техникумында укытучы булып эшләп ала. Укытучы – практик психолог.

Актуальләштерү өлешеннән үк кызыксыну зур булганга, дәресләр бик җанлы бара. Бу халәтне анализлау,

рефлексия өлешенә кадәр шулай эшлекле темпта, балалар йөзендәге ялкынны сүндерми йомгаклау өчен укытучыдан бик күп тырышлык сорала. Повестьны укып чыкканнан соң, укытучының проблемалы сораулары белән башланган дискуссия, бәхәс этабы – дәресемнең иң кызыклы, мавыктыргыч моменты. Яшьлек фикерләр көрәшенә омтылучан, дөреслек, хакыйкатьне эзли. Монда үрелеп барган тормыш вакыйгалары һәркемне уйланырга мәҗбүр итәрлек. Анализлау өлешендә интерактив тактада креатив уйлау сәләтен үстерүгә юнәлдерелгән биремнәр эшләтеп алу да нәтиҗәле була.

Биремнәрне рефлексия өлешендә дә эшләтү яхшы.

Мәсәлән, мәхәббәтне ... нәрсәгә охшатып була, чөнки ул ... , ни өчен шулай уйлыйсың ...

Гаилә, хыял, киләчәк, хыянәт һәм башка сүзләр. *(Соңыннан укучылар фикерне дәлилли, бер-берсе белән чагыштыра.)* Бу күнегү барышында карашлар төрле. Әлеге биремдә, җавапларның язучы фикере белән туры килү-килмәвен дә билгелиләр. Креатив фикерләр дә чагылып китә. Бәхетле гаиләдә тәрбияләнгән баланың җавабы башкачарак.

Шулай ук интерактив тактада төрле ситуатив күнегүләр бирү, чишелешен, җавапларын эзләтү логик фикерләү сәләтен үстерү максатыннан бик отышлы. Студентлар шулар аша үз-үзләрен тәрбияли. Һәркемгә үзе, гаиләсендәге мөнәсәбәтләр турында уйланырга да зур мөмкинчелек ачыла.

Укытучы үз сораулары белән әңгәмәне тагы да баета ала.

Һөнәри юнәлештәге текстлар, тестлар белән эшләү, квест уены, объектив анализлау, үз карашларын булдыру, һөнәр асылына төшенүгә шулай ярдәм итә. Мөстәкыйль эшләр, хатлар яздыру, фәнни эзләнү-проект эшләре, рефератлар белән чыгышлар эшләтү һәм башка төрле алымнар куллану да көтелмәгән нәтиҗә бирә. Әсәр укучыга гаилә кыйммәтләрен җиткерү, тормыш итәргә әзерләү, җаваплылык тәрбияләү ягыннан безгә күп мөмкинлекләр бирә. Әйе, бу тема – бүгенге көндә гомумкешелек алдында торган иң төп проблемаларның берсе. Моны яңача укыту программаларында да күрәбез. Монда илаһи сафлык, намус төшенчәсе дә, гыйбрәт алырлык сюжетлар да җитәрлек. Үз тәҗрибәмдә бу теманы үткән вакытта, йомгак өлешен гаилә кору турындагы җыр белән тәмамлыйм. Җыр – үзе куәтле чара, рухи кыйммәт өсти, әйтеп бетергесез тәэсир көченә ия. Укучылар бу вакытта эстетик ләззәт кичерә. Гаилә учагын сүндерми саклау серләренә җыр аша да төшенә. Җирдә яшәү, тормыш итү мәгънәсе – гаилә. Авторы үзем, көйне язучы күренекле композитор Альфред Якшимбетов язды. Беренче башкаручы – халык артисты Резеда Шәрәфиева. Анда түбәндәге юллар бар: «Мәхәббәткә тугры булса йөрәк, сүнмәс янар кабызган учак».

Дәрес темасын аңлау, үзләштерүгә юнәлтелгән бу чараларның барысы да укучы күңелендә эз калдырса, димәк, укытучы куйган максатына ирешкән.

Һөнәри компетентлык һәм әхлак сыйфатлары тәрбияләүдә «Тапшырылмаган хатлар» әсәренең әһәмияте һичшиксез зур. Повесть үзенең актуальлеген югалтмас, укытучы өчен тәҗрибәсен баеткан, мөкатдәс әсәр булып калыр.

**Укыту процессын нәтиҗәле итү өчен бик күп көч куярга кирәк. Шулай булганда гына шәхесне тулы һәм мәгънәле, якты кеше итеп тәрбияли алырбыз.**

8



**Рания ЗАКИРОВА,**

Казандагы 174 нче гимназиянең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы



**Миләүшә ХӨСНЕТДИНОВА,**

Казандагы 174 нче гимназиянең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

# «СӘЛАМ ИЛЕНӘ» СӘЯХӘТ

(«Сәлам» УМКсы белән эшләүчеләр өчен мюзикл. 3 нче сыйныф укучылары белән күрсәтелә)

ҺӨНӘРИ ТӘҖРИБӘ

**Уен – балалар эшчәнлегенең төп төре. Уен вакытында туган шатлыклы кичерешләр уенны көчле тәрбия чарасына әверелдерә, балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен ача, теләк-омтылышларын берләштерә, мөстәкыйль эш итәргә, үз уйларын гамәлгә ашырырга, дөньяны танырга өйрәтә.**

**Татар теленә өйрәтүдә җырлы-биюле уеннарның әһәмияте**

Балалар күңелле, хәрәкәтле, җырлы-биюле уеннар ярата. Шуңа да уенны текстның эчтәлегенә, уен кагыйдәләренең һәм хәрәкәтләрнең катлаулыгына карап, «гадидән катлаулыга» дигән принцип буенча оештырабыз һәм балаларның психологик үзенчәлекләрен, яшь аермалыкларын истә тотып башкарабыз.

Музыка ритмына төгәл хәрәкәтләр ясау, уенның сүзләрен сәнгатьле итеп әйтү, төрле образлар башкару – болар барысы да балаларда канәгатьләнү хисе уята, сөйләм телен үстерергә, матурлыкны аңларга ярдәм итә. Алай гына да түгел, алар нәниләрдә дуслык, иптәшлек, гаделлек кебек сыйфатлар тәрбияли. Уен вакытында балаларның ишетү мөмкинлекләре ачыла, мөстәкыйльлекләре арта, оештыру сәләтләре үсә. Кулга-кул тотышып, берәр көйгә күмәк җырлап, түгәрәк тирәли әйләнеп йөрү балаларда эстетик ләззәт уята, ритмик хәрәкәт буларак күңелле ял бирә.

Уеннарның эчтәлеген балалар өчен гади һәм аңлаешлы, шул ук вакытта кызыклы һәм мавыктыргыч итәргә тырышабыз. Катлаулырак эчтәлекле уеннарны гадиләштерәбез, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап яраклаштырабыз.

Җырлы-биюле уеннарның максаты – балаларда җыр эчтәлегенә һәм музыканың характерына туры китереп, хәрәкәт итү күнекмәләрен формалаштыру; җыр һәм биюләрне мөстәкыйль рәвештә башкарырга омтылыш булдыру; халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыру һәм аларга карата мәхәббәт тәрбияләү.

Уен вакытында балалар көй ритмына хәрәкәтләнә, дәртләнеп җырлый, бии. Уеннар музыкаль авазларны тоемларга ярдәм итә, бала күңелендә нәфислек, матурлык тойгысы уята.

Иң әһәмиятлесе: уеннар аңлаешлы һәм мавыктыргыч. Җырлы-биюле уеннарны кыз балалар бигрәк тә яратып уйный. Музыка тавышына балалар хәрәкәтләрне тизрәк үзләштерә. Шуңа күрә дә балаларның уңай эмоциональ халәтен саклап, шат күңел белән уйнауларына ирешү, аларны тыныч һәм мөстәкыйль уйнарга күнектерү, хәрәкәтләрне матур, нәфис итеп башкарырга өйрәтү өлкәннәрнең бурычы булып тора.

Уен вакытында текстка, җырга кушылып, аның кагыйдәләрен үтәп, йә булмаса ниндидер роль башкарып, бала үз көченә ышанырга, эшләгән эшенә бәя бирергә өйрәнә, аңарда башкаларның хәленә керә белү, ярдәмләшү, игътибарлылык кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә.

**Сәхнә бизәлеше:** сәхнәнең уң ягында – өй, агачлар, чәчәкләр. Өйнең кырыенда балалар уенчыклары өелеп тора. Сәхнәнең икенче ягында парталар, такта тора. *(Мәктәп, сыйныф күренеше).*

***1 нче пәрдә***

Укучылар тезелешеп баса. *(2 рәттә, 1 нче рәт сәхнә астында, икенче рәт сәхнәдә.)* «Сәлам»УМКсының 1 нче сыйныфында «Сәлам» темасы буенча өйрәнелгән җыр башкарыла.

*Сәлам-сәлам! Хәерле иртә!*
*Сәлам-сәлам! Хәерле иртә!*
*Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!*
*Сау бул, дустым! Хәерле көн!*

*Сәлам-сәлам! Хәерле көн!*
*Сәлам-сәлам! Хәерле көн!*
*Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!*
*Сау бул, дустым! Хәерле көн!*

Кыңгырау шалтырый, беренче рәт укучылары сәхнә артына кереп китә. Икенче рәт укучылары парта артына кереп утыра.

Шул вакытта укытучы ролендә 3 нче сыйныф укучысы керә.

– Исәнмесез, укучылар!
– Исәнмесез, укытучы апа!
– Ә сез ничәнче сыйныф укучылары?
– Без өченче сыйныф укучылары.
– Ә бу ничәнче мәктәп?
– 174 нче мәктәп.
– Бигрәк мәктәбегез зур, матур.

«Сәлам» УМКсының 1 нче сыйныфында «Мәктәп» темасы буенча өйрәнелгән җыр башкарыла. *(Укучылар предметларны күрсәтеп җырлый.)*

*Безнең мәктәп бик матур,*
*Сыйныфлар якты һәм зур.*
*Урындык, өстәл, такта –*
*Барысы да урынында.*
*Безнең сыйныф бик матур,*
*Өстәл, урындыклар зур.*
*Көндәлек, дәфтәр, китап*
*Дәрескә әзер һәрчак!*
*Безнең китаплар матур,*
*Рәсемнәр кызык һәм зур.*
*Безгә мәктәптә рәхәт.*
*Укытучыбызга рәхмәт!*

– Шәп, булдырасыз! Ә дәрестә кемнәр юк?
– Настя монда.
– Алсу монда.
– Артур монда.
– Ваня, Даша, Саша, Маша юк.
– Дәрестә 4 укучы юк! *(Укытучы хәйран кала.)*

Кыңгырау шалтырый, укучылар өйләренә таралыша.

***2 нче пәрдә***

Дәрескә бармаган укучылар урманда рәхәтләнеп уйнап йөри. «Сәлам» УМКсының 1 нче сыйныфында «Саннар» темасы буенча өйрәнелгән җыр башкарыла.

*(Тиен киемнәре кигән 5 укучы чыга. Агачлар арасында уйнап йөриләр һәм берәм-берәм агач артына качалар.)*

*Биш тиен агачта сикерә.*
*Биш тиен чикләвек яшерә.*
*Бер тиен качты куышка.*
*Ничә тиен калды агачта?*
*Бер, ике, өч, дүрт!*
*Биш тиен агачта сикерә.*
*Биш тиен чикләвек яшерә.*
*Бер тиен качты куышка.*
*Ничә тиен калды агачта?*
*Бер, ике, өч!*
*Биш тиен агачта сикерә.*
*Биш тиен чикләвек яшерә.*
*Бер тиен качты куышка.*
*Ничә тиен калды агачта?*
*Бер, ике!*
*Биш тиен агачта сикерә.*
*Биш тиен чикләвек яшерә.*
*Бер тиен качты куышка.*
*Ничә тиен калды агачта?*
*Бер!*
*Биш тиен агачта сикерә.*
*Биш тиен чикләвек яшерә.*
*Бер тиен качты куышка.*
*Ничә тиен калды агачта?*
*Биш! 1, 2, 3, 4, 5!*
*Тиеннәр куышта,*
*Ә куыш – агачта!*

«Сәлам» УМКсының 1 нче сыйныфында «Төсләр» темасы буенча өйрәнелгән җыр башкарыла. *(Күбәләк, чикерткә, бал корты, фатыйма (камка) булып киенгән укучылар биеп чыга. Күбәләк кулында кәгазьдән ясалган зәңгәр чәчәк, чикерткәдә яшел чәчәк, бал кортында сары чәчәк, фатыймада кызыл чәчәк. Агачлар арасында матур итеп биеп, уйнап, качып йөриләр. Һәм чәчәкләр астына кереп качалар. Үзләре турында җырлаганда чыгалар.)*

*Качышлы уйный алан.*
*– Син качасың, мин табам!*
*– Күбәләк, син кайда?*
*– Зәңгәр чәчәк астында!*

*Качышлы уйный алан.*
*– Син качасың, мин табам!*
*– Чикерткә, син кайда?*
*– Яшел чәчәк астында!*
*Качышлы уйный алан.*
*– Син качасың, мин табам!*
*– Бал корты, син кайда?*
*– Сары чәчәк астында!*
*Качышлы уйный алан.*
*– Син качасың, мин табам!*
*– Камка, ә син кайда?*
*– Кызыл чәчәк астында!*

***3 нче пәрдә***

Аланлыкта кыз лейка белән чәчәкләргә су сибеп йөри һәм бабайны чакыра. «Сәлам» УМКсының 1 нче сыйныфында «Гаилә» темасы буенча өйрәнелгән җыр башкарыла.

*(Бабай, әби, әти, әни, бәби булып киенгән укучылар чыгалар. Хәрәкәтләр ясап, сәламләп берсе артыннан берсе чыга.)*

*– Бабай бармак, бабай бармак.*
*Син кайда?*
*– Мин монда, мин монда! Сәлам сиңа!*
*– Әби бармак, әби бармак.*
*Син кайда?*
*– Мин монда, мин монда! Сәлам сиңа!*
*– Әти бармак, әти бармак.*
*Син кайда?*
*– Мин монда, мин монда! Сәлам сиңа!*
*– Әни бармак, әни бармак.*
*Син кайда?*
*– Мин монда, мин монда! Сәлам сиңа!*
*– Бәби бармак, бәби бармак.*
*Син кайда?*
*– Мин монда, мин монда! Сәлам сиңа!*

Гаилә чыгып беткәч, татарча бию көе уйнала. Матур итеп бииләр һәм сәхнәдән әкренләп чыгып китәләр. Ә бәби, сәхнәдәге уенчыкларны күреп, шулар белән уйнап кала.

«Сәлам» УМКсының 1 нче сыйныфында «Уенчыклар» темасы буенча өйрәнелгән җыр башкарыла. Барабан уйнаучы малай артыннан тезелешеп, уенчыклар күтәреп, бәби янына уйнарга чыгалар.

*Там, там, там, там!*
*Мин уйнарга яратам!*
*Бам, бам, бам, бам!*
*Мин барабанга кагам!*
*Там, там, там, там!*
*Мин уйнарга яратам!*
*Һап, һап, һап, һап!*
*Мин сиңа тупны атам!*
*Там, там, там, там!*
*Мин уйнарга яратам!*
*Оч, оч, оч, оч!*
*Мин очкычны очырам!*
*Там, там, там, там!*
*Мин уйнарга яратам!*
*А, Ә, Б, В!*
*Шакмакларны таратам!*
*Там, там, там, там!*
*Мин уйнарга яратам!*
*Тсс, тсс, тсс, тсс!*
*Мин курчакны йоклатам,* –

дип әйтүгә сыбызгы сызгыра. Шулвакыт гаишник киемнәреннән укучы малай керә. Һәм бу балаларга, туры басыгыз, дип команда бирә. «Сәлам» УМКсының 1 нче сыйныфында «Шөгыльләр» темасы буенча өйрәнелгән җыр башкарыла. Барлык катнашучылар кулны кулга тотынышып, җырлап сәхнәгә чыгалар. Ике рәт булып тезеләләр.

*Кулны кулга тотыныйк,*
*Күңелле уен уйныйк!*
*Әллә-лә, әллә-лә,*
*Мин әйтәм, ә син эшлә!*
*Җырла!*
*Кулны кулга тотыныйк,*
*Күңелле уен уйныйк!*
*Әллә-лә, әллә-лә,*
*Мин әйтәм, ә син эшлә!*
*Бие!*
*Кулны кулга тотыныйк,*
*Күңелле уен уйныйк!*
*Әллә-лә, әллә-лә,*
*Мин әйтәм, ә син эшлә!*
*Алга атла!*

Гаишник алга чыгып баса. «Сәлам» УМКсының 3 нче сыйныфында «Шәһәрдә» темасы буенча өйрәнелгән җыр башкарыла.

*Бер, ике, өч, дүрт, биш – Алга!*
*Без чыгабыз ерак юлга.*
*Тәрәзәдән карыйбыз,*
*Анда нәрсә табабыз?*
*Кибет, зур яшел кибет!*
*Бер, ике, өч, дүрт, биш – Алга!*
*Без чыгабыз ерак юлга.*
*Тәрәзәдән карыйбыз,*
*Анда нәрсә табабыз?*
*Мәктәп, ике катлы мәктәп!*
*Әйе, мәктәп, ике катлы мәктәп!*

– Әйе, безнең мәктәп. Алда әле безне яңа белемнәр көтә. Безгә әле алга барасы да. Алга. Алда. *(Укытучы булып киенгән укучы әйтә.)*

Соңыннан «Сәлам» УМКсының 3 нче сыйныфында темасы «Туган җиремне яратам» буенча өйрәнелгән җыр башкарыла.

*Дөньяда телләр күп,*
*Тик туган тел бердү.*
*Әти-әни телендә*
*Бигрәк рәхәт сөйләү!*
*«Бонжур» – французча,*
*«Хеллоу» – инглизчә,*
*«Ни хао» – кытайча,*
*«Привет» дип әйтәм русча.*

*Я әйтеп кара әле.*
*Бу сүз ничек татарча?*
*«Сәлам! Сәлам, дустым!» – дип,*
*Мин сәламлим татарча.*
*Дөньяда телләр күп,*
*Тик туган тел бердү.*
*Әти-әни телендә*
*Бигрәк рәхәт сөйләү!*

– Хөрмәтле дуслар, кунаклар! Игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт!



**Язгөл ТАМАСОВА,**

Әлмәттәге «Адымнар – Әлмәт»
күптелле гимназиясенең
I квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

9

# Сыйфатларны кабатлау

(5 нче сыйныфта татар теле дәресе)

**Дәреснең тибы:** яңа белем һәм күнекмәләрне үзләштерү дәресе.

**Дәресне оештыру төрләре:** фронталь, парлап, индивидуаль.

**Предмет буенча планлаштырылган нәтиҗә:** һөнәри лексиканы үзләштерү.

**Метапредмет:** укытучы ярдәмендә дәреснең максатын куя, эшчәнлекнең планын билгели һәм коллективта эшли белү.

**Дәреснең максатлары:**

***1. Белем бирү максаты:*** һөнәри лексиканы үзләштерү, сөйләм телендә куллана белү.

***2. Күнекмәләр үстерү максаты:*** укучыларның танып белү күнекмәсен үстерү, мөстәкыйль эшчәнлеккә өйрәтү.

***3. Тәрбия бирү максаты:*** укучыларда гаиләгә, якыннарына карата мәхәббәт хисләре уяту, бер-берең ярдәм итеп яшәргә кирәклеген аңлату.

**Универсаль уку гамәлләре:**

*Танып белү:* проблеманы күрә һәм чишә белү, аңлап уку, нәтиҗә ясау.

*Коммуникатив:* аралаша белү осталыгын үстерү, үз фикереңне әйтә белү, сорауларга җавап бирү.

*Регулятив:* максат кую, шуңа ирешү, эшне планлаштыру, үз эшчәнлекләрен бәяләү.

*Шәхси:* укуга уңай мотивация, үзара хөрмәт.

**Дәресне җиһазлау:** дәреслек, интерактив такта, презентация, төрле карточкалар, кәрзин, фишкалар.

**I. Оештыру этабы**

– Хәерле көн, хөрмәтле укучылар. Кәефләрегез ничек? Бер-беребезгә уңышлар теләп, матур сүзләр әйтеп, дәресебезне башлап җибәрик. *(Мәсәлән, син бүген бик матур, син бик тә ягымлы, син шундый сөйкемле, синең күзләрең нурлы.)*

– Бик әйбәт, укучылар. Безгә бүген бик күп яңа мәгълүмат белән танышырга туры киләчәк. Сез әзерме? *(Әйе, без әзер.)*

– Укучылар, кәрзиндә төрле төстәге тасмалар бар, үзегезгә ошаган төсне сайлап, төркемнәргә бүленеп утырырга кирәк булыр. *(Укучылар 2 төркемгә бүленә.)*

– Ә хәзер, укучылар, телебезне шомарту өчен фонетик зарядка ясап алыйк. Әйдәгез, тизәйткечләрне безгә кем укуын сайлыйк. *(Исемнәр язылган таякчыклар ярдәмендә, укучыны сайлыйбыз.)*

| **1 нче төркем:** | **2 нче төркем:** |
| --- | --- |
| Алмалар да алланган,<br>Алланган да балланган.<br>Бал кортлары аларны<br>Чәчәкләр дип алданган. | Җылы җәйнең көннәрендә<br>Җәймә тау итәгендә<br>Җизни кызы Җәүһәрия<br>Җиләк җыя чиләгенә. |

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

– Тизәйткечләр нәрсә турында иде? *(Укучылар җавап бирә.)*

– Дөрес, укучылар. Әлеге сүзләрнең билгеләрен тактадан сайлап алып, кәрзиннәргә урнаштырыйк. *(Кәрзин, алма, җиләк һәм аларга кагылышлы сыйфатлар язылган карточкалар тактада эленеп тора, аларны укучылар төркемнәрдә сайлыйлар һәм тактада тиешле урынга беркетәләр.)*

– Укучылар, сез биремне бик тиз һәм төгәл эшләдегез. Үзегезгә үзбәя куеп барырга онытмассыз. Бәяләү слайдта язылган. Кемнең бер хатасы да юк, ул үзенең билгеләр дәфтәренә – «5»ле, кемнең бер хата – «4»ле, ике-өч хата җибәргән укучы «3»ле билгесе куя. Ә хәзер сәяхәтебезне дәвам итәбез.

**III. Яңа теманы аңлату**

**1. Уку мәсьәләсен кую.**

– Афәрин, укучылар, димәк, без бүген предметларның билгесен белдергән сүзләрне карап китәбез, бу сүзләр ничек атала? *(Сыйфат.)*

– Сыйфатларның сораулары ничек? *(Нинди? кайсы?)*

– Сыйфат җөмләдә нәрсә булып килә? *(Сыйфат җөмләдә аергыч булып килә.)*

– Афәрин, укучылар. Укучылар, әлеге дәрестә безнең максатыбыз булып теманы үзләштерү һәм алган белемнәрне практикада дөрес куллана белү тора.

**2. Яңа теманы модельләштерү.**

– Димәк, сыйфат предметның билгесен белдерә, Нинди? кайсы? сорауларына җавап бирә. Мәсәлән, матур, озын, зәвыклы һ.б. Тагынниләр әйтә аласыз? *(Сыйфат сүз төркеме предметның төсе, формасы, тәме, кыяфәте ягыннан билгесен белдерә.)*

– Әйе, дөрес, укучылар, ә хәзер дәфтәрләргә бирелгән модельне сызып куярбыз. *(Тактада модель сызылган.)*

**IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту**

**1. Текст белән эш.**

– Хәзер, әйдәгез, бирелгән текстны карап китик әле. *(Бергәләшеп текстны укыйлар.)*

***Безнең гаилә***

*Безнең гаилә зур һәм тату. Гаиләбездә биш кеше бар: әбием, әтием, әнием, абыем һәм мин. Әбием карт, ул лаеклы ялда, эшләми. Минем әнием – татар теле укытучысы. Ул яңа, матур мәктәптә эшли. Әтием зур заводта эшли. Ул – баш инженер. Абыем миннән зур. Ул – тырыш укучы, имтиханга әзерләнә. Мин өченче сыйныфта укыйм. Мин укырга яратам, шуңа күрә мәктәпкә бик шатланып йөрим.*

– Укучылар, әлеге текст нәрсә турында? *(Әлеге текстта сүз гаилә турында бара.)*

– Дөрес. Балалар, сезгә хәзер әлеге җөмләләрдән аергычларны табарга кирәк булачак, аның өчен интерактив тактада эшләячәкбез. *(LearningApps сайтында берничә җөмләләр язылган, шул җөмләләрдән укучылар сыйфатларны табалар.)*

**2. «Минем сөйлисем килә».**

– Укучылар, сезгә өй эшенә үзегезнең гаилә турында язып килергә кирәк иде. Әйдәгез, тыңлап китик әле. *(Берничә укучы гаиләләре турында сөйли, укучылар аларга сораулар бирәләр.)*

**3. «Кирәкле сүзне тап» уены.**

– Укучылар, әлеге куар-кодлар астында җырлар яшеренгән, аларны тыңлап, сезгә ул җырларда сыйфатларны табарга кирәк булачак. *(Җырларны тыңлыйлар, җавапларны әйтәләр, башта укучылар төркемнәрдә эшлиләр, соңыннан җаваплар тыңлана.)*

1 нче җыр:

*Иң якты кояшым,*
*Иң назлы гөлкәем,*
*Иң якын кешем син,*
*Әнием җаным син.*

Тыңла

2 нче җыр:

*Ак яулыклы әнием, чал чәчле әтием,*
*Тик исән булыгыз, картларым.*
*Без әле бергәләп яшәрбез, яшьнәрбез,*
*Кадерле, сөекле картларым.*

Тыңла

**4. Сыйфат белән сыйфатланмышны тап.**

– Укучылар, хәзер без сезнең белән интерактив тактада эшләячәкбез. Сезгә әлеге җырларда ишеткән сыйфатлар белән алар ияртеп килгән исемнәрне табып билгеләргә кирәк булачак.

*(«Скрэббл» уены ярдәмендә биремне эшлиләр.)*

**V. Өй эше бирү**

– Афәрин, биремне барыгыз да дөрес башкарды. Сезгә хәзер киләсе дәрескә өй эшен язып куярга кирәк булачак:

**1.** Кагыйдәне кабатла.

**2**. Китаптан 51 нче күнегүне эшләргә (38 нче бит). Нинди? кайсы? сорауларына җавап биргән сүзләрне табып, язып алырга.

**3.** Сыйфатлар кулланып, 5 җөмлә төзергә.

**VI. Рефлексия**

– Хәзер, укучылар, бүгенге дәрескә йомгак ясап, әйдәгез әле, тактага игътибар итик, сезгә хәзер әлеге сүзләрдән кирәкле билгеләрне генә сайлап алып, сыйфат темасы буенча пазл төзергә кирәк булачак. *(Укучылар, кирәкле билгеләрне табып, пазлны дөрес җыя.)*

***Бирелгән сүзләр:***

*Исем Ничә? Ничәнче? Җөмләдә аергыч булып килә матур, яңа*
*Фигыль Кайчан? Кайсы? Нинди?*
*Җөмләдә хәл булып килә тиз, кинәт*
*Сыйфат Нинди? Кайсы?*
*Җөмләдә хәбәр булып килә яшел, бара*




– Димәк, әйдәгез, хәзер бергәләп йомгак ясыйк. Без бүген нинди сүз төркеме белән таныштык? *(Сыйфат сүз төркеме белән таныштык.)*

– Ул нәрсәне белдерә һәм аның сораулары? *(Ул предметның билгесен белдерә, предметларның тәмен, формасын, төсен һәм кыяфәтен ачыклап килә, сыйфатның сораулары: нинди? кайсы?)*

– Дөрес, ә җөмләдә ул нинди җөмлә кисәге булып килә? *(Җөмләдә ул аергыч булып килә.)*

**VII. Билге кую**

– Ә хәзер бүгенге дәрес өчен сезгә билге куярбыз. Афәрин, укучылар, барыгыз да әйбәт билгеләр алды. Сорауларыгыз булмаса, дәресне тәмамлыйбыз. Уңышлы көннәр!



**Эльмира ГАРИФУЛЛИНА,**

Балтач районы Бакый Зыятдинов исемендәге
Карадуган гимназиясенең
I квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

10

# Сүз ясалыш ысулы буларак, сүзләрне кушу. Кушма сүзләр

(5 нче сыйныфта татар теле дәресе)

**Һәр халыкның үз гореф-гадәтләре булган кебек татар халкының да үз бәйрәмнәре, милли традицияләре, үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Кызганыч, укучылар милли гореф-гадәтләрне, йолаларны онытып бара. Шуңа күрә әлеге дәресемдә уен технологиясен кулланып, татар халкының үз бәйрәмнәрен, милли гореф-гадәтләрен искә төшерүне максат итеп куйдым. Халык йолалары укучыларның күңелен били, тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә, бер-берләренә якынайта, дуслаштыра.**

**Максат:**

1. Кушма сүзләр турында мәгълүмат бирү.
2. Кушма сүзләрне аера, дөрес яза, җөмләдә куллана белергә өйрәтү.
3. Гореф-гадәтләребезгә сакчыл караш, хөрмәт тәрбияләү.

**Эш формалары:** төркемнәрдә эш, фронталь эш, индивидуаль эш, парларда эш.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр ачу.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Предмет нәтиҗәлелеге:*** татар тел гыйлемендә кушма сүзләр, аларны танып белү.

***Метапредмет нәтиҗәләр:***

*Танып белү УУГ:* укучыларның сорау куя белү, нәтиҗә ясый белү кебек фикерләү сәләтләрен үстерү, үз фикерләрен дөрес һәм матур итеп әйтүләренә ирешүне булдыру.

*Регулятив УУГ:* эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү; ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сыйфатларга ия булуга ирешү.

*Коммуникатив УУГ:* төркемдә эшли белү; мәгълүматны туплау өчен күмәк эшчәнлектә катнашу.

**Җиһазлау:** дәреслек, мультимедиа, компьютер, кроссворд, карточкалар, интерактив такта.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру**

– Хәерле көн, дуслар, сезгә!
Хәерле көн һәммәгезгә!
Татар телен өйрәнүдә
Уңышлар телим сезгә.

**II. Мотивлаштыру**

– Укучылар, түбәндәге слайдка карагач, нинди бәйрәм күз алдыгызга килде?

– Әйе, әлбәттә инде, Сабан туе! Сабан туе – татар халкының иң гүзәл бәйрәме, халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, җырлары һәм биюләре бергә кушылган хезмәт бәйрәме. Бәйрәм атамасы борынгы төрки «сабан» һәм «туй» сүзләреннән килеп чыккан.

– Сез дә, укучылар, бу бәйрәмне көтеп аласызмы?

– Әйе, сез генә түгел, бөтен татар халкы көтеп аладыр ул ямьле бәйрәмебезне. Шулай булгач, әйдәгез, туган ягыбызда салкын кыш булуга карамастан, үзебезне җәй көнендәге кебек хис итеп, дәресебезне Сабан туе рәвешендә үткәрик әле. Барыбыз да Сабан туенда уйнала торган уеннарда катнашырбыз, шул ук вакытта өйрәнәчәк тема буенча белем тупларбыз. Сез ризамы? Алайса, Сабан туен башлап җибәрәбез! *(«Сабантуй» җыры яңгырый. Ш. Җиһангирова сүзләре, И. Байтирәк көе.)*

**III. Яңа белемнәрне үзләштерү**

Беренче уеныбыз **«Сүзләр тавы»** дип атала.

– Укучылар, әйдәгез әле, түбәндәге слайдта бирелгән сүзләрне ясалышлары буенча төркемлик. *Агач, китап, эшче, тамыр, сүз, тәрәзә, уенчык, каенлык, авылдаш, ташбака, гөл, кеше, сөенче.* Кайсы сүз артып калды? Бу сүз ничек ясалган? Бу сүзне ничек дип атарбыз икән? *(Кушма сүз.)*

– Дөрес, бүген без сезнең белән **кушма сүзләр** белән танышырбыз. Дәфтәрләрегезне ачып, сыйныф эше,

бүгенге теманы язып куегыз. Дөрес утыру, каләмне дөрес тоту, дөрес, чиста һәм матур язу кебек кагыйдәләрне дә истән чыгармыйбыз.

– Ә бүгенге дәресебездә кушма сүзләр турында сез ниләр белергә телисез? Нәрсәләр белүне без дәреснең максаты итеп куябыз? *(Аларның нинди сүзләр икәнен, ничек язылуын.)*

– Сезнең зирәклекне тикшереп алыйм әле. Табышмакларны дөрес итеп чишеп, кроссвордка сүзләр урнаштырсак, Сабан туе булачак урынга да килеп җитәрбез. Ул биек тау итәгендә, урманга якын матур урында уздырыла. Башладык! *(Табышмакларның җавапларын тизрәк һәм дөрес тапкан укучы җиңүче була).*



1. Түп-түгәрәк кара күз.
Сап-сары керфекләре.
Ул ярата кояшны,
Без – аның бөртекләре. *(Көнбагыш.)*

2. Кыз исеме. Беренче тамыры – үсемлек, икенчесе – аңа үсәргә ярдәм итүче чыганак. *(Гөлнур.)*

3. Ятса – таш,
Якса – утын. *(Ташкүмер.)*

4. Тышы кабык, эче мамык. *(Гөлҗимеш.)*

5. Бер карасаң, тышта йөри,
Бер карасаң йортта ул.
Йортым ерак калмасын дип,
Аркасында йөртә ул. *(Ташбака.)*

– Игътибар иткән булсагыз, кроссвордтагы җавапларның барысы да нинди сүзләр? *(Кушма сүзләр.)* Ә нинди сүзләргә без кушма сүзләр дип әйтәбез соң? Әйдәгез, төркемнәрдә киңәшик. *(Укучыларның җаваплары.)*

– Әйе, бик дөрес: **ике сүз кушылып ясалган сүз кушма сүз дип атала.**

**Мәсәлән:** төн+боек, оек+баш, яр+канат, китап+ханә. *(Экранда сүзләр күрсәтелә.)* Ә үзегез нинди кушма сүзләр беләсез? *(Укучыларның җаваплары.)*

**IV. Яңа белемнәрне ныгыту**

– Сабан туебыздагы икенче уеныбызга рәхим итегез! Ул **«Колга башына менү»** дип атала. *(Экранда колгага менү күренеше.)*

*Озын гына шоп-шома*
*Бер багана бар шунда.*
*Әтәч тора әйләнгәләп,*
*Шул багана башында.*
*Әтәчкә шук малайлар*
*Әй кызыгып карыйлар,*
*Багана шома булганга*
*Бер дә менә алмыйлар.*

– Бәлки сез менә алырсыз? Кем җитез? Кем өлгер? Әтәч аягындагы сорауга җавап бирсәгез, димәк, сез колга башына менгәнсез дигән сүз. Я, кайсыгыз? *(Уенчык әтәч, аягында сорау: рус теленнән кергән кушма сүзләр бармы?)*

– Пароход, теплоход, самолёт, автовокзал, автозавод, автомашина, километр, сантиметр, килограмм.

– Рәхмәт, бик күп кушма сүзләр беләсез икән. Инде бер кагыйдәне искә төшерик: **ике тамыр сүз кушылып яңа сүз ясалганда, икенче тамыр ю, е, я авазларына башланса, бу сүзләр арасына ь һәм ъ билгеләре куела.** Укучылар, кайсы очракта без ъ, ә кайсы очракта **ь** билгесе куябыз? Мәсәлән, көньяк дигән сүздә нинди билге куелырга тиеш? Ни өчен? *(**ь** билгесе куела.)*

– Инде нәтиҗә ясыйк. *(Укучылар кагыйдәне әйтәләр.)* Бик дөрес, **әгәр сүзнең беренче иҗеге калын булса – ъ, ә нечкә булса, ь билгесе куела**. Мәсәлән: альяпкыч, төньяк, кульяулык, берьюлы һ.б.

*Инде белемнәрне ныгытып куйыйк:*
*Бергә берне кушкач ничә?*
*Беләм: ике диярсез.*
*Сүзгә сүзне кушкач?..*
*Менә анысы нәрсә дигән сүз?*
*Миңа кирәк ике сүз,*

*Шуннан ясыйм кушма сүз.*
*Карагыз минем көчкә:*
*Алам «ак»ны – төс бит ул,*
*Канатлы дус – «кош» бит ул;*
*«Ак»ны кушкач шул «кош»ка*
*«...» дигән дус чыга.*

*(Укучылар кушма сүзне, аккош сүзен үзләре әйтә.)*

– Алдагы уеныбыз **«Катыктан акча эзләү»** дип атала. Без дә тәмле катык ашый-ашый белемнәрне ныгытыйк әле. Катыктагы акчаны абыйлар тырышып эзләгән кебек, сезгә дә хәзер мин экранда күрсәтәчәк рәсемнәрне берләштереп, яңа сүз ясарга кирәк булачак. *(Рәсемнәр күрсәтелә, укучылар кушма сүзләр ясый.)*

– Алга таба биремне бераз катлауландырам: бер төркем рәсемнәр арасыннан бер-берсенә туры килгән сүзләрне табып, кушма сүзләр ясарга кирәк. Ягез, кем тизрәк?

– Сабан туе кызганнан-кыза бара бит. Тик нинди бәйрәм җыр-биюсез узсын инде?!

**Тиззарядка** *(татар биюе башкарыла)*

Сабан туе – күңел ачу,
Уен, шатлык бәйрәме.
Җырлар җырлап, биеп алыйк,
Шау-гөр килеп, әйдә әле!

– Бию барышында мин сезгә сораулар әйтәм, көй туктагач, шул сораудагы җавап санынча сезгә берләшергә кирәк. Мәсәлән, ике икең ничә? Дүрт. Димәк, сез дүрт кеше бергә тупланырга тиешсез. Башладык.

**Сораулар:**

*– Кушма сүз ничә сүз кушылып ясала? (Ике.)*

*– Аккош сүзендә ничә хәреф?*

*– Өчпочмакта ничә почмак?*

*– Сабан туенда уеннар*
*Төрле була, күп була.*
*Уеннарсыз Сабан туе*
*Булмаган да күк була.*

Ә хәзер барыбыз да **«Ат чабышы»** ярышында катнашырбыз. *(Экранда ат чабышы күренеше.)* Кем биремне дөрес һәм тизрәк үти, шуның аты беренче килә.

**Карточкалар белән эш.**

Сүзләрне туры китереп, кушма сүзләр ясарга.

| | |
|---|---|
| Иң | бау |
| Китап | җимеш |
| Көн | озын |
| Бил | баш |
| Гөл | көмеш |
| Тере | ханә |

– Сабан туеның төп бизәге – татарча көрәш. Искә төшереп китик әле, укучылар, Балтач районында үткәрелгән Сабан туе бәйрәмнәрендә милли көрәш буенча иң күп җиңү яулаган батыр кем икән ул?

– Әйе, Айдар Хәйретдинов. *(Экранда аның рәсеме.)* Арбор авылы егете.

– Укучылар, ә авылыбыз Карадуганда Сабан туе батыры булып калучы кешеләрдән кемнәрне беләсез?

– Фидаил Хәйруллин, Рифкать Камалетдинов, Илнур Хәйруллин, Ленур абыйлар.

– Ә үзегез көрәшәсезме? Киләчәктә дә авыл данын якларлык егетләр булырсыз дип ышанып калам. Ә хәзер без дә белем мәйданында көрәшеп алыйк әле.

*Уеннарда актив катнашып, иң күп кульъяулык җыйган 2 укучы чыга, чиратлашып түбәндәге сүзләргә ъ һәм ь билгеләрен куялар.*

**Ал+ япкыч, шәл+ яулык, бер+ юлы, йөз+ яфрак, дөн+ я, көн+ як, кул+ яулык, төн+ як, өч+ яклы, һәр+ яклап, Таш+ елга, Кызыл+ яр, Ях+ я, дүрт+ яклы, тигез+ янлы.**

– Сабан туе бәйрәменең абсолют көрәшчесе билгеле. Афәрин! *(Җиңүчегә уенчык тәкә бирелә.)*

**V. Рефлексия**

– Менә шуның белән Сабан туе бәйрәмебезне тәмамлыйбыз. Дәрестә ниләр белдек? Максатыбызга ирештекме?

Ә хәзер өй эшен язып куегыз. Кушма сүзләр кертеп, «Сабан туе» темасына хикәя язып килергә.

– Инде Сабантуй бәйрәменнән сезгә бүләк. *(Билгеләр кую.)* Дәрес тәмам.




**Эльмира ГЫЙЛЬМАНОВА,**

Казандагы 6 нчы гимназиянең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Налия ГОСМАНОВА,**

Казандагы 6 нчы гимназиянең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

11

# Бәйлекләр һәм аларның кулланылыш үзенчәлеге

(5 нче сыйныфта татар теле дәресе)

**Максат:** бәйлекләр һәм аларның төркемчәләре турында мәгълүмат бирү; бәйлекләрне дөрес итеп билгеләргә өйрәнү, балаларның уйлау, фикерләү сәләтен, иҗади активлыгын үстерү, телдә дөрес кулланырга өйрәтү; татар теле дәресенә мәхәббәт тәрбияләү.

**Дәрес төре:** иҗади-эзләнүле.

**Дәрес тибы:** яңа материалны аңлату.

**Дәресне җиһазлау:** компьютер, интерактив такта, карточкалар, презентация.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше**

– Якты чырай, яхшы кәеф
Күрәм сезнең йөзегездә.
Исәнмесез, хәерле көн!
Телим һәрберегезгә.

– Шушы җылы мөгамәләдә дәресне башлап җибәрик. Балалар, барыгыз да бүгенге дәрескә әзерме? Бүгенге дәрестә мин сезгә уңышлар телим.

– Без үткән дәресләрдә мөстәкыйль сүз төркемнәре белән таныштык. Искә төшереп китик әле. *(Исем, сыйфат, фигыль, сан, алмашлык.)*

– Аларның төп аермасы нәрсәдә? *(Сорау куеп була.)*

*(Һәрбер сүз төркеменең нинди сорауларга җавап бирүе сорала.)*

– Сүз төркемнәре белән танышуны дәвам итәбез.

**II. Уку мәсьәләсен кую** (Фронталь)

– Минем өстәлдә серле тартма бар. Серле тартма бүген безгә нинди биремнәр әзерләде икән? Әйдәгез, карап карыйк. *(Тартмадан зәңгәр конверт алабыз.)*

1 нче бирем карточкадагы сүзләрне сүз төркемнәренә бүләргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Әти | Акыллы | Бәрәңге | Өчен | Алар |
| Без | Белән | Китте | Шатлык | Кебек |
| Яза | Сөйли | Юмарт | Мин | Җиде |
| Биш | Песи | Унбер | Яшел | Йөгерә |

Уйлар өчен **1 минут вакыт** бирелә. *(Сүзләрне эчтән укыйлар. Бер-берсенә әйтәләр. Соңыннан укытучы сораган укучы кычкырып әйтә.)*

– Хәзер, әйдәгез, тикшереп китик. Укучылар, нинди сүз төркемнәрен таптыгыз? (*Исем, сыйфат, фигыль, сан, алмашлык.)*

– 1 нче команда, исемнәрне санап чыгыгыз әле. *(Әти, песи, бәрәңге, шатлык.)*

– Сыйфатларны? *(Акыллы, юмарт, яшел.)*

– Саннарны? *(Биш, унбер, җиде.)*

– Фигыльләрне? *(Яза, сөйли, китте, йөгерә.)*

– Алмашлыкларны? *(Без, мин, алар.)*

– Ә сез аларны ничек таптыгыз? *(Сорау куеп.)*

– Нинди сүзләр калды? *(Белән, өчен, кебек.)*

– Ә ни өчен? *(Чөнки аларга сорау куеп булмый.)*

– Димәк, без бүген нинди сүзләр белән танышырбыз? *(Сорау куеп булмый торган сүзләр белән.)*

– Әйе, без бүген сезнең белән сорау куеп булмый торган, сүзләрне һәм җөмлә өлешләрен үзара бәйли торган сүз төркеме турында сөйләшербез. Болар **бәйлекләр** дип атала.

– Дәресебезгә нинди максат куябыз? *(Бәйлекләрне өйрәнү һәм аларның сүзләрне, җөмләләрне төзүдә дөрес итеп куллану. Кагыйдәне кычкырып уку.)*

**Бәйлекләр** ярдәмлек сүз төркемнәренә керә. Алар сүзләрне, җөмләләрне бер-берсенә бәйләү өчен кулланыла.
Бәйлекләр: *белән, өчен, аша, сыман, шикелле, кебек, кадәр, башка, таба, соң, саен, бирле, чаклы, хәтле* һ.б.

– Укучылар, бәйлекләр җөмләдә нәрсә өчен кирәк? *(Бәйлекләр җөмләдә сүзләрне, җөмләләрне бер-берсенә бәйләү өчен кирәк.)*

– Алар нинди сүз төркеме була? *(Ярдәмлек сүз төркемнәре.)*

**III. Уку мәсьәләсен чишү**

Китапларда эш. 15 нче күнегү, 103 нче бит. *(Кулларын күтәреп, телдән әйтәләр.)*

Өчен — для
Белән — с
Кебек — как
Кадәр — до
Аша — через
Башка — кроме

*(Кем тоташтырып бетерә, карандашын күтәрә. )*

– Укучылар бәйлекләрнең тәрҗемәләрен үзегезгә саклап куегыз.

Серле тартма безгә 2 нче бирем әзерләгән. Ул безнең кызыл конвертта.

Кроссворд чишү. «Башваткыч».

Сезгә бирелгән сүзтезмәләр. Аларда нинди бәйлекләр турында сүз бара икән?

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 1. | К | Е | Б | Е | К | |
| | | С | | А | | | | А | |
| | | А | | Д | | | | Р | |
| | Б | Е | Л | Ә | Н | | | Ш | |
| | А | Н | | Р | | | | Ы | |
| | Ш | | | | | | | | |
| | К | | | | | | | | |
| Т | А | Б | А | | | | | | |

Кояш .... **(кебек)** елмая;
кибеткә ... **(кадәр)** йөгерү;
Алсу ... **(белән)** бергә уку**;**
көн ... **(саен)** шатлану**;**
әнидән ... **(башка)** бармау**;**
циркка ... **(таба)** атлау;
җилгә ... **(каршы)** бару.

**–** Вакыт чыкты. Тикшерәбез. *(Һәр команда берәр сүзтезмәне укый.)*

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү**

1. Серле тартмабызның алдагы биреме – яшел конверттагы сүзләр язылган стикерлар һәм А3 форматында сүзтезмәләрдә төшеп калган сүз.

– Әйдәгез, бәйлекләрне өйрәнүне дәвам итик. Сезнең алдыгызда – А3 кәгазендә язылган сүзтезмәләр һәм яшел конвертта – сүзләр язылган стикерлар. Сезнең бурычыгыз сүзтезмәләрдә төшеп калган сүзләрне уйлап стикерларны ябыштырырга кирәк булыр. Сезгә уйлар өчен **1 минут вакыт** бирелә.

... <u>белән</u> бару, ... <u>таба</u> йөгерү, ... <u>өчен</u> сөйләү, ... <u>башка</u> бармау, ... <u>төсле</u> матур, ... <u>кадәр</u> килү, ... <u>кебек</u> якты. *(Тикшерелә. Һәр командадан бер сүзтезмә укыла. Тактада слайдта чыга: әни <u>белән</u> бару, мәктәпкә <u>таба</u> йөгерү, дустым <u>өчен</u> сөйләү, әтидән <u>башка</u> бармау, курчак <u>төсле</u> матур, урманга <u>кадәр</u> килү, кояш <u>кебек</u> якты.)*

– Укучылар, яңадан тактага карыйк әле. Бәйлекләр нинди сүз төркеменнән соң килгәннәр? *(Исемнәрдән соң килгәннәр.)*

– Ә бу исемнәр безнең нинди сорауларга җавап бирә? *(Кем? Кая? Кемнән? Нәрсә?)*

– Кайсы килеш сораулары алар?

*(Баш килеш, юнәлеш килеше, чыгыш килеше.)*

– Димәк, балалар бәйлекләр алдында килгән исемнәр кайсы килешләрдә килгән? *(Баш килеш, юнәлеш килеше, чыгыш килеше.)*

– Укучылар, бәйлекләр 3 төркемчәгә бүленә: баш килешне таләп итүче бәйлекләр, юнәлеш килешен таләп итүче бәйлекләр һәм чыгыш килешен таләп итүче бәйлекләр. *(Кагыйдә тактада күрсәтелә.)*

2. Почмак уены.

Почмакларда: баш килеш, юнәлеш килеше, чыгыш килеше.

– Сезнең парталарыгызда – сары конвертлар, эчендә – сүзтезмәләр язылган карточкалар. Һәрберегез берәр сүзтезмә алып, үзегезнең почмакларыгызны табып басарга кирәк булыр.

*(Һәр партадагы конвертта 4 сүзтезмә. Укучылар, сүзтезмәләрне укып, тиешле почмакларга баса.)*

| | | |
|---|---|---|
| Әти белән бару | Курчак төсле матур | Җилгә каршы бару |
| Стадионга таба йөгерү | Дәрестән соң килү | Юл аша чыгу |
| Дустым өчен сөйләү | Абыем кебек көчле | Эштән соң ял итү |
| Гаиләмнән башка бармау | Маратка таба йөгерү | Мәктәпкә кадәр йөгерү |

*(Тикшерәбез. Вакыт калса җөмләләр төзетергә.)*

– Дәфтәрләрдә бүгенге числоны, сыйныф эшен, теманы язабыз.

3. Дәфтәрләрдә эш. 17 нче күнегү (104 нче бит). Исемнәргә килеш кушымчалары ялгап, җөмләләрне күчереп язарга. *(Бер-берләрен тикшерәләр, дөрес җавапка + куеп баралар.)*

*1. Фатир__, мәктәп___, авыл__ кадәр озатам.*

*2. Әби___, әни__, әти__ башка күңелсез.*

*3. Уку__, тренировка__ соң кайтам.*

**V. Рефлексия**

Әйдәгез, хәзер тест сорауларына да җавап биреп, белемебезне ныгытып куйыйк. Сезнең алда карточкалар: карточкаларга исем-фамилиягезне язып куеп, + тамгасы белән сорауларга җавап бирегез.

| **Сораулар** | **Әйе (+)** | **Юк (-)** |
|---|---|---|
| Татар телендә бәйлекләр бармы? | + | |
| Бәйлекләр сүзләрне һәм җөмләләрне бәйләү өчен хезмәт итә. | + | |
| Бәйлекләр ярдәмлек сүз төркемнәреме? | + | |
| Аларга сорау куеп буламы? | | – |
| *Белән, аша, буенча* сүзләре – бәйлек. | + | |
| Бәйлекләр килеш белән төрләнә. | | – |
| *Белән* бәйлеге *кем?* соравына җавап бирә. | | – |
| *Энә белән кое казу* сүзтезмәсендә *белән* бәйлеге исемнән соң килә. | + | |

**VI. Йомгаклау**

**–** Балалар, без бүген нинди сүз төркеме турында сөйләштек? *(Ярдәмлек сүз төркемнәре.)*

– Нинди тема өйрәндек? *(Бәйлекләр.)*

– Алар ни өчен кирәк? *(Сүзләрне, җөмләләрне бер-берсенә бәйләү өчен кирәк.)*

**VII. Өй эше бирү.**

19 нчы күнегү. Сүзләргә тиешле килеш кушымчаларын ялгап текстны укырга. *(Телдән.)*

2. 19-1 нче күнегү. Тексттан бәйлекләр кергән җөмләләрне күчереп язарга. Килешләрне билгеләргә.

18 нче күнегү. Бәйлекләр белән җөмләләр төзергә.



**Гөлнара ЮНЫСОВА,**

Тәтеш районы Бидәңге төп мәктәбенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

12

# Шарт фигыль

(6 нчы сыйныфта татар теле дәресе)

**Дәреснең максаты:** шарт фигыль турында төшенчә формалаштыру, аның ясалу үзенчәлеген үзләштерергә ярдәм итү, хикәя һәм боерык фигыльләр буенча белемнәрен исәпкә алу.

**Формалашырга тиешле универсаль уку гамәлләре (УУГ)**:

***Предмет нәтиҗәләре:***

– шарт фигыль турында төшенчә формалаштыру, аның ясалу үзенчәлеген үзләштерергә ярдәм итү, төп фигыльгә бәйләнеп килүен аңлау; сөйләмдә дөрес куллану;

– хикәя һәм боерык фигыльләр буенча белемнәрен исәпкә алу.

***Метапредмет нәтиҗәләр:***

*Регулятив*: сөйләм телен үстерү, системалылык булдыру, мөһим нәтиҗәләрне истә калдыру.

*Танып белү*: булган белемнәргә таянып, шарт фигыль турында гомуми нәтиҗәне чыгару.

*Коммуникатив*: төрле мисаллар белән үз фикереңне дәлилләү, хезмәттәшлеккә ирешү.

***Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:***

– укуга җаваплы караш булдыру;

– бер-береңне хөрмәтләү, теләктәшлек кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү.

**Эшне оештыру тәртибе**: фронталь, парда, индивидуаль.

**Күрсәтмә әсбаплар:** презентация, кроссенс карточкалары (8 данә), 4 аңлатмалы сүзлек, биремле карточкалар (өлешчә тулган таблицалар; җөмләдә төшеп калган сүзле җөмләләр), кластер өчен терәк карточкалар.

**Метод һәм алымнар (структуралар):** өлешчә эзләнү, сүзлек һәм дәреслек белән эш, кроссенс, кластер.

**Дәреслек:** Шәкүрова М. М. Туган тел (татар теле). 6 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы  А. Шляпкин]. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. – 192 б.: рәс. б-н.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру. Уңай халәт тудыру**

– Исәнмесез, укучылар! Дәресебез кызыклы һәм файдалы үтәр дип ышанам, барыбызның да уңышка ирешүен телим.

**II. Актуальләштерү (6 мин.)**

– Балалар, уйлап карагыз әле: укучы дәрестә нишләсә уңышка ирешә?

*Диалог белән бергә кроссенс төзелә.*

| | | |
|---|---|---|
| Укытучыны игътибар белән **тыңласа** | Биремнәрне **үтәсә** | Сүзлекләр **кулланса** |
| Ялкау **булмаса** | **Шарт фигыль** | Өстәмә китаплар **укыса** |
| Вакытның кадерен **белсә** | Сыйныфташларына да **ярдәм итсә** | Дәрестә үзе дә **тырышса** |

– Әлеге карточкалардан калын шрифт белән бирелгән сүзләрне укып чыгыгыз. *(Тыңласа, үтәсә, кулланса, укыса, тырышса, ярдәм итсә, белсә, булмаса.)*

– Бу сүзләргә нинди сорау куеп була? *(Нишләсә?)*

– Алар нәрсәне белдерә? *(Эш-хәлне.)*

– Нинди сүз төркеменә карыйлар? *(Болар – фигыльләр.)*

– Фигыль дип нинди сүз төркемен атыйбыз? *(Фигыль – зат яки предмет тарафыннан үтәлгән эш-хәлне белдергән, нишли? нишләде? нишләячәк? нишләр? кебек сорауларга җавап биргән сүз төркеме.)*

– Алдагы дәресләрдә фигыльнең нинди төркемчәләрен өйрәндегез? *(Хикәя һәм боерык фигыльләрне.)*

– Атаган фигыльләр кайсы төркемчәгә караганын әйтә аласызмы? *(Юк. Безгә алар таныш түгел.)*

– Укучылар, бу төркемчәне шарт фигыль дип атыйлар *(кроссенска соңгы урта битен куям: **шарт фигыль**).*

– Бу фигыльләрнең уртаклыклары бармы? *(-са/-сә кушымчасы.)*

**III. Дәреснең максаты белән таныштыру (1 мин.)**

– Шарт сүзе нәрсәне аңлата? Аңлатмалы сүзлекләрдән аның мәгънәсен эзләп табыгыз. *(Сүзлек белән эш.)*

***– Берәр эшнең булу-булмавын тәэмин итә торган хәл.*** *(Бер укучы кычкырып укый. Яңа сүзлекләрдә – 678 нче бит.)*

– Балалар, без беренче биремне үтәдек. Сез сыйныфташыгыз белән килешсәгез, үзбәя битенә + куегыз. *(Үзбәя битендә эш.)*

**Слайд ярдәмендә максат кую:**

– Шарт фигыль белән танышырга.

– Аның мәгънәсен, ясалышын, төрләнешен белергә.

– Шарт фигыльләрне сөйләмдә кулланырга.

– Дәфтәрне ачып, число, сыйныф эше һәм теманы язып куябыз.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү**

– Игътибар белән рәсемгә карап, татар халык мәкален искә төшерегез.

**Күп укысаң, күп белерсең.**

*Слайдта башта рәсем, аннары мәкаль.*

1. Фигыльләрне атагыз. *(Укысаң, белерсең.)*
2. Төркемчәсен әйтегез. *(Укысаң – шарт фигыль, белерсең – хикәя фигыль.)*
3. Барлыктамы, юклыктамы? *(Икесе дә барлыкта.)*
4. Зат-санын билгелибез. *(Укысаң – 2 нче зат, берлектә. Белерсең – 2 нче зат, берлектә.)*

**Яшьлегеңдә өйрәнмәсәң, картлыгыңда үкенерсең.**

1. Шарт фигыльне атагыз. *(Өйрәнмәсәң.)*
2. Сорау куегыз? *(Нишләмәсәң?)*
3. Барлыктамы, юклыктамы? *(Юклыкта.)*
4. Зат-санын билгелибез. *(2 нче зат, берлектә.)*
5. Кайсы фигыльне ачыклап килә? *(Үкенерсең.)*
6. *Үкенерсең* фигылен төшереп калдырсак, җөмлә мәгънәсен аңлый алабызмы? *(Юк.)*

***– Җөмләдә шарт фигыль һәрвакыт икенче бер фигыльгә бәйләнеп килә.***

Димәк, шарт фигыль турында нинди нәтиҗә ясап була?

**Шарт фигыль икенче бер фигыльдән аңлашылган эшнең яки хәлнең үтәлү-үтәлмәвенә шарт булып килә. *Нишләсә?* соравына җавап бирә, зат-сан белән төрләнә. Барлыкта һәм юклыкта килә.**

– Басымга да игътибар итик әле. Моның турында нәрсә әйтә аласыз? *(Юклык кушымчасы алганда, басым фигыльләрдә юклык кушымчасы алдындагы иҗеккә төшә.)*

**Кагыйдә белән танышу. (2 мин.)**

– Нәтиҗәне дөрес ясадыкмы? Дәреслекнең 41 нче битен ачып, кагыйдәне тагын бер кат укып чыгыгыз, чагыштырыгыз. *(Нишләсә? соравына җавап бирә, зат-сан белән төрләнә.)*

**1 нче язма эш: карточкаларда эш.**
– Таблицаның баганаларын тутырыгыз.

| Фигыль | Сорау | Барлыкта-юклыкта | Шарт фигыль кушымчасы | Зат-сан |
|---|---|---|---|---|
| **Өйрәнмәсәм** | *Нишләмәсәм?* | *Юклыкта* | *-сә* | *1 нче зат, берлек сан* |
| **Тыңласак** | *Нишләсәк?* | *Барлыкта* | *-са* | *1 нче зат, күплек сан* |
| **Санасагыз** | *Нишләсәгез?* | *Барлыкта* | *-са* | *2 нче зат, күплек сан* |
| **Тырышса** | *Нишләсә?* | *Барлыкта* | *-са* | *3 нче зат, берлек сан* |
| **Үтәмәсәләр** | *Нишләмәсәләр?* | *Юклыкта* | *-сә* | *3 нче зат, күплек сан* |

– Партадашыгыз белән эшләрне алмашыгыз, эталон буенча тикшерегез.

– Хатасыз эшкә үзбәя битендә 3 +, 1 – 2 хаталыга – 2+, аннан да артыкка 1+ куябыз.

**2 нче язма эш: җөмләләргә төшеп калган шарт фигыльләрне өстәп языгыз.**

1. Укытучыны игътибар белән … *(тыңласам)*, шарт фигыльне кулланырга өйрәнермен.
2. Шарт фигыльне кулланырга … *(өйрәнсәм)*, сөйләмем бай булыр.
3. Сөйләмем бай … *(булса)*, мин гел татарча сөйләшермен.
4. Гел татарча … *(сөйләшсәм)*, әбием минем өчен шатланыр.
5. Әби минем өчен … *(шатланса)*, мин тагын да яхшырак укырга тырышырмын.
6. Яхшы укырга … *(тырышсам)*, белемем артыр.
7. Белемем … *(артса)*, уңышка ирешермен.
8. Уңышка … *(ирешсәм)*, укытучым минем белән горурланыр.

**V. Белемнәрне гомумиләштерү**

– Мине игътибар белән тыңладыгызмы икән, хәзер тикшереп карыйк.

– Укучылар, өйрәнгән тема буенча кластер төзик. Эшне иптәшегез белән үтисез. Бирелгән 2 карточкадан шарт фигыль темасына кагылганын сайлап алыгыз.

*1 нче парта*

**– бер фигыльдән аңлашылган эшнең яки хәлнең үтәлү-үтәлмәвенә шарт булган эш-хәлне белдерә;**

**– сөйләм вакытында чынбарлыкта үтәлә яки үтәлми торган эшне белдерә.**

*2 нче парта*

**– -са/-сә кушымчасы;**

**– -ды/де, -ты/-те кушымчалары.**

*3 нче парта*

– **затланышлы;**

– **затланышсыз.**

*4 нче парта*

– **Нишләсә? Нишләмәсә?**

– **Нишләде? Нишләмәде?**

Кластер төзү.



Схема буенча нәтиҗә ясыйбыз.
Карточканы дөрес сайлаган булсагыз, үзбәя битенә + куябыз.

**3 нче язма эш: тест үтәү.**

1. Шарт фигыль нәрсәне белдерә?
а) эш-хәрәкәтнең максатын;
ә) эш-хәрәкәтне үтәүнең шартын;
б) эш-хәрәкәтнең билгесен.

2. Шарт фигыль нинди кушымчалар ярдәмендә ясала?
а) -ма, -мә;
ә) -ды,-де;
б) -са,-сә.

3. Фигыльләрнең төрен билгеләргә: *Керсә, әйтсә, белсә, аңласа.*
а) хикәя фигыль;
ә) боерык фигыль;
б) шарт фигыль.

4. *Уйна, кер, укы, яз* нинди фигыльләр?
а) хикәя фигыль;
ә) боерык фигыль;
б) шарт фигыль.

5. Кайсы фигыль төркемчәсе заман белән төрләнә?
а) шарт фигыль;
ә) хикәя фигыль;
б) боерык фигыль.

**Тестны шаблон буенча тикшерү.**
*Слайд буенча тикшерәләр.*
*Хатасызга – 1+.*

**VI. Рефлексия**

«Уңыш баскычы» алымы:
1 нче – шарт фигыль турында ишеттем һәм оныттым.
2 нче – ишеттем, ләкин аңламадым.
3 нче – күрдем һәм истә калдырдым.
4 нче – үтәдем һәм аңладым.
5 нче – шарт фигыльләрне сөйләмдә кулланырга башкаларны да өйрәтә алам.

**VII. Өй эше**

1. Кагыйдәне кабатларга, кагыйдәләр дәфтәренә шарт фигыль моделен ясарга.
2. 43 нче бит, 60-1 нче күнегү, бирелгән җөмләләрдән шарт фигыльләрне табып, астына сызарга.
3. Шарт фигыльләр кулланып, көндәлек тормышта күзәтелгән диалог төзергә.

***Үзбәя бите***
*Исем*____________________

| *№* | *Эш төрләре* | *Билге* |
|---|---|---|
| *1* | *Сүзлек белән эш* | |
| *2* | *Таблица тутыру* | |
| *3* | *Шарт фигыль белән җөмлә төзү.* | |
| *4* | *Тест* | |

***Таблицаны тутырыгыз***

| Фигыль | Сорау | Барлыкта-юклыкта | Шарт фигыль кушымчасы | Зат-сан |
|---|---|---|---|---|
| Өйрәнмәсәм | | | | |
| Тыңласак | | | | |
| Санасагыз | | | | |

1. Укытучыны игътибар белән ..., шарт фигыльне кулланырга өйрәнермен.

2. Шарт фигыльне кулланырга ..., сөйләмем бай булыр.

3. Сөйләмем бай ..., мин гел татарча сөйләшермен.

4. Гел татарча ..., әбием минем өчен шатланыр.

5. Әби минем өчен ..., мин тагын да яхшырак укырга тырышырмын.

6. Яхшы укырга ..., белемем артыр.

7. Белемем ..., уңышка ирешермен.

8. Уңышка ..., укытучым минем белән горурланыр.



**Гөлнара СӨНГАТОВА,**

Әтнә районы Күәм урта мәктәбенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

13

# Бәйлек сүзләр темасын кабатлау

(6 нчы сыйныфта татар теле дәресе)

**Максатлар:**

***Коммуникатив максат*** – авазларны кулланып, бәйлек сүзләрне дөрес әйтү, сүз байлыгын арттыру.

***Фәнни максат*** – бәйлек сүзләрне сөйләмдә куллану күнекмәләрен гомумиләштерү, ягъни ныгыту.

***Тәрбияви максат*** – биремнәрнең эчтәлегеннән чыгып, өлкәннәргә хөрмәт, бер-береңә ихтирам хисе тәрбияләү.

**Бурычлар**: авазларның һәм бәйлекләрнең дөрес әйтелешен, язылышын үзләштерү һәм ныклы күнекмәләр формалаштыруга игътибарны юнәлтү; бәйлекләрне татар, рус телләрендә чагыштыру, рус телле балаларның сүз байлыгын арттыруга юнәлеш бирү.

**Укыту ысуллары**: аңлату-күрсәтү, өлешчә эзләнү ысуллары.

**Җиһазлау**: карточкалар, тематик презентация, дәреслек, интерактив такта.

**Дәреснең тибы**: катнаш белемнәрне ныгыту.

**Дәрес барышы**

**I. Уңай психологик халәт тудыру**

– Исәнмесез, укучылар! Әйдәгез, бер-беребезгә хәерле көн телик!

Хәерле көн миңа! Хәерле көн сиңа!
Хәерле көн сезгә! Хәерле көн безгә!
Хәерле көн барчабызга!!!

**II. Теманы ныгыту, системага салу**

– Укучылар, бүген мин сезне «Хәзинәләр утравына» («Остров сокровищ») сәяхәткә чакырам! Сезне сәяхәтебезнең тәртибе белән таныштырып китәм. Безнең утравыбыз утраучыклардан торыр. Һәрбер утраучыкта безгә биремнәр үтәргә кирәк. Сез әзерме? *(Әйе!!!)*

– Димәк, без беренче утраучыгыбызга сәяхәтебезне башлыйбыз. Бу утраучык – «Исеңә төшер» утраучыгы. Биредә авазларны, сүзләрне дөрес әйтә белергә тиешбез. Әйдәгез, сүзтезмәләрне кабатлыйбыз:

*Тәлинкә астында; чынаяк янында; өстәл уртасында; өстәл өстендә; өстәл астында.*

– Хор белән. Төркем-төркем. Аерым-аерым. Молодцы. Булдырдыгыз! Бу сынауны үттек. Исегездә калдырыгыз, әле бу сүзтезмәләр алдагы утраучыклардагы биремнәрне үтәргә ярдәм итәчәкләр!

– Әйдәгез, 2 нче утраучыкка юл тотыйк. Ул утраучык «Фикер алышу» дип атала.

Рәсемгә карап, сорауларга җавап бирергә кирәк:

1. Укучылар, сезнеңчә, гаиләдә нинди көн? *(Туган көн.)*
2. Ни өчен шулай уйлыйсыз? *(Чөнки торт, конфетлар, җиләк җимеш.)*
3. Торт кайда куелган? *(Өстәл уртасында.)*
4. Кашык кая куелган? *(Тәлинкә янында.)*
5. Ә урындыклар кая тора? *(Урындыклар өстәл янында.)*

– Өстәл өстендә нәрсәләр бар? *(Пирог, җиләк-җимеш, тәлинкә.)*

– Торт кая тора? *(Өстәл уртасында.)*

– Кашык кая куелган? *(Чынаяк янында.)*

– Табын янында кемнәр утыра? *(Өстәл янында әби, әни, аю баласы утыра.)*

– Димәк, дәресебезнең темасы – «Минем туган көн бәйрәме» һәм бәйлек сүзләр. Хәзер дәфтәрләрегезне ачып, бүгенге числоны языгыз. Сыйныф эше.

– Ягез әле өченче – «Дөрес кушымчаны сайлап ал» утраучыгына барыйк. Моның өчен дәреслектән 100 нче биттәге 3 нче күнегүне үтәргә кирәк.

– Настя, үскәнем, биремне укы әле? *(Проставить пропущенные окончания.)* Бу биремне үтәү өчен, сезгә 3 минут вакыт.

1. Табын уртасы... матур вазада чәчәкләр. 2. Ул тәрәзә алды... басып тора. 3. Шәһәр уртасы... тимер юл үтә. 4. Күл яны... камышлар үсә. 5. Мәктәп алды... чәчәкләр утырттык. 6. Парта өсте...ге китапларны алды.

– Тәмамладыгызмы, балалар? Тикшереп алыйк. Слайдка карагыз.

– Афәрин. Булдырдыгыз!

– Сәяхәтебезне дәвам итеп, «Уйлап тап утраучыгы»на килеп җиттек. Анда без тәрҗемә итәрбез. Сары карточкаларны алдык.

*Табын артында – за столом.*
*Өстәл янында – около стола.*
*Өстәл астында – под столом.*
*Өстәл өстендә – над столом.*
*Шкаф эчендә – внутри шкафа.*

– Дөреслеген тикшереп алыйк әле, укучылар. *(Таблица.)*

– Рус телендәге предлоглар исемнең алдыннан килә, ә татар телендә бәйлек сүзләр исемнән соң килә. Аермасы шунда.

– Хәзер шушы сүзтезмәләр белән җөмлә төзибез.

*Женя табын артында чәй эчә.*
*... өстәл астында ... ...*
*... өстәл янында ... ...*
*... өстәл өстендә ... ...*

– «Ял утраучыгы». (*Җыр куела. «Туган көн» (Крокодил Гена.)*

– Яңа көчләр белән «Хикәя» утраучыгына күчик.

*Бүген Фәридәнең туган көне. Әнисе иртән бик матур торт пешерде, өстәлгә тәмле-тәмле ризыклар куйды. Өйләре дә искиткеч матур бүген. Тиздән аның дуслары да килер. Фәридә әнисе янына кухняга керде:*

*– Әни, әйдә, бүген әбием минем кунакларым янына чыкмасын. Бүген кунаклар бүлмәсе бик матур, анда бөтен нәрсә яңа, ә әби шундый карт, матур түгел.*

*Фәриданең әнисе сүзсез калды. Аңа бик авыр, кызы өчен оят иде.*

*– Фәридә, дусларыңа шалтыратып әйт: бүген туган көнеңне уздырмыйбыз.*

– Хәзер, укучылар, чылбырлап укыйбыз, тәрҗемә итәбез.

– Ни өчен гаиләдә туган көнне уздырмыйлар? *(Көтелгән җавап: Фәридә әбисеннән ояла.)*

– Ничек уйлыйсыз Фәридә әбисен яратамы?

– Сез әбиегезне чакырыр идегезме?

– Димәк, укучылар, олыларны яратырга, хөрмәт итәргә һәм алар белән горурланырга кирәк.

– Бу сынауны да уңышлы гына үттек! Хәзер «Син – миңа, мин – сиңа» утраучыгында сезнең туган көнегез турында сөйләшеп алыйк әле!

– Туган көнегез кайчан?

– Кемнәрне чакырасыз?

– Нинди бүләкләр бирделәр?

– Рәхмәт, укучылар! Сезне соңгы «Белемеңне тикшер» утравына килеп җитүебез белән котлыйм.

**III. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту этабы**

– Хәзер тест эшләп алырбыз.

**Тест**

1. Артык сүзне табыгыз. (Найдите лишнее слово.)
а) алдында; ә) өстендә; б) астында; в) киткәнче.

2. Сүзнең дөрес тәрҗемәсен табыгыз. (Найдите правильный перевод.)
*Котлыйм*
а) прощаюсь; ә) поздравляю; б) помогаю; в) покупаю.

3. Туры килгән сүзне табыгыз.
*Якшәмбе көнне мин әнием ... кунакка бардым.*
а) аркылы; ә) янында; б) белән; в) уңда.

4. Пригласи друга на день рождения!

**IV. Дәресне йомгаклау**

1. Нәтиҗә ясау.

– Рәхмәт, укучылар! Дәрес сизелми дә үтеп китте. Хушлашырга вакыт җитте. Әйдәгез, укучылар, дәресебезгә нәтиҗә ясыйк. Без бүген дәрестә нишләдек? *(Бәйлек сүзләрне кабатладык.)* Тагын диалог сөйләдек, тагын нишләдек? Ошадымы?

2. Билгеләр кую.

*Клад – хәзинә.*
*Рәхмәт миңа!*
*Рәхмәт сиңа!*
*Рәхмәт сезгә!*
*Рәхмәт безгә!*
*Рәхмәт барчабызга!*



**Антонида ВАСИЛЬЕВА,**

Алексеевскидагы 2 нче урта мәктәпнең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

14

# Бакый Урманче – җырлы, моңлы, шигъриятле, озын гомер юлы үткән шәхес

(7 нче сыйныфта әдәбият дәресе)

**Максат:**

***Белем бирү максаты:*** укучыларны Бакый Урманченың тормыш юлы, эшчәнлеге һәм иҗат сәхифәләре белән таныштыру.

***Үстерү максаты:*** бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү; чагыштырып, аермалыкны таба белү кебек фикерләү сәләтен үстерү; коммуникациягә керү сәләтен үстерү.

***Тәрбия максаты:*** балаларда татар халкының бөек шәхесләренә, аларның иҗатына кызыксыну уяту; сирәк очрый торган талантка ия булган сынчы иҗаты белән горурлану хисләре тәрбияләү; әхлак тәрбиясе бирү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Метапредмет:***

*Танып белү УУГ:* уку максатын мөстәкыйль билгеләү, темага караган лексиканы кулланышка кертеп, тиешле мәгълүматны табу, нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру.

*Коммуникатив УУГ:* үз фикереңне әйтә һәм дәлилли белү, әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү.

*Регулятив УУГ:* дәреснең темасын һәм максатын формалаштыру; уку мәсьәләсен кую, бәяли алу, төзәтү.

***Шәхескә кагылышлы:*** белем алуга мотивация формалаштыру, татар теленә карата кызыксыну уяту.

**Җиһазлау:** Бакый Урманче портреты, Бакый Урманче әсәрләренең фотокүчермәләреннән күргәзмә (тормыш юлы, картиналары, сыннары, график эшләре), компьютер, проектор, экран, магнитофон, «Мәңгелек моң» – кассета, укучыларның иҗади эшләреннән күргәзмә; «Б. Урманченың рухи дөньясы» китабы, Казан, 2005 ел, «Казан» журналы, «Мәгариф» журналы.

***Эпиграф:***

Әй, адәм... әүвәл мал җыясың комсызланып,
Аннары кол буласың шул малыңа;
Картаясың малыңа сакчы булып,
Барысын да калдырасың үзең үлеп.

*Б. Урманче*

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру** (уңай психологик халәт тудыру)

Дәрестә кулланырга тиешле кагыйдәләр искә төшерелә:

а) игътибар белән тыңла, бүлдермә;
ә) тулы җөмләләр белән сөйлә;
б) кеше фикерен тыңла, үз фикереңне әйт.

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

– Укучылар, үткән дәрестә без сезнең белән Бакый Урманче биографиясен кыскача гына карап киткән идек. Өй эше итеп, сезгә аның биографиясен укып килергә, теләгән кешеләргә аның турында өстәмә материаллар табып, берәр шигырен ятлап килергә кушылган иде. Дәрес барышында без аларны барысын да тикшереп, карап китәрбез.

Иң элек без аның биографиясенә тукталырбыз һәм әңгәмә уздырып алырбыз. Укучылар, сүзне сезгә бирәм.

**1 нче укучы.** Бакый Идрис улы Урманче 1897 елның 23 февралендә хәзерге Буа районы Күл Черкене авылында мулла гаиләсендә туа. *(Рәссамның портреты, туган елы экранда күрсәтелә.)* Башлангыч белемне әтисеннән ала. Аннан соң «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Әнисе – нәкышьче, бабасы – буяучы, әбисе җыр-бәеткә оста кешеләр булалар. Рәссам кечкенәдән үк рәсемнәр ясап, балчыктан төрле уенчыклар әвәләп уйный торган булган. Бигрәк тә агач белән эш итәргә яраткан. *(Экранда слайдлар күрсәтелеп бара.)*

**2 нче укучы.** Үсә төшкәч, өйгә кирәк-яракларны үзе ясый башлый. Урындыклар, умарта ояларын да үз куллары белән ясый. Искиткеч гаҗәеп уен коралы – скрипканы да үзе ясый, чөнки аның скрипкада уйнарга теләге була.

**3 нче укучы.** Гаиләсенә матди ярдәм күрсәтер өчен, Уралга һәм

Донбасска бара. Ул анда мөгаллимәлек итә. Шуннан соң армиягә алына һәм Казахстанда хезмәт итә. Ул анда рәсем ясау буенча беренче дәресләрен ала. Аның иҗаты нәкышь, пейзаж, скульптура, графика, шәмаилләр, рәсем сәнгатен һәм башкаларны үз эченә ала.

1917–1918 елларда Наркомпрос инструкторы булып эшли, клублар, мәктәпләр һәм бәйрәм демонстрацияләрен бизәү өчен лозунг һәм нәфис паннолар ясый.

**4 нче укучы.** 22 яшендә Бакый Урманче Казан сәнгать мәктәбенә укырга керә. Бер елдан соң Мәскәүгә күчә. Берьюлы ике факультетта укый – нәкышь һәм скульптура.

1926 елда укуын тәмамлап, Казанга кайта. Монда аның иҗади эшчәнлеге башлана. Бер үк вакытта сәнгать техникумында педагоглык эше алып бара.Шушы вакыттан башлап, ул 70 елдан артык гомерен сынлы сәнгатькә багышлаган.

**5 нче укучы.** 1929 елда милләтчелектә гаепләп кулга алалар. Аны Соловкига җибәрәләр. Ул анда авыр шартларда яши. Монда да бизәү эшен дәвам итә.

Азат ителгәннән соң, 1933–1934 елларда Мәскәүдә яши һәм эшли. Аның эшләре күргәзмәгә куела. «Творчество» журналы һәм «Комсомольская правда» газеталарында фоторәсемнәре урнаштырыла. *(Слайдта күрсәтелеп бара.)*

**6 нчы укучы**. 1958 елда Казанга кайта һәм соңгы көненә кадәр шунда яши. Бакый Урманче 100 дән артык скульптура әсәрләре, 300 гә якын нәкышь картиналарын иҗат иткән. Инглиз, француз, алман телләрендә укый алган.

Бакый Урманченың ике хатыны булган. Беренче гаиләсе Мәскәүдә яшәгән, Казанга кайтмаган. Ике улы булган: Илдар һәм Айдар. Казанда Флора Әхмәтовага өйләнә. Ул аңардан күпкә яшьрәк. Аңа багышлап шигырьләр яза. *(«Беренче очрашу» шигырен такта янында бер укучы сәнгатьле итеп укый.)*

**7 нче укучы.** Бакый Урманче 1990 елның 6 августында 93 яшендә вафат була. Республикада аның исемендәге премия булдырылды. 1998 елда Казанда Бакый Урманче музее ачылды. *(Музей рәсеме күрсәтелә.)*

1997 елның 28 февралендә рәссамның 100 еллыгына Казанның Зур Кызыл урамында скульптор Мәхмүт Гасыймов ясаган һәйкәл ачылды. *(Һәйкәлнең рәсеме күрсәтелә.)*

– Рәхмәт, укучылар. Менә без Бакый Урманченың тормыш юлын тагын бер кат искә төшереп киттек. Безнең бит әле ике укучыбыз эзләнү эше буенча үзләренең эшләрен алып килгәннәр. Әйдәгез әле, аларны да тыңлап китик.

**1 нче укучы.** Мин бу дәрескә «Соловки һәм казах дусларым» дигән темага материал таптым. Ул интервью формасында бара. Б. Урманченың хатирәләре. *(Кыскача сөйләп китә.)*

**2 нче укучы.** Мин аның әле бик күп картиналары, сыннары, җырлары, шигырьләре барлыгын белдем. *(Рефератын күрсәтеп, кыскача сөйләп китә. Укучылар сөйләгәндә, слайдлар күрсәтелеп бара.)*

**III. Яңа темага кереш**

– Укучылар, материалларыгыз бик бай, бик әйбәт итеп эшләнелгән. Рәхмәт сезгә. Чыннан да, укучылар, Бакый Урманченың бик күп картиналары, сыннары, график эшләре булган. Менә шуларны карап үтәр өчен, тагын да күбрәк белер өчен, бүгенге дәрестә без сезнең белән читтән торып музейга экскурсия оештырырбыз. Берничә эше турында безгә экскурсоводлар сөйләр, ә инде калганнарын компьютерда слайдлар формасында карап үтәрбез. *(Укучыларның игътибары эпиграфка юнәлтелә. Барысы бергә укыйлар.)*

– Бу эпиграфта нәрсә турында язылган?

– Кеше байлык, мал җыяр өчен генә яшәргә тиеш түгел. Ул рухи байлыкка омтылырга тиеш. Рухи байлык – иң зур хәзинә. *(Русча да әйтергә кирәк.)* Менә без музейга килеп тә җиттек.

**Экскурсовод.** Исәнмесез, укучылар. Бу – безнең музеебыз. Бик матур, якты һәм чиста. Ул Щапов урамы, 20 нче йортта урнашкан. Без: «Яңа татар поэзиясенә һәм татар музыкасына нигез салучылар кемнәр?» – дип сораганда, «Беренчесе – Тукай, икенчесе – Сәйдәш» – дип җавап бирсәк, инде: «Татар сурәтчелек сәнгатенең нигез салучысы кем?» – дигәндә, «Бакый ага Урманче, – дип, бүген хаклы рәвештә әйтә алабыз. Ул гомере буе тылсымлы сәнгать төрләрен ачкан. Бакый Урманче үзенең табигать биргән сәләте, тырыш хезмәте һәм югары белеме белән меңнән артык график эш, 300 гә якын картина, 100 дән артык скульптура иҗат иткән. Музей берничә бүлмәдән тора. Менә монда аның тормыш юлы күрсәтелә. Биредә аның картиналары. Монда сыннары. Ә монда график эшләре. *(Өч өлешкә бүленгән тактада рәсемнәр.)* Бакый Урманченың иң зур картинасы «Татарстан» дип атала. Ул өч полотнодан тора. Берсендә борынгы һәйкәлләр һәм Болгар иленең башкаласы тасвирлана. Икенчесендә православие монастыре белән Зөя тасвирлана. Үзәк полотнода – Сөембикә манарасы белән Казан.

**1 нче укучы**. Бу – Кол Гали портреты. «Йосыф – Зөләйха» поэмасының авторы. Портретны язу өчен рәссам поэманың эчтәлеген өйрәнә. Нәтиҗәдә бай шагыйрь портреты туа.

**2 нче укучы.** Бу – Сөембикә образы. Бакый Урманче бу образны, хатын-кызларны ясарга бик яраткан. Аларны кызганган, яклаган. Бу сын юкә агачыннан ясалган. Сәнгатьнең бу төре нәкышь дип атала.

**3 нче укучы.** Бакый Урманче үзенең һәр яңа эшен шигырь юллары белән башлый торган булган:

*Күңел багладым эшем уңасына,*
*Тәвәккәл иттем Кодрәт Иясенә.*
*Өметем камил, ышанычым нык*
*Бу фәкыйрьгә бәхет иңәсенә.*

Ул портретларны буяу юлы һәм график юлы белән язган *(сызыклар ярдәмендә)*. Экранда үзенең автопортретын күрәсез.

– Рәхмәт, балалар. Хәзер танышуыбызны дәвам итеп, компьютерда слайдлар карап үтәрбез. *(Комментарий ясап барам.)*

1. Рәсемдә Казандагы Бакый Урманче музееен күрәсез. Ул Казанда, Щапов урамында, 20 нче йортта урнашкан.
2. Музей вестибюле.
3. Скульптура залы.
4. Нәкышь залы.
5. Музейда этнографик күренешләр.
6. «Печән базары» картинасы.
7. Галина Казанцева, җырчы.
8. «Сепаратор янында» картинасы.
9. Кырлайда Тукайның мемориаль музее.
10. Ш. Мәрҗани.
11. Г. Ибраһимов, язучы.
12. М. Гафури.
13. С. Сәйдәшев.
14. Ф. Әмирхан.
15. Ф. Әхмәтова-Урманче. *(Б. Урманченың хатыны.)*
16. Бакый Урманче үзенең автопортретын да ясаган. Ул портретларны буяу һәм график юл белән ясаган. Графика – буяусыз, сызыклар һәм штрихлар белән генә рәсем ясау дигән сүз.
17. Г. Тукай һәйкәле *(бронзадан эшләнгән)*.
18. Тукай бюсты *(бронзобетон)*.
19. Ш. Мәрҗани *(гипс)*.
20. Дәрдемәнд *(мәрмәрдән эшләнгән ярымфигура)*.

Бу сыннар Б.Урманче музеенда саклана.

21. Шәмаил *(экранга шәмаилләр турында язу чыга)*. Ислам динен

тотучыларда изге дип саналган урыннарның рәсеме төшерелә, матурлап догалар языла һәм стенага элү өчен рамга куела. *(Русча да әйтергә кирәк.)* Менә бу – «Туган тел» җырының шәмаиле. Җырның бер куплеты тыңлана, балалар кушылып җырлый алалар.

22. Бакый Урманченың китапханәсе дә бай булган. Анда меңләгән китап саклана.

**Укытучы.** Укучылар, сезгә музей ошадымы?

– Музейның адресы ничек?

– Иң зур картинасы ничек атала?

– Баки Урманче кемнәрнең сыннарын ясаган? *(Г. Тукай, Н. Исәнбәт, Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Г. Камал.)*

**IV. Теманы ныгыту**

– Хәзер без сезнең белән диалоглар төзербез. *(Парлап эшлиләр.)*

– Бакый Урманче бит әле җырларга да бик яраткан. «Әгәр рәссам булмасам, мин җырчы булыр идем», – дигән. Аның яраткан җырлары «Ончы Фәхри», «Иске кара урман», «Тәфтиләү» булган. Мин сезгә «Ончы Фәхри» җыры турында сөйләрмен, аннан соң без аны тыңларбыз.

**Сораулар:**

1. Сезгә җыр ошадымы?
2. Яраткан җырларын әйтегез.
3. Тыңлаган җыр ничек атала?
4. Ул нәрсә турында?

**V. Шигырьләр уку**

– Бакый Урманче бит әле шигырьләр дә язган.

– Сез соң шигырьләр дә язасызмы, дигәч, бер интервьюсында, минем шигырьләрем күп, тик мин аларны үзем өчен генә яза идем, дип җавап биргән. Мин сезгә үткән дәрестә теләгән укучыларга бер шигырен ятлап килергә кушкан идем. Әйдәгез, аларны тыңлап китик.

*(Укучылар сөйлиләр.)*

– Рәхмәт, укучылар. Шигырьләрне бик матур, сәнгатьле итеп сөйләдегез. Миңа бик ошады.

**VI. Нәтиҗә ясау**

– Укучылар, без бүген дәрестә нинди зур шәхес турында сөйләштек?

– Ул кем булган?

– Бакый Урманче нәрсәләр иҗат иткән?

– Бакый Урманченың тууына быел ничә ел булды?

Укучылар, без бүгенге дәрестә читтән торып Бакый Урманче музеена экскурсиягә бардык. Аның картиналары, сыннары белән таныштык. Шигырьләрен укыдык, яраткан җырлары турында сөйләшеп, аларны тыңлап үттек. Без сезнең белән үзебезнең иҗади эшләребездән күргәзмә оештырдык. Сезнең арада да бик матур итеп рәсем ясаучылар бар. Бәлки кайберләрегез киләчәктә рәссам, скульптор да булып китәр.

Сезнең белемнәрегезне тикшерү өчен мин сезгә ***тест*** әзерләдем.
Шуларга карап билгеләр куярмын.

1. Б. Урманче ничәнче елда туган?
а) 1890;
б) 1897;
ә) 1894;
в) 1900.

2. Кайсы районда туган?
а) Буа;
в) Алексеевск;
ә) Чистай;
г) Аксубай.

3. Иң зур картинасы ничек атала?
а) «Сабантуй»;
б) «Семипалатинск»;
ә) «Татарстан»;
в) «Башкорт йорты».

4. Бакый Урманче музее кайсы урамда урнашкан?
а) Г. Тукай;

б) М.Җәлил;
ә) Щапов;
в) А. Пушкин.

5. Хатынының исеме ничек?
а) Мөршидә;
б) Флора;
ә) Фәридә;
в) Зөһрә.

6. Ничә малае булган?
а) 1;
б) 3;
ә) 2;
в) 4.

7. Яраткан җырлары:
а) «Туган тел»;
б) «Тәфтилләү»;
ә) «Random Фәхри»;
в) «Иске кара урман».

8. Кайда хезмәт итә?
а) Казахстанда;
б) Донбасста;
ә) Уралда;
в) Тамбовта.

9. Ничәнче елда Казанга кайта?
а) 1950;
б) 1956;
ә) 1954;
в) 1958.

10. Бакый Урманче музее Казанда ничәнче елда ачыла?
а) 1998;
б) 2000;
ә) 1999;
в) 2001.

11. Ничә яшендә вафат була?
а) 90;
б) 93;
ә) 94;
в) 92.

12. Ничәнче елда Зур Кызыл урамында мәшһүр сынчының бронза һәйкәле куела?
а) 1996;
б) 1998;
ә) 1997;
в) 1999.

13. Бакый Урманче ничә нәкышь картинасы иҗат итә?
а) 100 гә якын;
б) 300 гә якын;
ә) 200 гә якын;
в) 400 гә якын.

14. Күпме скульптура әсәре иҗат итә?
а) 50 дән артык;
б) 200 дән артык;
ә) 100 дән артык;
в) 300 дән артык.

**VII. Өй эше**

Бакый Урманче музеена бару турында монологик сөйләм төзергә.

Бакый Урманче иҗаты буенча диалог төзергә.

Берәр картинасы буенча сөйләргә.

**Алсу ХӘМИДУЛЛИНА,**

Кайбыч районы Олы Кайбыч урта мәктәбенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

15

# Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясе

(7 нче сыйныфта әдәбият дәресе)

**Дәреснең максатлары:** 1) жанр буларак драма әсәре турында күзаллау формалаштыру, билгеләрен аерып күрсәтә белү, Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәре белән танышу, әсәрнең сәнгатьчә эшләнешен аңлату, автор позициясен аерып чыгару; 2) әсәрнең мәгънәсен, образлар системасын аңлау күнекмәләрен камилләштерү, укучыларда күзәтү, анализ ясау, эзләнү, чыганаклар белән эшләү кебек яңа эш ысуллары формалаштыру.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

***Шәхескә юнәлтелгән:*** укучы телнең байлыгын һәм матурлыгын күреп, үз сөйләмен дә камилләштерергә омтылачак, әхлак сыйфатлары һәм нормаларының кыйммәтен таныячак.

***Метапредмет***

*Регулятив УУГ:* укытучы биргән юнәлеш ярдәмендә укучы куелган уку мәсьәләсен мөстәкыйль рәвештә анализларга һәм чишәргә өйрәнәчәк.

Уку мәсьәләсен чишү барышында танып белү эшчәнлеге белән мөстәкыйль шөгыльләнергә мөмкинлек алачак.

*Танып белү УУГ:* укытучы җитәкчелегендә укучы төшенчәләргә аңлатма бирәчәк, күзәтүләр үткәрәчәк, чагыштырачак.

Мөстәкыйль рәвештә эзләнүләр үткәрү, нәтиҗәләр чыгару, аргументлар китерү мөмкинлеге алачак.

*Предмет УУГ:* әдәби әсәрләрнең бер-берсе белән бәйләнештә булуын аңлаячак, әдәби әсәрне анализларга, кайсы жанрга каравын билгеләргә, темасын, идеясен күрсәтергә, диалогларның әһәмиятен аңларга, образларга характеристика бирергә өйрәнәчәк.

Сүз сәнгатенең образлы сөйләмен аңлау мөмкинлеген алачак.

**Дәрес барышы**

Уку эшчәнлегенә мотивация уяту.

– Хәерле көн, укучылар! Сезне күрүемә бик шатмын. Кеше шатланганда нәрсә эшли, укучылар. Елмая, әлбәттә, әйдәгез, бер-беребезгә карап елмайыйк һәм бергәләшеп кыска гына видео карап китик.

*(Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясеннән Әлмәндәр белән Әҗәлнең елмаю турында өзеге карап кителә.)*

– Укучылар, нинди спектакльдән өзек карап үттек. *(«Әлдермештән Әлмәндәр» спектакленнән өзек.)*

– Димәк, бу дәрестә нәрсә турында сөйләшербез? *(«Әлдермештән Әлмәндәр» әсәре турында.)*

– Әйе, укучылар, сез аны өйдә укып бетереп килергә тиеш идегез. Дәрескә нинди максат куярбыз, бүген нәрсә эшләрбез. *(Әсәрне анализларбыз, геройларга характеристика бирербез, авторы турында белгәннәрне искә төшерербез.)*

– Бик яхшы, укучылар. Сезнең алдыгызда бәяләү кәгазьләре, шунда дөрес җавапларны билгели барыгыз. Сезгә шундый сораулар әзерләнде:

**1 нче сорау.** Әсәр нинди жанрга карый? *(Драма төре, комедия.)*

**2 нче сорау.** Драма әсәренең нигезендә нәрсә ята? *(Конфликт.)*

**3 нче сорау**. Нәрсә ул конфликт? *(Каршылык.)*

**4 нче сорау**. Конфликт кемнәр арасында чыга? *(Әлмәндәр белән Әҗәл арасында.)*

**5 нче сорау.** Конфликтның сәбәбе нәрсәдә? *(Әҗәлнең алып китәсе килә, Әлмәндәрнең китәсе килми.)*

– Әйе, укучылар, афәрин, сорауларга дөрес җаваплар бирдегез, ә бу драма әсәрен кем язган соң, әйдәгез, бирелгән портретлар арасыннан язучыны күрсәтик әле, ул кем икән? *(Туфан Миңнуллин, уртада урнашкан.)*



– Ә калганнары кем? *(Беренчесе – Ибраһим Гази, өченчесе – Гомәр Бәширов.)*

– Туфан Миңнуллин кем соң ул? *(Ул – драматург, җәмәгать эшлеклесе.)*

– Сезнең алда язылган фактлар бирелгән, янәшә утырган иптәшләрегез белән шуларның кайсылары Туфан Миңнуллинга туры килмәгәнен сызып куегыз әле. *(Икенче факт дөрес түгел, ул Врангельгә каршы сугышта катнашмаган, 6 нчы факт дөрес түгел, «Туган ягым – яшел бишек» әсәрен Гомәр Бәширов иҗат иткән.)*




– Бик яхшы, бәяләү битенә дөрес җавапларны теркәп куегыз, хәзер әсәрдәге геройларны искә төшерәбез. Берәр кеше такта янына чыга һәм минем кулдан бер портретны ала, аны таныргa һәм аның исеменнән белгәннәрегезне сөйләргә кирәк.

– Мин – Әлмәндәр, 91 яшендә, Әлдермеш авылында улым һәм киленем белән яшим, дача салам. Рус-япон сугышында, 1914 елгы сугышта катнаштым, Бөек Ватан сугышы елларында колхоз рәисе булып эшләдем, 5 улым бар иде, 4 улым сугыштан кайтмады, беренче хатыным Йөзембикә дә, икенче хатыным да вафат булдылар һ.б.

– Мин – Илсур, 7–8 яшьтә, Әлмәндәр бабайның күршесе, мин аның янына еш керәм, ул мине бал, конфет белән сыйлый, ә мин аңа җырлыйм.

– Мин – Өммия, Әлмәндәр картның килене, Искәндәрнең хатыны. 7 бала үстердек, каенатам белән бергә яшибез, ул дача салам дип йөри, өйләнәм, ди. Без аның белән әйткәләшеп тә алабыз, 40 ел тел яшердем, 10 ел инде тел яшермим.

– Мин – Искәндәр, Әлмәндәр картның исән калган бердәнбер улы, 4 ел сугышта йөрдем, тәнем тулы яра эзе, хәзер бик авырыйм, эш эшли алмыйм.

– Мин – Гөлфирә, Әлмәндәр бабайның оныгының кызы, шәһәрдән кайтып йөрим, дәү бабаемны бик яратам, без аның белән серләребезне сөйләшәбез, әбием мине аңлап бетерми, авылда дус егетем Мансур бар.

– Мин – Хәмдебану, тол хатын, ялгыз яшим, Әлмәндәр абзый мине башкаларга кияүгә бирмәкче иде, хәзер үзем өйләнәм, ди, чыгаммы соң, сугышта һәлак булган иремне онытмыйм.

– Мин – Әҗәл, Әлмәндәр картны алырга килдем, ул, Ходай әмереннән узып, 1 ел артык яшәгән, бу инде 4 нче һәм соңгы килүем, 3 тапкыр ул мине алдап, качып киткән иде инде.

– Мин – Ефстигней, күрше Антоновка авылында яшим, Әлмәндәр карт белән урман юлында танышкан идек, аны колхоз төзегәндә кулаклар сәнәк белән кадаганнар иде, мин аны үлемнән коткардым, шуннан бирле без дуслар, ул безнең авылга, мин Әлдермешкә кунакка йөрешәбез.

*(Укытучы бу портретларны тактагаябыштыра бара, беткәч сорый.)*

– Укучылар, шушы геройлар арасында кайсыларын төп герой дип атарга мөмкин? *(Әлмәндәр һәм Әҗәлне.)*

– Әйдәгез, аларга чагыштырма характеристика бирик, алдыгызда яткан кәгазьләргә язып барыгыз. Аның өчен тексттагы сүзләргә игътибар итәбез.

**Төп геройларга характеристика бир**

| Әлмәндәр | Әҗәл |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

*(Укытучы җитәкчелегендә таблица тутырыла.)*

Ә л м ә н д ә р. Кәҗә маеңны чыгарамыни? Шулай ул. Ярый, ял итеп ал. Йә минем урынга үзең аягыңны сузарсың. Аннары җавап тот синең өчен теге дөньяда.

Ә җ ә л. Мин үлемсез. Үлемсез булу начар, Әлмәндәр. Үлү –зур бәхет ул. Сез кешеләр шуңа бәхетлеләр. Минем миллиард ел яшәвем сезнең бер ел гомерегезгә тормый. Сез төзисез, сез өмет белән яшисез. Минем өмет юк, мин – җимерүче.

Ә л м ә н д ә р. Җимермә, кем куша җимерергә!

Ә җ ә л. Булмаганны сөйләмә.

Ә л м ә н д ә р. Соң, явыз, минем оныкларым бар, оныкларымның уллары, улларының уллары бар. Мин үлгәндә алар минем янда булырга тиеш. Минем соңгы киңәшләремне ишетеп калырга тиешләр. Алар читтә, аларга хәбәр итеп өлгерергә кирәк.

Ә җ ә л. Ха! Яшисе килгән, имеш. Кемнең яшисе килми. Ләкин кеше мәңгелеккә килмәгән.

Ә л м ә н д ә р. Туктале, чурту-матыр, син монда... Бар, үтбәләвәй, эшемне калдырып йөрмә. *(Кулына ышкы ала.)*

Ә җ ә л *(Әлмәндәр кулындагы ышкыга тотынып)*. Мин шаярырга килмәдем, Әлмәндәр. Мин шаяра белмим.

Әлмәндәр аптырап Әҗәлгә карап тора да кинәт артка чигенеп куя.

– Бик яхшы, укучылар, әсәр барышында бу сыйфатлар үзгәрмиме соң? Үзгәрә, нәтиҗәдә Әлмәндәр бабай үлеме белән үлемсезгә әверелә, үзе үлсә дә башкаларга үрнәк гомере кала.

| Әлмәндәр | Әҗәл |
|---|---|
| Гомере чикле – | Үлемсез – |
| Төзүче | Җимерүче – |
| Игелек эшли, яхшы күңелле | Явыз- |
| Шаян, көлке сүзләр сөйли | Гел җитди, шаяра белми- |
| Әҗәлдән шүрли- | Әлмәндәрне куркыта – |

– Укучылар, ә тагын кемнәрне үлемсез дип әйтеп була? *(Сугыштагы батырлар үлемсез. Безнең бабайларыбыз Бөек Җиңү өчен гомерләрен дә кызганмаган, аларның исеме мәңгелек.)*

– Муса Җәлилләр, Абдулла Алишлар – үлемсез, алар корал белән генә түгел, каләмнәре белән дә дошманга каршы сугышып, исемнәрен үлемсез иткәннәр. Әйе, шул уңайдан 2025 ел Ватанны саклаучы елы дип игълан ителгән иде. Укучылар, дөньялар әле һаман тыныч түгел, авылыбыздан, районыбыздан бик күп ир-егетләребез Ватанны сакларга китте, кайберләре һәлак булды, сыйныфыбызда Сабинаның әтисе һәлак булды, сыйныфыбыз белән аны җирләргә бардык. Кече Мәми авылыннан Козин Владимир Николаевич һәлак булганнан соң Россия Герое исеменә лаек булды, без аларны беркайчан онытмабыз.

Муса Җәлилнең «Имән» шигырен искә алып китик:

*Җирдә кеше торса торсын,*
*Эзе калсын тирән булып.*
*Үзе үлсә, эше калсын,*
*Мең яшәрлек имән булып.*

***Өй эше.*** «Минем бабай (әби) язмышы» темасына сочинение язарга әзерләнеп килергә. *(Бабайның (әбинең) тормыш юлы. Иң шатлыклы, яки иң күңелсез вакыйгалары. Бабайның (әбинең) холкы, төсе, кыяфәте, кем булуы. Үзегезнең әби-бабайларыгыз булмаса, күрше яки танышлар турында мөмкин.)*

***Рефлексия.***

1. Бүген нәрсә турында сөйләштек?
2. «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәре белән автор безгә нәрсә әйтергә тели?
3. Әлмәндәр картның кайсы сыйфаты сезгә аеруча ошады?

– Дәрес тәмам, бәяләү кәгазьләренә билгеләрне куеп, җыеп алабыз, дәрестә катнашуыгыз өчен зур рәхмәт, киләсе дәрескә кадәр сау булыгыз.



**Энҗе ГАЛИУЛЛИНА,**

Балык Бистәсендәге 1 нче гимназиянең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

16

# Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» драмасында Муса Җәлил образы

(8 нче сыйныфта әдәбият дәресе)

**I. Оештыру-мотивлаштыру этабы**

– Хәерле көн, исәнмесез. Дәресебезне башлыйбыз.Үз фикерегезне әйтергә оялмагыз, курыкмагыз. Дөрес булмаса, юнәлеш бирербез, дөрес булса хупларбыз. Җавапларыгыз тулы булсын. Татар телендә җөмлә төзелешен истә тотып, җавап бирергә тырышыгыз. Һәрберегезгә интеллект карталар таратылган. Үзбәягезне һәр бирем саен билгеләп барыгыз.

Сезгә өй эше итеп, Туфан Миңнуллинның тормыш юлы һәм иҗатын укырга бирелгән иде. Экранга игътибар итегез.

*Экранда Туфан Миңнуллинның «Сәхнә картасы юлы» моделе.*




– Әлеге географик атамалар драматургның иҗатында нинди роль уйный? Дәреслектәге 42 нче биткә игътибар итегез. *(Аның драма әсәрләре илебезнең төрле почмакларында куелган.)*

– Фикерләрегез өчен рәхмәт. Укучылар, игътибарны тактага юнәлтәбез. Игълан-афишага күз салыгыз. Бүген Туфан Миңнуллинның нинди әсәре белән танышабыз? Игътибар белән карап, исемен, жанрын әйтегез. *(Туфан Миңнуллин. «Моңлы бер җыр».)*




– Әсәр белән эшли башлаганчы, драматург әйтергә теләгән фикергә – искәрмә – ремаркага тукталабыз.




– Әлеге әсәрнең үзенчәлеге драматург кулланган алымда. Язучы үз хыялы ярдәмендә вакыйгаларны башка дөньяга күчерә. Шагыйрь һәм Муса образлары тәңгәл килә, ягъни алар бер үк кеше – Муса Җәлил.

**II. Дәреслек белән эш**

– Дәреслегебезнең 44 нче битен ачабыз. Шагыйрь (үзалдына) сөйләшеп утырган өлешне укыйбыз, шигырьдә кабатлауларны, чагыштыруны эзлибез.

– Кайсы юллар кабатлана?

– Шагыйрь гомерен нәрсә белән чагыштыра? *(Моңлы бер җыр белән.)*

– Фикерләрегез дөрес.

– Драмадан видеоөзекне игътибар белән карыйбыз. Муса Җәлил өчен моңлы җыр нинди җыр ул? Рольләрне Г. Камал театры артистлары

башкаралар. Муса Җәлил ролендә – Әзһәр Шакиров.

– Укучылар, Муса Җәлил өчен моңлы җыр нинди җыр ул? *(Моңлы җыр кайгылы, хәсрәтле җыр түгел...)*

– Дәресебезне Алиш һәм Кормаш диалогын рольләргә бүлеп уку белән дәвам итәбез. *(53 нче бит.)*

– Алиш әйткәнчә, моңлы кеше нинди кеше? *(Моңлы булган кеше бәхетле кеше, кайгылы була алмый.)*

– Ә хәзер бу өч модельне берләштереп, без нинди нәтиҗә чыгара алабыз? *(Гомерем минем=моңлы җыр=кайгылы, хәсрәтле җыр түгел. Моңлы булган кеше – бәхетле кеше, кайгылы була алмый. Моңлы булган кеше – бәхетле кеше.)*

**– Ә тоткынлыктагы Муса өчен бәхет нәрсәдә? Диалогларны төркемнәрдә укып чыгыгыз, сорауга җавап табыгыз.** *(46–47, 49 нчы битләрдә.)*

– Шагыйрь бәхетлеме, ни өчен бәхетле? *(Ул туган ягына кайта. Ул туган ягына герой-шагыйрь булып кайта. Аны халык таный...)*

– Чыннан да, тоткынлыкта булган Муса Җәлил өчен шагыйрь һәм герой буларак халыкның ышанычын яулау – зур бәя.

**III. Рефлексия, бәяләү**

– Бирелгән репликалар эчтәлегеннән Мусаның характер сыйфатларын шагыйрь һәм герой буларак ачыклагыз.

**1 нче төркем. *Шагыйрь*** *Муса Җәлилнең характер сыйфатларын билгели.*

**2 нче төркем. *Герой*** *Муса Җәлилнең характер сыйфатларын ача.*

– Җавапларыгызны тыңлыйк.

– Муса Җәлил образы нинди кеше буларак  күз алдыгызда калды? Үзегездә кайсы сыйфатларын булдырыр идегез?

– Туфан Миңнуллин «Моңлы бер җыр» драмасында Муса Җәлилне безнең өчен камил шәхес итеп биргән. Ул – киләчәк буын кешесенә, ягъни безгә, юл күрсәтүче. Намусы, тугрылыгы, вөҗданы – аның исемен һәм батырлыгын бөтен дөньяга таныта һәм мәңгеләштерә.

– Дәресебез ахырына якынлаша, менталь карталарны тулыландырып, дәрестә ирешелгән максатларны билгеләп, нәтиҗә ясап, миңа тапшырыгыз. Сез бүгенге дәрестә игътибарлы, актив, кыю булдыгыз. Рәхмәт.



**Азалия ШИҺАПОВА,**

Чаллыдагы 4 нче мәктәпнең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

17

# Шамил Рәкыйповның «Чәчәкләр сөйли белә» әсәрен өйрәнү

(8 нче сыйныфта әдәбият дәресе)

**Максат**: 1) әсәргә анализ ясау; 2) мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтү, фикерләү тирәнлеге булдыру, фикерләрне җиткерә белүләренә ирешү; 3) үз-үзеңне тормышка әзерләү, Туган илгә мәхәббәт хисләре тәрбияләү, батырларны барлау, белү.

**Җиһазлау**: язучының портреты, дәреслек, «Чәчәкләр сөйли белә» дигән китаплар, дзот күренеше белән рәсемнәр, экран, проектор, ноутбук.

**Дәрес барышы**

**Оештыру. Уңай психологик халәт тудыру.**

– Исәнмесез. Яхшы кәеф, күңел күтәренкелеге телим. Үзебезнең белгәннәрне кыю итеп сөйлик. Булдыра алганча эшләү сәләтебезне күрсәтик.

Өйдә Шамил Рәкыйповның «Чәчәкләр сөйли белә» әсәрен укып килергә бирелгән иде. Хәзер бирелгән калып буенча әсәрне анализлыйбыз.

Эшне башлыйбыз.

1. Бу әсәр нинди жанрда язылган? *(Повесть жанрында.)*

2. Повесть жанры булуын раслыйк. *(Төп образ бер. Ул – Барый, вакыйгалар аның белән бәйләнештә бара. Бала чагы, мәктәп еллары, мәктәпне тәмамлау, колхозда эшләү, сугыш башлану, сугыш солдаты. Вакыт аралыгы озын.)*

3. Әсәр кайчан басылып чыга? *(1967 елда.)*

4. Бу чорда (вакытта) нинди вакыйгалар булган? *(Илдә идеологик басым бераз кими төшкән кебек була, ягъни партиянең өстән кушып яздыруы. Ләкин бу озакка бармый. Тиздән партиянең йогынтысы тормышның бөтен өлкәләренә үтеп керә. Бөек Ватан сугышы турындагы әсәрләр дәүләт кушуы буенча языла; геройлар күп булу аркасында, Җиңү яулануы турында сөйләнә. Ләкин тикшерү, эзләнү материалларына нигезләнгән объектив чынбарлык юк диярлек. Язучы шушы чордагы хәлләрне аңламый, тарихи моментларга мөрәҗәгать итә, үзе бәя бирергә тырышып карый. Корбаннарны (вафат булганнарны) акларга тырыша. Үзләрен корбан итүләре эзсез түгел.)*

5. Язучының иҗат югарылыгы нинди дәрәҗәдә? Матбугатта аның исеме ничәнче елларда күренә башлый? *(1956 елда. Хикәяләр, кечкенә күләмле сәхнә әсәрләре белән күренә.)*

6. Димәк, бу әсәрне язарга керешкәнче, исеме билгеле, үз сүзен әйтә башлаган язучы була. Әдәбиятта нинди әсәрләре белән урын били? *(Документларга нигезләнеп язылган әдәби әсәрләре белән: «Кайда син, Жан?», «Таңнар һаман матурмы?», «Кызлар-йолдызлар» һ.б.)*

7. «Чәчәкләр сөйли белә» повестеның язылу тарихы үзенчәлекле: Бөек Җиңүнең 20 еллыгы алдыннан СССР Кораллы Көчләренең Үзәк музеенда йөргәндә, тәмам саргаеп беткән бер листовкага очрый. Анда Барый Шәвәлиевнең Александр Матросов, Газинур Гафиятуллин батырлыкларын кабатлавы турында язылган була. Батырлык эшләнгән, ләкин билгесез булып калган. Шуннан Ш. Рәкыйпов аның турында материал туплый башлый. Архив документлары, истәлекләргә нигезләнеп, «Чәчәкләр сөйли белә» повестен иҗат итә. Барый Шәвәлиев – Татарстанның Балык Бистәсе районы Түбән Тегермәнлек авылында туып үскән егет.

**Сүзлек өстендә эш**.

**Дзот** – (һөҗүмнәрдән саклану өчен) оборона өчен җиргә казып, агачлар, ташлар белән ныгытылган (ут ноктасы) корылма, хәрби ныгытма. Анда якын килеп булмый, амбразура дигән җиреннән пулемёт өзлексез атып, сугышчыларны кырып кына сала.

**Амбразура** – хәрби ныгытмаларның (дзотның) стеналарында сугыш кырын күзәтү һәм ату өчен калдырылган махсус тишек, тәрәзә. Шул амбразурадан пулемёт көпшәсе чыгып тора. Амбразураны гәүдә белән каплаганда, сугыш кырын күзәтүгә мөмкинлек ябыла, ату тукталып, сугышчыларга алга ыргылу мөмкинлеге

туа *(бик аз вакытка гына).*

8. Әсәр нәрсә турында? *(Сугыш турында, батырлык эшләү турында, Барый турында.)*

9. Димәк, төп образ кем булды? *(Барый.)*

– Язучы безгә Барыйны ничек итеп бирә? *(Аны характерлаучы сыйфатларны язып барырга кушылган иде.)* Бернәрсәне искә төшереп китик: әсәр нинди иҗат методы белән язылган һәм аңа нәрсәләр хас? *(Социалистик реализм. Бу методка вакыйгаларны бизәп сурәтләү, образны берьяклы бирү, уңай сыйфатларны гына идеаллаштыру хас.)*

– Ә Барый ничек сурәтләнгән? *(Укучылар характер сыйфатларын әйтәләр: мәктәп укучысы; башлык, командир, лидер; аны тыңлыйлар.) (Үзенә карата belә, беркайчан да зарлана белми; пөхтә, чиста, матур яза; яхшы укый, тапкыр, зирәк,акыллы; юаш, оялчан, тыйнак, ләкин кирәк чакта кыюлык җитәрлек үзендә (иптәшләрен ант итүгә әзерләү өчен, төнлә зиратка керү; кулны кисеп, каннары белән ант итү һ.б.); үтә сабыр, тәртипле; чәчәкләр ярата.)*

– Укучылар, язучы ни өчен Барыйны чәчәк үстерүче итеп бирде икән? Чәчәк дигәч, безнең күз алдыбызда нинди күренеш туа соң? *(Матурлык күренеше килеп баса.)*

– Чәчәк нәрсә символы? *(Чәчәк – матурлык символы, күңел матурлыгы.)*

– Барый нәрсә тудыра? Аңа үзен чорнап алган тирәлектә нәрсә җитмәгән? *(Матурлык тудыра. Аңа матурлык җитмәгән.)*

– Бу матурлыкны ул нәрсәләрдән тапкан? *(Ул матурлыкны чәчәкләрдән таба.)*

– Чәчәкләр (биология) – тере затлар. Үз хуҗаларын көтәләр, үз куллары белән су сибүен телиләр, аны танйилар. Хуҗалары турында күп беләләр, кирәк икән аның турында сөйли дә алалар. Алга таба барабыз: Барый әти-әнисе, туганнары белән нинди мөнәсәбәттә? *(Хөрмәт итә, сүзләрен тыңлый; аларны бик ярата; әнисенә бик ярдәмчел (идән юа; самавыр чистарта; су ташый); энесенә бармак белән дә чиертми.)*

– Дуслары белән ничек аралаша? *(Ярдәмләшәләр, киңәшләшеп кенә эшлиләр; бер-берсе өчен борчылалар; Барый иптәшләренә авторитет булып тора. Барый турында уйлау да дусларына уңыш алып килә. Сихере бардыр, дип куялар. Үзара сугышу юк.)*

– Укучылар, төп героебызның уеннарга мөнәсәбәте ничек? Ул – бала. Баланың күңеле уенда. Фикеребезне әсәрдәге өзек белән дәлиллик. *(Төп нөсхә: 146 нчы биттәге өзекне уку.)*

– Аның уеннарга карата үз фикере бар. Нинди фикер? *(Уеннарны сайлап кына уйнарга, алар файда китерсен, батырлык тәрбияләсен, – ди дусларына Барый.)*

– Ни өчен ул уеннар файда китерергә тиеш дип исәпли? *(Үзеңне киләчәк тормышка әзерләү һәм алар аша батыр булырга өйрәнү өчен.)*

– Барый иптәшләренең нинди сыйфатларын үзендә булдырасы килә? *(Иптәшләре кебек оста итеп капчык киеп йөгерәсе һәм алка атып уйнауда беренче буласы килә.)*

– Әлеге сыйфатларны үзендә булдырдымы? *(Әйе, әйттеме – эшли ул. Моның өчен ул зур тырышлык куйды, һәр көнне шөгыльләнде, чөнки җиңү үзеннән-үзе генә килми бит.)*

– Барый 7 нче сыйныфны тәмамлады. 7 нче сыйныфны тәмамлау – мәктәпне тәмамлау, чөнки ул чорда җидееллык мәктәпләр була. Олы тормыш юлына чыгар вакыт җитте. Барыйның тормыш юлы ничек дәвам итә соң? *(Идарәгә хисапчы итеп алалар.)*

– Аның эшләве турында язылган өзекне укып та китик. *(Дәреслекнең 151 нче бите.)*

– Ни өчен аны шундый җаваплы эшкә алалар? *(Мәктәптә яхшы укыган, исәп-хисапны су урынына эчә; төгәл, пөхтә; өлгер, тырыш.)*

– Авылга нинди шомлы хәбәр килә? *(Сугыш башлану хәбәре.)*

– Әйе, 1941 ел, 22 июнь. Фашист

илбасарлары безнең илебезгә сугыш башлый. Халык алдында бер максат: илне азат итү. Авыл нинди хәлдә? *(Кайгылы; ир-атлар сугышка озатыла; авылда бала-чага, хатын-кыз, карт-коры гына кала.Ә инде 1943 елның гыйнвар аенда Барый солдат була, сугышка китә.)*

– Сугыш эчендә Барый нинди соң? Сугыш аны явызландырмадымы? *(Кыюлыгы артты; куркусыз, түземле, намуслы; киләчәкне дә кайгырта: урман кискәндә, агачларны өеп калдырырга куша.)*

– Язучы ни өчен урманны биргән? Нәрсә соң ул урман? Урман… берүзең… курку… Агачлар, агачлар. Алар артында нәрсә барын беләбезме? *(Юк, белмибез, ягъни агач артында нәрсә бары билгесез. Билгесезлек чорнап алган. Урман – билгесезлек символы.)*

– Укучылар, нәрсәләр билгесез? *(Исән калу-калмау.)*

– Тагын нәрсәләр билгесез? Сугыш кайчан башланды? *(1941 елда башланды. Хәзер 1943 ел. Җиңү көне билгесез. Илнең язмышы билгесез.)*

– Әйе, аларны билгесезлек чорнаган. Язучы шуны күрсәтер өчен, урманны биргән. Сугышта Барыйны кем итеп билгелиләр? *(Отделение командиры. Ул – җитәкче.)*

– Җитәкчегә кемне куялар? *(Башкалардан өстен дип табылган кешене.)*

– Барый кайсы яклары белән өстен? *(Иптәшләренә, өлкәннәргә хөрмәт белән карый; ярдәмчел, сугышка әзерләнгәндә (өйрәнү күнегүләре вакытында), арыган иптәшләренең винтовкасын үзенә ала; җитез, өлгер, тапкыр; сугыш өчен кирәкле нәрсәләргә өйрәтә; окопны да тизрәк казый.)*

– Үзенең иптәшләрен нинди кирәкле нәрсәләргә өйрәтә? *(Балачактагы уеннарын искә төшерә. Очып килә торган гранатаны тотып алып, кире фашистлар өстенә ташларга өйрәтә. Тормыш өчен бик куркыныч. Ләкин солдатлар куркып тормыйлар, Барыйны тыңлыйлар, өйрәнәләр.)*

– Игътибар иттегезме икән: һөҗүмгә күтәрелүне көткән вакытта Барый нәрсәләр күрә? *(Чәчәкләр.)*

– Әйе, солдатлар янында, Барыйлар янында – чәчәкләр… Чәчәкләр аларның сугыш юллары турында беләләр икән. Киләчәктә алар барысы турында да сөйләрләр. Соңгы һөҗүм вакытында Барый нинди адым ясады? *(Үз гәүдәсе белән дзот амбразурасын каплый, пулемёт аның гәүдәсен теткәләп ташлый.)*

– Бу вакыйганың бирелешен дәреслектән укыйк. *(155 нче бит, укучы укый.)*

– Укучылар, амбразура үзе кечкенә генә тәрәзә, ләкин шуннан килә торган фаҗига, шуннан эшләнә торган явызлык – искиткеч зур. Барый ни өчен шундый адымга барды соң? *(Башка юл юк, чөнки пулемёт дзотка кереп яшеренгән дә, котырынып, сугышчыларны кыра. Туган илне ярату.)*

– Нәрсә дигән сүз соң ул Туган ил? *(Әти-әниең, туганнарың, дусларың; авылың, урамың, кешеләрең; авылыңның табигате.)*

– Әйе, Барый барысын да ярата һәм бик сагына. Ләкин бу кемнәр кулына күчүе бар? *(Фашистлар кулына күчүе ихтимал.)*

– Барыйның максаты нәрсәдә? *(Туган илен фашистлардан азат итү өчен, гомерен бирде. Туган ил азатлыгы тизрәк җитсен дип, батырлык эшләде.)*

– Бу адымга бару бик җиңел булгандыр дисезме? *(Гомер бер генә! Һәркемнең яшисе килә. Барый да бу адымны ясаганчы, Туган иле алдындагы изге бурычы белән яшисе килү теләге аз тартышмагандыр. Балачактан үзен батырлык эшләүгә, югалып калмаска тәрбияләгән Барый, үз-үзен җиңеп, шушы батырлыгын эшләде.)*

– Менә шушы батырлар янында нәрсәләр үсә? *(Чәчәкләр. Алар сугышчыларның батырлыкларын күреп тордылар, шул турыда*

*халыкка, илгә сөйлиләр. Ә каберендәге чәчәкләр халыкның, илнең ихтирамын батырларга сөйлиләр.)*

10. Әсәрнең темасы нинди булды? Әсәр нәрсә турында? *(Әсәр батырлык турында.)*

11. Әсәрнең идеясе? *(Билгесез батырларны илгә, халыкка билгеле итү, аларны онытмау.)*

12. Проблемасы? *(Батырларны белү; билгесезләрне халыкка кайтару, чөнки билгесез батырлар күп.)*

13. Әһәмияте: а) идея-эстетик кыйммәте: (*Документларга нигезләнеп язылса да, төзек телле әдәби әсәр; сурәтләү чараларына бай; мәкальләр күп кулланган.)*

14. Әсәрдән үзегезгә нәрсә алдыгыз? *(Укучылар фикерен тыңлау.)*

15. Әдәбиятта бу әсәрнең әһәмияте? *(Сугыш, сугыш эчендәге кешеләр һәм алардан бер генә кеше дә билгесезлектә калмасын иде.)*

– Укучылар, һәлак булганнар истәлеге тереләр өчен кирәк. Дөнья тыныч түгел. Вакытсыз вафат булганнар турында даими сөйләргә кирәк. Алар онытылмаска тиеш. Украинадагы махсус хәрби операция башлану белән курку белмәс ир-егетләребез илебез сагына басты. Алар бүгенге көндә үз бурычларын намус белән үти. Аларның батырлыгы турында «Звезда» телеканалы документаль фильм төшерде. Хәзер шул фильмнан өзек карап китәрбез. *(Бу сугышта минем энем Касыймов Ринат Расих улы да катнаша, фильмда ул да бар.)* Сугыш тизрәк бетеп, ир-егетләребез исән-сау кайтсыннар иде. «Сугыш» дигән афәт башка кабатланмасын, меңнәрчә гомерләр вакытсыз өзелмәсен иде. Илебез тыныч, имин булсын иде дигән теләк белән, бүгенге дәресебезне йомгаклыйбыз.

**Билгеләр кую.**

**Өй эше.** Батырлык турында 5 мәкаль язып килергә.



**Гөлназ ШАГАЛИЕВА,**

Азнакай районы Актүбә 2 нче урта мәктәбенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

18

# Басым

(10 нчы сыйныфта татар теле дәресе)

**Дәрес тибы:** яңа уку материалы үзләштерү дәресе.

**Эшчәнлек формалары:** әңгәмә, дәреслек белән эш, парларда һәм төркемнәрдә эш.

**Максат:** орфоэпик нормаларны практик үзләштерү аша укучыларның сөйләм осталыгын формалаштыру.

**Бурычлар:** укучыларның фонетика турындагы белемнәрен гомумиләштерү һәм системалаштыру; телдән һәм язма сөйләмдә орфоэпик нормаларны үтәүнең мөһимлеген аңлау; укучыларның сөйләм культурасын үстерү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

***Предмет нәтиҗәләре:*** укучы басым турында белә; сүзләрне дөрес укырга, дөрес язарга мөмкинчелек ала.

***Шәхси нәтиҗәләр:*** укучыларда укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш булдырырга өйрәтү, иҗади активлыкларын эшкә җигү.

***Метапредмет универсаль уку гамәлләре:***

*Регулятив УУГ:* укучы яңа максат һәм бурычлар куярга өйрәнә; укучы максатка ирешүне планлаштыру, аның чараларын һәм шартларын үзлегеннән таба белү мөмкинчелеге ала, үзанализ һәм үзбәя булдыра.

*Танып белү УУГ:* укучы, кагыйдәләрне кулланып, сорауларга җавап бирергә өйрәнә; сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булдыру мөмкинчелеге ала; үз фикерен исбатлый һәм яклый алырга өйрәнә.

*Коммуникатив УУГ:* укучы, үз фикерен әйткәнче, төрле фикерләрне исәпкә алырга, чагыштырырга, нәтиҗә ясарга өйрәнә.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру**

– Исәнмесез, укучылар! Кәефләрегез ничек? Барыбызга да уңышлы көн телим. Дәрестә игътибарлы булыгыз, бер-берегезгә ярдәм итегез, актив катнашыгыз.

**II. Актуальләштерү**

– Укучылар, фонетика буенча белемнәрне тикшереп, кроссворд чишеп китик әле.



1. [ʿ](һәмзә) тартыгының ясалу урыны? *(Бугаз.)*

2. Сөйләмнең бүленми торган иң кечкенә берәмлеге. *(Аваз.)*

3. Сузык авазларның сүз эчендә охшашлануы. *(Сингармонизм.)*

4. Кояшның ... – төсендә, кешенең ... – эшендә. *(Матурлыгы.)*

5. Тартыкларның охшашлануы. *(Ассимиляция.)*

**III. Уку мәсьәләсен кую**

– Безнең төсле шакмаклар астында нинди сүз чыкты? *(Басым.)*

– Бүгенге дәрестә без нинди тема өйрәнәбез?

– Нәрсә ул басым? Сез басым турында нәрсәләр беләсез? *(Басым – сөйләмнең бер иҗеген башкалардан аерып әйтү. Ул иҗек составындагы сузык авазга төшә. Татар телендә басым соңгы иҗеккә төшә, сорау алмашлыкларында һәрвакыт беренче иҗектә була.)*

– Яхшы, балалар, рәхмәт. Бүгенге дәреснең максаты нинди булыр? Дәрестә сүз басымын дөрес куярга

өйрәнү. Сүз басымының урынын белү фикерне дөрес аңлату өчен кирәк. Без бүген басымны дөрес куеп сөйләү күнекмәләрен ныгытырбыз дип ышанып калам.

– Әйдәгез әле, алдагы елларда үзләштергәннәрне тикшерү максатыннан, бирем эшләп алыйк. Моның өчен безгә телефоннар кирәк була. Телефоннар белән бирелгән куар-код буенча кереп, биремне башкарыгыз.

https://wordwall.net/ru/resource/80930873

Басым беренче иҗеккә һәм соңгы иҗеккә төшкән сүзләр.
*(Кемнәрнең мөмкинлеге юк, экранда бирем чыга.)*

| Басым беренче иҗеккә төшкән сүзләр | Басым соңгы иҗеккә төшкән сүзләр |
|---|---|
| | |

**Сүзләр:** киен, барыгыз, нишли, күлмәкләр, китап, килмә, күлмәкләрнең, эшли, җырчы, һәркем, кып-кызыл, башладылар, басым, укытучы, ләкин, мәңге, телефон, телефонга, глобус, глобуста.

| Басым беренче иҗеккә төшкән сүзләр | Басым соңгы иҗеккә төшкән сүзләр |
|---|---|
| киен, барыгыз, нишли, килмә, һәркем, кып-кызыл, ләкин, мәңге, глобус, глобуста | күлмәкләр, китап, күлмәкләрнең, эшли, җырчы, башладылар, басым, укытучы, телефон, телефонга |

– Кемнәр карточкаларда эшләде, яшел ручкалар белән тикшереп чыгыгыз.

Дөрес эшегезгә + куегыз һәм җавапларыгызны санап, билге куегыз. 1 балл – 5 процент. *(1–39 процент – «2»ле, 40–59 процент – «3»ле, 60–79 процент – «4»ле, 80–100 процент – «5»ле.)*

– Кемнәр тәмамлады? Хаталар бармы? Ни өчен хаталар китте икән? Әлеге сорауга җавап бирү өчен, төркемнәрдә эшләп алыйк. Мин карточкалар таратам, таблицаларда басымнары күрсәтелгән сүзләр бирелгән. Сезгә аңлатмасын язарга кирәк. Башкару өчен 5 минут вакыт бирелә. Башладык.

– Таблицаны тикшерү яки тулыландыру өчен, дәреслекләрнең 44 нче битен ачыгыз да 66 нчы күнегүдән җавапларыгызны тикшерегез, үзегез белмәгәннәрен язып куегыз. Төшеп калганнарын тулыландырыгыз.

| Сүздәге басымның урыны | Аңлатмасы |
|---|---|
| балА, урмАн – балалАр, урмандА | *Басым соңгы иҗеккә төшә, кушымча ялганганда, шул иҗеккә күчә.* |
| Аша, тУкта Язылыз, кИлегез | *Барлыкта, боерык фигыльләрдә басым беренче иҗеккә төшә.* |
| килдЕңме, бардЫңмы, бардЫңмыни, килдЕңмени | *Басым сорау кисәкчәләре алдындагы иҗеккә төшә.* |
| татАрча, инглИзчә | *Рәвеш ясаучы кушымчаларга басым төшми, ә алар алдына төшә.* |

| | |
|---|---|
| шАктый, бАйтак | *Кайбер рәвешләрдә беренче иҗеккә төшә.* |
| кАйда, бАрлык, һИчкем, кЕмдер, мОндый, шУндый, | *Сорау, билгеләү, юклык, билгесезлек  һәм кайбер күрсәтү алмашлыкларында басым беренче иҗеккә төшә.* |
| барЫрсың, кайтАлар | *Хәзерге заман хикәя фигыльләрдә басым зат-сан кушымчасы алдына төшә.* |
| пАртия, пАртиягә, дОктор, доктОрны, телефОн, телефонгА | *Алынма сүзләрдә басым шул телдәгечә кала, соңгы иҗектә булса, кушымчага күчә.* |
| укыгАнмын, укыгАнсыз | *-ган/-гән, -кан/-кән үткән заман I һәм II зат хикәя фигыльләрдә басым зат-сан кушымчасы алдыннан төшә.* |
| барачАксың, барачАкбыз | *-ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк киләчәк заман I һәм II зат хикәя фигыльләрдә басым зат-сан кушымчасы алдыннан төшә.* |
| кАра, карА | Син тәрәзәдән кАра.<br>Алсу карА костюм кигән.<br>Укытучы кызыл карА белән язды. |

– Таблицадагы соңгы шакмакта нәрсә бирелгән? Бу нинди сүзләр? *(Омоним.)*

– Беренче җөмләдә басым соңгы иҗеккә төшә (боерык фигыль), икенчесендә соңгы иҗеккә (сыйфат), өченчесендә дә (исем) соңгы иҗеккә төшә. Җөмләдә сүз басымы дөрес куелмаса, интонация дөрес булмый һәм тыныш билгеләре ярдәмендә генә интонацияне үзгәртә алмыйбыз. Сүзләрнең дөрес әйтелешен без ничек тикшерә алабыз? Каян табарга мөмкин? (*Орфоэпик сүзлектән.)*

– Әйе, орфоэпик сүзлекләрдә сүзләрнең әдәби телдә дөрес әйтелеш кагыйдәләре урын ала. Аларның төп максаты – әйтелеше яки басым куелышы ягыннан кыенлык тудырган сүз турында мәгълүмат бирү.

**IV. Яңа белемнәрне ныгыту**

– 67 нче күнегү. Укыгыз. Атларның кеше тормышындагы роле нинди?

– Басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне табып әйтегез. *(Мөмкинме, күзәтмәгән, бармы ...)*

**V. Өй эше. 67 нче күнегү**

Басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне языгыз.

*Омоним парларда басымнар төрле урында булган сүзләр белән җөмләләр төзегез яки әдәбият китабыннан мисаллар табып языгыз.

**VI. Алган белемнәрне тикшерү**

– Бүгенге теманы аңладыгызмы? Сорауларыгыз бармы?

– Тагын телефоннарны алдык һәм әлеге сылтама буенча керегез һәм биремнәрне башкарыгыз.

https://onlinetestpad.com/frmqn5c337xyu

*(Мөмкинлекләре булмаган укучыларга тест таратыла.)*

1. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез.
*Дөрес сөйләгән ялгышмый. (Мәкаль.)*
1) дөрес; 2) сөйләгән; 3) ялгышмый

2. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез.
*Акылсыз авызны ачарга ачкыч кирәкми. (Мәкаль.)*
1) кирәкми; 2) ачкыч; 3) ачарга

3. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне билгеләгез.
*Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә. (Мәкаль.)*
1) кеше, сүзне; 2) булса; 3) ышанмаслык, сөйләмә

4. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне билгеләгез.
*Кешегә яманлык теләгәнче, үзеңә яхшылык телә. (Мәкаль.)*
1) кешегә, үзеңә; 2) теләгәнче, телә;
3) яманлык, яхшылык

5. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез.
*Бер югалган вакыт кире кайтмас. (Мәкаль.)*
1) югалган; 2) вакыт; 3) кайтмас

6. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез.
*Бүген эшләнәсе эшне иртәгәгә калдырма. (Мәкаль.)*
1) бүген; 2) эшләнәсе; 3) калдырма

7. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрнең санын билгеләгез.
*Уйламыйча эшләсәң, чирләмичә үләрсең. (Мәкаль.)*
1) 1; 2) 2; 3) 3

8. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрнең санын билгеләгез.
*Тирләгәнче эшлә, туйганчы аша. (Мәкаль.)*
1) 4; 2) 3; 3) 2

9. Басымы соңгы иҗеккә төшми торган сүзне билгеләгез.
1) утыра; 2) барыгыз; 3) агачлар

10. Басымы соңгы иҗеккә төшми торган сүзне билгеләгез.
1) бара; 2) утынлык; 3) минемчә

11. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне билгеләгез.
*Дөядәй буең булганчы, төймәдәй акылың булсын. (Мәкаль.)*
1) буең, акылың; 2) булсын;
3) дөядәй, булганчы, төймәдәй

12. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне күчереп языгыз.
*Асфальт җәелгән мәйданда малайлар туп уйныйлар иде. (А. Шамов.)*

13. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне күчереп языгыз.
*Ипинең һәр бөртеген кешеләр ел буе тир түгеп, тырышып эшләп табалар. (А.Шамов.)*

14. Җөмләдәге басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне күчереп языгыз.
*Маратның кулында китап, тик ул аны укымый, үз уйларына кереп чумган иде.*

15. Басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне күчереп языгыз.
*Бу фәннән башка тормышыбыз нинди булыр иде, күз алдына китерү дә кыен*.

– Җавапларны тикшерү өчен, дәфтәрләрне алмашыгыз һәм яшел ручка белән дөресләренә + тамгасы, хатасы булса төзәтеп чыгыгыз. Җаваплар экранда. ( 1.3, 2.1, 3.3, 4.2, 5.3, 6.3, 7.3, 8.1, 9.2, 10.3, 11.3, 12. УЙНЫЙЛАР, 13. ТАБАЛАР, 14. УКЫМЫЙ, 15. НИНДИ)

***Бәяләү:*** *1–6 б. – «2»ле, 7–9 б. – «3»ле, 10–12 б. – «4»ле, 13–15 б. – «5»ле куела.*

– Ничә кеше «5»легә эшләде? Бу эшне эшләгәндә авырлык кичердегезме? Сүз басымын белү ни өчен кирәк?

– Әйе, басымга карап, сүзнең мәгънәсе үзгәрә, шигъри әсәрләрне укыганда, басым дөрес булмаса, матур яңгыраш, шигърилек югала. Басымны дөрес куя белмәү аркасында интонация дә дөрес булмый. Алдагы дәрестә интонация белән тирәнрәк танышырбыз. Дәрес тәмам. Бик зур рәхмәт сезгә.



**Гөлия БУЛАТОВА,**

Кайбыч районы Олы Кайбыч урта мәктәбенең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

19

# Илдар Юзеевнең «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасы

(11 нче сыйныфта әдәбият дәресе)

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр үзләштерү дәресе.

**Дәреснең максатлары:**

*Дидактик:* Илдар Юзеевнең «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасын үзләштерү, иҗатының үзенчәлекләре буенча күзаллау булдыру.

*Эшчәнлек ягыннан:* күзәтү аша текстны анализлау күнекмәләре формалаштыру, әсәрдә күтәрелгән тема, проблемаларны билгеләү, тел-стиль чараларына, символларга күзәтү ясау, дәреслек, терминнар, рәсемнәр белән эшләү алымнарын камилләштерү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

***Шәхси:*** яшьлектә тормыш юлын сайлаганда, матур итеп үтү, яшәү мәгънәсенең асылын аңлау, әхлакый сыйфатлар формалашу, киләчәк тормышка кызыксыну уяну.

***Метапредмет нәтиҗәләр:***

*Танып белү УУГ:* дәреслек белән эшләү, укытучының сорауларына җавап бирү, гомумиләштерү, нәтиҗәләр ясау, укучылар укытучы җитәкчелегендә анализ ясау мөмкинлеге алачак, бирелгән мәсьәләләрне чишү юлларын табачак.

*Регулятив УУГ:* дәрескә куелган максатны аңлау, үз нәтиҗәләреңне бәяли белү, укучылар уку мәсьәләсен чишү өчен кирәкле эшчәнлек алып бару мөмкинлеге алачак.

*Коммуникатив УУГ:* диалог алып баруга әзерлек, коллективта үз фикереңне җиткерә белү, укучы башка укучыларның фикерләрен тыңлау, аларга карата үз фикерен белдерә алу мөмкинлеген алачак, фикерен телдән төгәл һәм дөрес итеп әйтү турында уйлаячак.

*Предмет УУГ:* Илдар Юзеевнең «Өчәү чыктык ерак юлга» әсәре турында белү, тел-сурәтләү чаралары, символлар турында искә төшерү, тикшерү биремнәрен үтәү.

**Кирәкле материаллар:** 11 нче сыйныф татар әдәбияты дәреслеге, рәсемнәр, проектор, үзбәя карточкасы, тикшерү карточкалары.

**Дәрес барышы**

**I. Уку эшчәнлегенә мотивация тудыру**

*– Җирдә кеше торса торсын,*
*Эзе калсын тирән булып,*
*Үзе үлсә, эше калсын,*
*Мең яшәрлек имән булып,* –
дигән Муса Җәлил. Сез бу шигырь юллары белән килешәсезме?

– Кеше тормышта матур эш-гамәлләр кылып, лаеклы итеп яшәргә тиеш. Имән кебек башкаларга файдалы булырга тиеш. Яшәгән чорда җәмгыять өчен файдалы эшләр башкарып, сине яхшы яктан гына искә алырлык итеп яшәргә кирәк.

**II. Уку мәсьәләсен кую һәм чишү**

– Әлеге слайдка карап нәрсә әйтә аласыз? *(Укучылар Илдар Юзеевнең тормыш юлы һәм иҗаты белән бәйләп әйтә.)*

– Димәк, бүген дәресебезнең темасы нинди булачак?

1. Әсәргә анализ ясарбыз, әһәмиятен ачыкларбыз.
2. Әсәрдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табарбыз.

**III. Үзбәя**

Алдыгызда бәяләү карталарына һәр этапта үзбәя куярга онытмагыз.

**IV. Актуальләштерү**

| № | | Әйе, юк |
|---|---|---|
| 1 | Малайлар бала чакта бергә уйнап үскән. | |
| 2 | Фазыл гитарада уйный. | |
| 3 | Малайлар ерак юлга өчәү чыкты. | |
| 4 | Фазыл «Кара урман» көен уйный. | |
| 5 | Нур, җиңел тормыш эзләп, көймәдән төшеп калган. | |
| 6 | Нур – Каспий диңгезендә зур корабның капитаны. | |
| 7 | Фазыл «әйттер-типтер» дигән көй артыннан кайларгадыр китеп югалган. | |
| 8 | Лирик «мин» Фазыл белән суд залында очрашты. | |

**Эш барышы**

– Әдипләребезнең һәркайсы тормышны, яшәү мәгънәсен үзенчә сурәтли. Бүген укылачак «Өчәү чыктык ерак юлга» әсәренең нинди үзенчәлеге бар икән?

– Жанры буенча – поэма.

– Поэма нәрсә ул?

– Әсәр нәрсә турында?

– Кешенең тормышта үз урынын эзләве.

– Яшьлектә тормыш юлын сайлау, яшәү мәгънәсен аңлау.

– Гомер (тормыш) юлы катлаулы, аны ничек үткәрү безнең үзебездән тора.

– Тормыш юлы, яшәү мәгънәсе турында язылган әсәрләр әдипләребез иҗатында зур урын алган. Кайсыларында күрергә мөмкин? *(Фатих Хөсни «Йөзек кашы», Шәйхи Маннур «Муса».)*

Ә нәрсә соң ул тормыш юлы, **яшәү мәгънәсе?** Бу сорауга җавап бирү өчен кластер алымын кулланып, яшәү мәгънәсенә туры килгән төшенчәләрне языйк.

Яшәү мәгънәсе:

*Матур эш-гамәлләр кылу.*

*Җәмгыятьтә үз урыныңны табу.*

*Үзебезгә лаеклы нәсел калдыру.*

*Тормышта куйган максатларыңа ирешү.*

*Көчле рухлы булу.*

*Балаларны дөрес тәрбияләү, үз телебездә сөйләшергә өйрәтү, телебезне саклау.*

**V. Яңа материалны үзләштерү**

*Өчәү чыктык ерак юлга,*
*өчебез,*
*Ишкәк тотып нәни кулга*
*өчебез,*
*Ерак киттек чишмәдән*
*инде без.*

– Бу юллар белән автор ни әйтергә тели?

– Тормыш кечкенә генә чишмәдән башлана, ләкин ул сынау-сыналу, кешенең киләчәк язмышын билгеләү чоры кебек билгеләнә.

– Тормыш – көймә, әмма туктап кала, ишкәк ишеп, үзең бармасаң…

– Игътибар итегез әле, нинди образ килеп керде? Ул нәрсәне аңлата?

– Көймә – тормыш көймәсе.

– Су юлы – тормыш юлы.

– Ишкәк – яшәүгә ярдәм итүче көч.

*– Һәм без бардык:*
*Ярты ел бардык, өч ел бардык,*
*Алты ел бардык*
*Һәм беркөнне нәни көймәбезне*
*Диңгезләргә илтеп чыгардык.*

– Бу юлларда нинди образны күрәсез? Ул нәрсәне аңлата?

– Диңгез образы. Чишмә суының диңгезгә барып җитүе ул – геройларның, ягъни Нур белән лирик геройның, тормышта үз урыннарын табуы, яшәүләренең мәгънәсен күрсәтә.

Игътибар итегез әле, нинди образ килеп керде? Ул нәрсәне аңлата?

*–…сезнең алда ике юл бар,*
*Теләсә кайсын сайлагыз*
*Үзегез, – ди кәккүк, –*
*Алда әле борылмалар бик күп,*
*кәк-күк!*
*Я түзегез, я китегез кирегә,*
*Хәл итегез үзегез, – ди кәккүк.*

– Укучылар, поэмага нинди образ килеп керә?

– Кәккүк.

– Аның вазифасы нинди?

– Ул яшьләрне күзәтеп, искәртеп киңәшен биреп тора. Халыкның бик борынгы чорлардан килгән ышанулары буенча, кәккүк – кеше гомеренең озынлыгын әйтеп бирүче кош.

– Көймә, кәккүк турындагы җырларны искә төшерик әле.

– «Парлылар йөри көймәдә», «Кәккүк», «Көймә генә килә генә», «Көймәдә», «Ишкәк ишкәндә», «Ялгыз көймә» һ.б.

*– Их!..*
*Бер дә генәй* ***нужа*** *күрмәенчә,*
*Ир булалмый ата баласы…*

*– Әйттер, типтер, сиптер әйдә,*
*без җирдә кунак кына.*

– *Нужа* сүзенә нинди мәгънә салынган?

– Әлеге юллар нәрсәдән алынган һәм нәрсәне аңлата?

– Җырдан алынган, тормыш юлының авырлыгын аңлата.

– Бу җыр сүзләре аша автор нәрсә әйтергә тели?

– Җырларда – ата-бабаларыбызның тормыш тәҗрибәсе. Язучы юкка гына бу мәгънәле сүзләрне кертмәгән, егетләр инде хәзер үк ишкәк артына утырган бит.

Ике җыр – халыкның авыр, әмма мәгънәле тормышын яктырткан «Кара урман» көе белән мәҗлес такмагының каршы куелуы ярдәмендә автор Фазыл белән аның дусларының тормыш юллары, яшәү мәгънәсе каршылыгын тагын бер кат көчәйтеп куя.

*– Уңга китсәң – авыр, әмма*
*бәхет ишеген ачар, ди икән,*
*сулга китсәң – җиңел, әмма*
*бәхет синнән качар, ди икән.*

– Әкияттән алынган сүзләр белән әсәрдә күтәрелгән проблема туры киләме?

– Автор әкият алымнары белән Фазылның дөрес юлдан китмәгәнлеген сурәтли. Ул тимер рәшәткә артына эләгә.

*– Ул кирегә китеп бара иде,*
*Үзе төн шикелле кап-кара иде.*
*Әллә җырлый, әллә кычкыра,*
*Аңа кушылып аты пошкыра.*

– Нинди образ килеп керде? *(Төн кешесе, егет сайлаган юлның куркыныч булуын искәртә.)*

Без аны Фазылның караңгы киләчәге, авыр язмышы дип аңлый башлыйбыз. Көймәдә җырлап-уйнап кына барса да, арган Фазыл аннан бөтенләй үк төшеп калырга уйлый. «Без җирдә – кунак кына», – дигән җырларны үз итә башлый ул. Халык мәкаленә нигезләнгән бу җыр җиңел яшәргә күнеккәннәрнең яшәү фәлсәфәсен чагылдыра.

*– Их, Фазылҗан,*
*Ят җыр арбасыннан*
*Тартып алыр идем мин сине...*
*Соң инде, зур диңгездән*
*Кипкән инешләргә*
*Һич тә барып булмый шул инде.*

Фазылҗанның ике юл чатында калып адашуын, ялгыш юлдан китеп югалуын кипкән инеш образы символлаштыра.

– Әсәрдә нинди саннар белән очраштыгыз? Алар ни өчен кулланылды икән? *(Мәгънәне, каршылыкны көчәйтү өчен.)*

– Хәзер тексттагы шигъри юлларның нәрсә аңлатуын билгеләгез. Индивидуаль биремне эталон буенча иптәшебез тикшерә һәм билге куя.

| Мисаллар | |
|---|---|
| Сулар кая илтә икән,<br>Безне ниләр көтә икән,<br>кәк-күк! | *риторик эндәш* |
| Ишетәсеңме, урманда<br>киңәш бирә кем анда? | *рефрен* |
| Чабыш атларга охшатам<br>Гомернең агышларын | *чагыштыру* |
| Дулкын ярга кага икән,<br>Гомер судай ага икән,<br>кәк-күк! | *чагыштыру*<br>*риторик эндәш* |
| Ул кирегә китеп бара иде,<br>Үзе төн шикелле кара иде.<br>Әллә җырлый, әллә кычкыра,<br>Аңа кушылып аты пошкыра. | *янәшәлек* |

**VI. Ныгыту, күнекмәләр формалаштыру этабы**

– Ә автор фикере буенча, тормышның әһәмияте нидә? Парларда бу сорауга җавапларны тексттан табабыз һәм аңлатырга әзерләнәбез.

– Тормыш – көймә, әмма туктап кала, ишкәк ишеп, үзең бармасаң...

– Авылдан, чишмә буеннан башланган тормыш юлы аларны төрле биеклекләргә күтәрә. Шагыйрь теле белән бу хакта без, һәр лирик геройның чишмәсе үзе сайлаган диңгезгә коя, дип тә әйтә алыр идек.

– Бу фикерне әсәрнең шигъри юллары белән дәлилләгез.

*– Моңлы булгангамы, көймәмне мин*
*Шигырь диңгезенә караттым.*
*Ә Нур дустым – Каспий диңгезендә*
*Капитаны зур бер корабның.*

– Сез быел чыгарылыш сыйныф укучылары буларак, һөнәр сайлаганда ныклы ышаныч һәм акыл белән эш итеп, туры юлдан тайпылмыйча, максатыгызга ирешсәгез иде.

**VII. Рефлексия этабы**

– Автор нәрсә әйтергә тели?

– Илдар Юзеев, Фазылҗан язмышы аркылы, кешенең яшәешне һәм үз-үзен танып белүе, кеше гомеренең кыйммәте, язмыш, яшәү мәгънәсе хакында фәлсәфи фикерләрен җиткерә, ягъни тормышта үз юлыңны эзләргә һәм табарга кирәклеген ассызыклый,  көрәшкә, хезмәткә, тормышка сәләтсез кеше явызлык корбаны булуын күрсәтә.

– Әйдәгез, дәрес башында башлаган кластерыбызны тулыландырып, бүгенге дәрестә өйрәнгән төшенчәләрне язып куйыйк. *( Кластер тулыландырганда, «Яшәү яме» җыры тыңлана.)*

*Үкенмичә яшәүләргә*
*Бу дөньяда ни җитә:*
*Үкенечле булмый гомер*
*Изгелекләрдә үтсә.*

Һәркем җиргә яхшылык кылу, матурлык тудыру максаты белән җибәрелә, шуны үтәмәгәннәр Фазылҗан кебек юкка чыгуга дучар ителә. Әсәрнең идеясе кеше кулында, үз язмышы гына түгел, бөтен галәм, кешелек язмышы, кеше шуны тоеп, миссиясен үтәп яшәргә тиеш дигән фикер ята.

Бәяләү карталарына билгеләрне куеп җыябыз, өй эше алабыз.

1. И.Юзеевнең «Өчәү чыктык ерак юлга…» поэмасын укырга.
2. «Тормышта үз юлыңны ничек табарга?» дигән темага фикерләреңне язарга.



**Ләйсән ИБРАЕВА,**

Казан шәһәре 167 нче мәктәпнең
югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

20

# Галимҗан Гыйльмановның «Ике дус һәм Ак бабай хакында кыйсса» әсәре буенча квест

(6 нчы сыйныфта әдәбият дәресе)

**Квестның максаты:** Галимҗан Гыйльмановның «Ике дус һәм Ак бабай хакында кыйсса» әсәренең идея-эстетик кыйммәтенә төшенү.

**Теманың актуальлеге:** федераль стандартлар буенча укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру мөһим урын алып тора. Дәрестән тыш эшчәнлеккә укучыларны тарту, аларны әлеге эшчәнлек белән кызыксындыру укытучыдан тәҗрибә һәм белем сорый. Бүгенге көндә үз халкыңның тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, төбәгеңнең күренекле шәхесләрен өйрәнү һәм алар турында мәгълүматлы булу бик кирәк.

**Үткәрү формасы:** квест-уен.

**Бурычлар:** Галимҗан Гыйльманов иҗатына карата кызыксыну тудыру; укучыларның әсәрнең идея эчтәлеген һәм әхлакый кыйммәтен аңлауларына ирешү; табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

**Уен тәртибе:** квест уенында 7–10 кешедән торган ике команда катнаша. Аларның һәрберсенә маршрут кәгазьләре бирелә. Мәктәпнең төрле урыннарында (алар шулай ук алдан билгеләнә) укучыларны алдан әзерләнгән биремнәр көтеп тора. Биремнәрне тапшыручы биремнең үтәлешенә дә билге (балл) куя. Квесттан соң жюри кайсы команданың баллар саны күбрәк җыйганын ачыклый. Биремнәрне тизрәк башкарган командага өстәмә балл куела.

Укучыларны сәламләгәннән соң аларга маршрут кәгазьләре бирелә.

**1 нче маршрут кәгазе**

***1 нче бирем.*** Язучыларның портретлары арасында Галимҗан Гыйльманов портретын табыгыз (2 балл).

Алдагы бирем сезне математика кабинетында көтә.

***2 нче бирем.*** Әсәрдә ничә герой бар? *(Дөрес җавап: 3, дөрес җавап өчен 2 балл бирелә.)* Алдагы биремне табу өчен, ребусны чишәргә кирәк булыр.




Укучылар, ребусны чишеп, *баскыч* янына баралар. Анда 3 нче биремне табалар.

***3 нче бирем.*** Сыерчык оясын кайсы урынга элергә кирәк? Ак бабайның киңәшләрен искә төшерегез. *(Оя кояш ягына карап торырга тиеш, чөнки яз көне һава торышы үзгәрүчән була; агач өй янында ук урнашмасын, югыйсә кошлар песидән куркачаклар; шулай ук йорт түбәсенә җил вакытында шакылдаган агач ботаклары да кошларга зыян итәчәк. Дөрес җавап өчен 1–3 балл бирелә.)* Алдагы биремне табу өчен, укучыларга табышмак чишәргә кирәк була.

Сырлы-сырлы-сырлы ул,
Безнең белән җырлый ул.

Укучылар, табышмакның җавабы гармун икәнен әйтеп, музыка кабинетына юнәләләр. Анда аларга 4 нче бирем бирелә.

***4 нче бирем.*** Сорауларга җавап бирегез *(һәр җавапка 1 балл бирелә)*:

– Мөсәллим карт кем ул? *(Ак бабайның чын исеме.)*

– Башта ояга әти сыерчык киләме, әни сыерчыкмы? *(Әти сыерчык, берничә көннән ул әни сыерчыкны алып килә.)*

– Әсәрдә үкенү хисләрен кайсы геройлар кичерә *(Ак бабай Хәлимгә нindидер мөһим әйберне әйтеп кала алмаганына үкенә; Хәлим, картның киңәшләрен тотмыйча, басмасыз оя ясавына үкенә.)*

**2 нче маршрут кәгазе.**

***1 нче бирем.*** Бирелгән рәсемнәрдән сыерчык рәсемен табыгыз. *(Укучылар алдына тукран, карлыгач, сыерчык рәсемнәре куела. Дөрес җавап өчен 2 балл.)*

Алдагы бирем сезне тарих кабинетында көтә.

***2 нче бирем.*** Ак бабайның тормышын фаҗигалы төскә буяган сугыш. *(Әфган сугышы, улы шунда һәлак була. Дөрес җавап өчен 2 балл бирелә.)*

Алдагы биремне табу өчен, ребус чишәргә кирәк.




Укучылар, ребусны чишеп, кабинетта өстәл өстендә яткан китапны алалар. Китап эчендә 3 нче биремне табалар.

***3 нче бирем.*** Бу агач әйберләрнең кайсыларын Хәлим, кайсыларын Сәлим ясаган?



*(Дөрес җавап: Хәлим урындыклар ясый, Сәлим уенчыклар ясау остасы була. Дөрес җавап өчен 1–3 балл бирелә.)*

Алдагы биремне табу өчен, укучыларга табышмак бирелә. Аның җавабын табып, укучылар тиешле кабинетка юнәләләр. Табышмак:

– Диңгезе бар – йөзеп булмый,
Юлы бар – йөреп булмый.
Җире бар – сөреп булмый.

Укучылар, җавапның географик карта икәнен белеп, география кабинетына юнәләләр.

***4 нче бирем.*** Сорауларга җавап бирегез *(һәр җавапка 1 балл бирелә)*:

– Хәлим белән Сәлимнең сыерчык ояlары арасында нинди мөһим аерма бар?

*(Сәлимнекендә басмачык бар.)*

– Ак бабай нинди җан турында гомерле булмый, ди? *(Куркып үскән җан.)*

– Кем ясаган ояга кошлар беренче булып оялый? *(Сәлим ясаган ояга.)*

Квест ахырында әсәрнең әхлакый кыйммәте турында нәтиҗә ясала. Укучыларга кошлар тормышына игътибарлы булырга киңәш ителә, чөнки безнең җылы якларда кошлар тормышларын саклап калыр өчен, салкыннардан качып торалар, ә туган ягыбызга бала чыгару, нәсел калдыру миссиясен үтәр өчен кайталар. Командаларның һәрберсенә дә рәхмәтләр әйтелә.

# Берничә журналга язылганда махсус ташламалар

**«ГАИЛӘ һӘМ МӘКТӘП» журналы**
Индекс **П2429** **798 сум**

**«МӘГАРИФ» журналы**
Индекс **П2423** **798 сум**

**«МӘГАРИФ» + «ГАИЛӘ һӘМ МӘКТӘП» комплекты**
Индекс **П2433** **1500 сум**

**АЛЬТЕРНАТИВ РӘВЕШТӘ**
**«ГАИЛӘ һӘМ МӘКТӘП» журналы** **570 сум**
**«МӘГАРИФ» + «ГАИЛӘ һӘМ МӘКТӘП» комплекты** **1 100 сум**




*Язылырга онытма!*

## Ничек язылырга?

1 Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль порталында

2 «Татарстан почтасы»ның теләсә кайсы бүлекчәсендә

3 Альтернатив рәвештә, редакциягә килеп **(Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт, 7 нче кат)**

4 Телефон аша: **8 (917) 259-28-31**

## «Гаилә һәм мәктәп» журналын сатып алу өчен:

**Вендинг аппаратларында:**

- EUROSPAR. Глушко ур., 16
- Сукно бистәсе метро станциясе
- МЕГАСТРОЙ. Гаврилов ур., 5

**«Әдәби кафе»да**
Казан, Декабристлар ур., 2 йорт

SHOP.TATMEDIA

Яндекс Маркет